Рафаэль Мостафин

КАБАН КУЛЕ СЕРЛӘРЕ


П. Калан

Рафаэль Мостафин



Тарихи-документаль повесть

ҚАЗАН ТАТАРСТАН ҚИТАП НӘШРИЯТЫ 1990

ББК 63.3(2Р-Тат)
М67

Мостафин Р. Ә.

М67 Кабан күле серләре.— Казан. Татар. кит. нәшр., 1990.— 143 бит.
ISBN 5—298—00346—X

Язучы Кабан күле мисалында, аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлана һәм әйләнә-тирә мохитне саклау хакында фикер йөртә.

Китап киң катлау укучыларга атап чыгарыла.

М $\frac{0503020900-180}{М132(03)-90}$ 29—90 ББК 63.3(2Р-Тат)

ISBN 5—298—00346—X

© Татарское книжное издательство, 1989.
© Рафаэль Мостафин, 1990
© М. Вәлиев, рәссам, 1990

ЛЕГЕНДАМЫ, ГАИЛӘ РИВАЯТЕМЕ?

Шул заман, кем, килде Мәскәү гаскәре,
Бу Казанга туп атарга башлады.
Шул вакыт ханнар, вәзирләр качтылар,
Барча малны ушбу күлгә сачтылар
Сачтылар алтын-көмешнең һәммәсен,
Ягъни «безнең мал кешегә калмасын».
Шул заманнан бирле, кем, алтын-көмеш
Күл төбендә һич хисапсыз күп, имеш.

Габдулла Тукай.
«Печән базары яхут яңа Кисекбаш».

Әрсез карт. Ханнар хәзинәсенең сере.
Күл төбендә ниләр бар?
Югалган ярлыклар.

Ничә еллар инде мин үземне гаепле кешедәй хис итәм. Шул чакта теге картка тиешенчә хөрмәт һәм игътибар күрсәткән булсам, бәлки бөтенесе башкача булыр иде... Гасырлар кичкән бу табышмакны чишеп җиткермәсәк тә, бәлки шуңа якын торыр идек. Хәер, барысын да рәттән сөйлим әле.

Кайсы елда булды соң әле бу? Һәрхәлдә, 1965 елның августы — 1968 елның апрель арасында бугай. Шул вакытта мин «Казан утлары»нда редактор булып эшли идем.

Көннәрдән бер көнне кабинетыма бер бик сәер карт килып керде. Кечерәк буйлы, бераз бөкрәя төшкән бу бабайның башында картлар кия торган иске түгәрәк каракүл бүрек, аягында — тузып кыршылган читек-кәвеш иде. Төсе уңган кәзәкие революциягә кадәр үк тегелгән булгандыр, мөгаен... Кулындагы таягына хәтле тәмам шомарып-ялтырап беткән. Култык астында — төенчек. Әйтерсең лә мунчага барышлый гына редакциягә сугылган.

Бабай өстәл янына килде һәм татарча ике куллап күреште. Аның пергамент кебек сап-сары куллары кытыршы иде. Күзләре әллә инде төсе белән бер-берсеннән аерыла, әллә инде кылыерак.

Менә ул, биленә таянып, аһ-ваһ килеп, тәкъдим ителгән урындыкка барып утырды. Башта гаиләм, әти-әниемнең исәнлеген, аларның һәркайсының сәламәтлеген сора-

шып чыкты. Иркенләп дога кылды, битен сыпырды, шуннан соң гына сүзен башлады.

Бабакай һаман әле сүзенең төп өлешенә күчә алмый утырганда сиздермичә генә сәгатемә күз төшердем. Һәрвакыттагыча, эшнең иге-чиге юк, бер сәгатьтән редколлегия, ә син монда чираттагы графоман — язу чире кагылган бераүнең кульязмасын ничек итеп ипләбрәк кире кагарга икән дип борсаланып утыр.

Әмма карт көтмәгәндә Кабан күленә мөнәсәбәтемне сорашырга кереште. Дөресен генә әйткәндә, үз мәшәкатьләрем дә баштан ашкан иде, шунлыктан, исем китмичә, икеле-микеле генә җавап кайтардым.

Әйе, күл, әлбәттә, Казанның горурлыгы, тарихи бизәге... Әйе, ул элекке данын югалта бара («Югалта гынамы? Күз алдында чери, үлеп бара»,— дип бүлдерде мине карт). Ләкин... Ни эшләмәк кирәк — прогресс өчен бәһане зурдан түләргә туры килә шул... Күлне чистартасы бар анысы. Ләкин моңа миллионнар кирәк. Аларны каян аласың?

Менә шунда карт «тондырды» да инде. Хәйләкәр елмаеп, серле генә әле бер, әле икенче күзен ялтыратып бераз карап торгач, ярып салмасынмы:

— Ә миллионнар күл төбендә ята бирә...

Карт миннән нидер көтә иде сыман.

— Сез Казан ханлыгының хәзинәсе турындагы легенданы күздә тотасызмы?

Бабай тантаналы төстә көлеп җибәрде:

— Кемгәдер, бәлки легендадыр да. Минем исә моңа иманым камил. Ул гына да түгел, сезнең алдыгызда хакыйкатьне белүче бердәнбер кеше. Менә нәкъ шуны әйтергә килдем дә.

«Имәндә икән чикләвек!» — дип эчтән генә елмаеп куйдым. Димәк, алдымда графоман түгел, ә бәлки авышкан бер карт булып чыкты. Редакцияләргә андыйлар да күп йөри шул.

— Мин Әҗемнәр нәселеннән булам,— дип дәвам итте карт.— Бу исем сезгә мәгълүмме?

Кайсыбызның гына бу борынгы нәсел турында ишеткәне юк икән? Алар акчасына салынган данлыклы мәчет бизәлеше, нәфислеге белән Казанда иң матур биналарның берсе булып санала.

— Шул-шул,— диде карт һәм, авыз ачарга да ирек бирмичә, борынгы исемнәрне тезеп китте. Мин аларны отып калырга да өлгермәдем. Турысын әйтим, артык игътибар да итмәдем. Аның шактый ук буталчык аңлатмаларыннан

шуны аңладым: бабай буыннан-буынга тапшырылып килгән ханнар хәзинәсе турындагы мәгълүматларны белүчеләрнең соңгыларыннан берсе икән. Ул «легенда» дигән сүзгә җаны-тәне белән каршы. «Гаилә риваяте» дип кырт кисә. Легенда булды ни дә, гаилә риваяте булды ни — ул вакытта әллә ни зур аерма күрмәгән идем мин.

Менә ул кәкрерәк, калтыранып торган бармаклары белән төенчеген чишәргә кереште. Андагы папкалардан көрән төскә керә башлаган бик борынгы кәгазьләр килеп чыкты. Аларның чит-читләре, почмаклары уалган, сынган, хәтта янган иде. Барысы да диярлек гарәп шрифтында язылган. Аңлавымча, монда әлеге гаилә әгъзаларының хәзинәгә кагылышлы васыятьләре, хатлары һәм башка төрле язмалары тупланган иде.

Бабай кат-кат төрелгән, су тамгалары төшерелгән зур гына кәгазьне аеруча бер саклык белән җәеп салды. Аны аерым кисәкләрдән җыйды дисәм дә була, чөнки кәгазь бөкләнгән урыннарыннан ертылып ук чыккан иде.

Кәгазьгә очы аска карап торган агачка охшаган бер сурәт төшерелгән. Ботакларга, алма кебек, төрле төстәге түгәрәкләр тагылган. Кайбер ботаклар алмадан соң үсүдән туктап калган, күбесе исә тармаклана бара. Бу — татар шәҗәрәсе иде. Шәҗәрәләр күргәнем бар анысы, әмма мондый да борынгы һәм бу кадәр дә пөхтәләп-җентекләп эшләнгәнен беренче очратуым иде.

— Монысы,— карт үзенең сөякчел сары бармагы белән өстәге түгәрәкләрнең берсенә төртте,— Казанның соңгы ханы Ядгәр яраннарыннан. Укымышлы кеше — Кол Шәриф [1] мәдрәсәсендә гыйлем алган.

Дөрес хәтерләп калган булсам, бу кемсә югары хан советы — диван составына кергән, хәзинәне яшерүдә катнашмаса да, серне белгән. Камалган шәһәрдән исән-имин чыга алган, әмма берме, икеме ел үткәч, бәрелешләрнең берсендә һәлак булган, имеш.

Картның әйтүенчә, хәзинәнең төгәл урынын ханлыкта нибары ике яки өч кенә кеше белгән, тик берсе дә исән калмаган. Килмешәк дип, серне Ядгәр ханга да ачмаганнар. «Һәм бик дөрес эшләгәннәр,— дип өстәде карт,— ник дисәң, ышанычлы кеше булмаган ул. Шәһәрне саклый алмаган. Әсир төшкән. Белгән булса, язмышын җиңеләйтер өчен, серне һичшиксез чишкән булыр иде...»

Бабай сәгатьтән артык утырды. Ул үзе миңа кызганыч

[1] Кол Шәриф — XVI гасырның беренче яртысында яшәгән галим, дин әһеле. Казанның ул чордагы иң зур һәм атаклы мәдрәсәсе аның исемен йөрткән. 1552 елда батырларча һәлак була.

һәм теңкә корыткыч кеше булып, ә ул сөйләгән нәрсәләр исә күп дигәндә тарихи мәзәк кенә булып тоелды. Хәзер, менә егерме елдан артык вакыт үткәч, кайта-кайта әңгәмәбезне хәтердә яңартам, аннан реаль, ягъни риваятьләрдә дә, тарихи чыганакларда да булмаган мәгълүмат табарга тырышам.

Хәзинә яткан урынны анык белмәсә дә, Исмәгыйль агай, аны күлнең төньягында, «Спартак» комбинаты турысындарак булырга тиеш, дигән иде. Аны табу өчен, имеш, Болак агып чыккан җирдән ерак түгел Кабанга койган инеш янына басарга кирәк. (Хәзер анда төзелмичә калган проект оешмалары бинасының бетон субайлары ыржаеп тора — шул хан заманнарыннан бирле үк түгел микән?) Аннары берничә ук атымы араны үтәргә, ярдагы билгеле бер урынны табарга (нинди урын икәне шулай ук мәгълүм түгел), каршы ярдагы икенче бер урынга йөз төбәп, берничә дилбегә буе араны йөзеп үтәргә кирәк. (Күргәнегезчә, табышмак өстенә табышмак!) Хәзинә күлнең нәкъ менә шул турысында ята инде. Һәм әле шундый тирәнлектә ки, тагын бер хәйләсен белмәгән килеш кулга төшерермен димә.

Карт, күзләрен ялтыратып, кеткелдәп алды.

— Безнең бабайлар аңгыра булмаган шул!

«Информация»нең бу кадәресен мыек астыннан елмаеп кына тыңладым — анык берни дә юк иде анда. Ә менә карт хәзинәнең үзен тасвирлауга күчкәч, кызыксынуым арта төште. Агайның әйтүе буенча, бер кушуч тәңкә белән берничә балдак яки акча тулы чүлмәк тә түгел, бәлки хан казнасы яшерелгән. «Моның ни икәнен аңлыйсызмы? — диде ул, нигәдер пышылдауга күчеп һәм миңа таба елышып.— Юк, сез моны күз алдына да китерә алмыйсыз. Хәзер аңлатып бирәм. Моны сезгә мин генә сөйли алам».

Исмәгыйль абзый әйтүенчә, казна өч өлештән торган. Беренчедән — акча суга торган алтын-көмеш һәм Казанда сугылган тәңкәләр үзләре, затлы металл ханлыкның Уралдагы приискаларында чыгарылган. Чулман һәм Идел буйлап Казанга китертелгән. Карт хәтта акча сугу йорты (бусы — безнең заман атамасы, бабай мин белмәгән борынгы бер сүз кулланды) башлыгының исемен дә әйтте әле.

Икенчедән — казна акчасы. Ул чакларда кәгазь акча чыгарылмаган. Казанда төрле тарафларда сугылган алтын һәм көмеш тәңкәләр сакланган: төрек, гарәп дирһәмнәре, фарсы, Мисыр, Көнбатыш Европа тәңкәләре... Иң күбе көмеш рус гривналары һәм гарәп дирһәмнәре булган. Акча ныклы контрольдә торган, аның өчен хан казначысы башы белән җавап биргән.

Казнаның төп өлеше ганимәт малыннан, ханга бирелгән бүләкләрдән, үз осталары ясаган затлы әйберләрдән тупланган. «Ниләр булганмы! И, анда булган затлы әйберләрне төшегездә дә күрәсегез юк...» Бабакай кызып-кызып сөйләргә керешге — Әстерхан чикләвеге хәтле зөбәрҗәтләр сирәк очрый торган шәрык бриллиантлары, испан шәрабыдай кызыл якутлар, күксел топазлар һәм төсен үзгәртүчән александритлар белән бизәлгән күз явын алырлык диадемалар, энҗе белән чигелгән камәрләр, алмаз һәм зәңгәр якутлар белән зиннәтләнгән кылыч-хәнҗәр, фил сөягеннән ясалган тартмалар, төрле-төрле алтын савыт-саба, кувшин-комган ише әйберләр, йөзек-балдак, муенсалар... Карт тәмам эсәрләнде, хәтта йөзләре үк алсуланып китте, ә төрле төстәге күзләре үзе тасвирлаган асылташлар сыман елкылдый башлады.

Аеруча зур һәм кыйммәтле асылташларның исемнәре дә булган. Мәсәлән, Сөембикәнең йокы бүлмәсендәге алтын шәмдәлдә солтан исемле искиткеч зур, матур асылташ беркетелгән булган.

Казнаның бу хәзинәсен саклаучы ханлыктагы иң дәрәҗәле затлардан саналган. Хәзинәгә ханның яраннары да якын килә алмаган. Бабайның әйтүенчә, бу байлыкка хан үзе дә хуҗа булмаган. Аны ишәйтергә яраган яравын, ә менә тоту-туздыру хәтлесе... Мондый ханны шунда ук тәхеттән төшергән булырлар иде — ханлыкта андый хәлләр дә булгалаган...

Чамасыз кызып киткән картны бүлдереп, сорау бирдем.

— Я, ярый. Сез сөйләгәннәр чынлап та чүлмәккә сыймас иде. Шулай да, сезнеңчә, күпме байлык соң анда?

— Миллионлаган сумлык! — дип кычкырып җибәрде бабай.— Уннарча миллион сумлык! Тик аларның кыйммәте акча белән генә бәяләнми ләбаса.

— Авырлыгы күпме тартыр икән?

Карт, җилкәсен җыерып һәм ничектер башын кош сыман янга салып, уйга калды.

— Әйтик, бер киломы, икеме, өчме?

Картның чын-чынлап кәефе китте.

— Ниткән кило ди ул? Сез миннән көләсез мәллә? Күпме гомер шуны тукыйм ләбаса — хан казнасы булыр ул! Төгәл үк әйтә алмыйм, тик, шулай да, тулаем авырлыгы уннарча, ә бәлкем йөзләрчә батмандыр [1],— дим.

---

[1] Батман — Казан ханлыгында авырлык үлчәме. Бер батманга төрле вакытта 4,8 дән алып 12 потка кадәр, ягъни 64—192 килограмм кергән.

Менә шушы урында «каптырмакчы» идем мин аны.

— Андый авыр йөкне камалышта калган каладан ничек алып чыкканнар соң?

Әмма карт моңа авыз чите белән елмаеп кына куйды.

— Камалыш вакытында дигәнне каян алдыгыз? Кем әйтте аны? Камалышка кадәр! Аңлыйсыңмы, камалышка КАДӘР! Күтәреп тә түгел, көймәләрдә алып чыгалар. Төнлә инде, әлбәттә, тиешле саклык чараларын күреп. Казан ул чакта әле авыл хәтле генә бит. Сизүче, бу хакта чышын-пышын сөйләшүче булгандыр, ансы. Тик бераздан мондый кеше дә калмый.

— Ярый, калдырыгыз кәгазьләрегезне,— дидем мин, карттан котылыр өчен.— Белгечләр белән киңәшеп карармын.

Әмма агай кәгазьләрне калдырудан катгый рәвештә баш тартты: кемгәдер калдырган булган да, соңыннан иң кирәкләре югалган, янәсе. Үзе алдында гына карарга рөхсәт итте. Тик... гарәп теле белгечләрен исәпләмәгәндә, минем кордашлардан кем генә бу борынгы язуларны ерып чыга алыр иде икән? Революциягә кадәрге рус газетасыннан «Волжский вестник» булса кирәк) кисеп алынган хәбәрне генә укый алдым. Анда әллә Белгия, әллә Америкадагы бер компаниянең Казан думасына Кабан күлен бернинди түләүсез ләмнән чистартып чыгарга тәкъдим итүе турында язылган. Бер генә шарт куела: табылган һәммә нәрсә компания милкенә әйләнә. Бабай хәбәргә мондыйрак аңлатма бирде: Әҗемнәр нәселеннән чит илдә яшәүчеләр дә бар, шулардан берсе серне саткан булса кирәк. Эшнең асылын аңлаганга, дума ризалык бирмәгән.

— Тарихчылар белән сөйләшеп карагыз. Алар расласа...

Картны ток куыргандай булды:

— Рәхмәт. Элек сөйләшкәннәрне дә онытасым юк.

— Нәрсә диделәр соң?

— Байбәтчә, хан калдыгы син, дип сүктеләр. Юк, хәзинәне эзләү сылтавы белән ханлык идеяләрен яңартырга юл куймабыз! Егерме еллар элек килгән булсаң, бүтән урында һәм бүтәнчә сөйләшкән булыр идек,— диделәр.

Бабайны ничек тә булса юатырга, хәленә керергә кирәк булгандыр. Бәлкем, кәгазьләрен тарихчыларга яки каллиграфия белгечләренә күрсәтеп карарга ризалашкан да булыр иде әле. Әмма... Ишектә — инде ничәнче тапкыр! — җаваплы секретарь күренде. Ул, түземсезләнеп, сәгатенә күрсәтте — редколлегия утырышын башларга күптән вакыт, янәсе. Карт күрмәгәндә ясаган башка ишарәләре дә

бик аңлаешлы иде: утырмасана шуның белән, бураның уйнатып чыгар кабинеттан!

Киткәндә бабакай шарт куйды: бу турыда беркемгә дә сөйләмәскә. Хәтта суд белән дә янады. Көлке түгел диген: күпме гомер минем башны катырды-катырды да, инде «оныт», имеш.

Исмәгыйль Әҗемов турында соңрак та ишеткәләргә туры килде. Редакцияләр һәм төрле учреждениеләрнең бусагасын шактый таптаган ул. Тик ханнар хәзинәсе турында бүтән авыз ачмаган бугай. Күбрәк Кабанны чистарту кирәклеген алга сөргән. Ләкин тыңлаган кеше сизеп тора бит: әйтеп җиткерми, җеп очын яшерә бабакай. Сүзен артык кызып-үрсәләнеп яклавы да шикләндерә: ай-һай, үз мәнфәгатен алга куймый микән бу? Өстәвенә, аны бабалары яшергән байлыкка ия булу теләге исәрләндергән, дигән хәбәр дә үзеннән алдарак йөри иде. Шуңа да картка мөнәсәбәт кирәкмәгән якка үзгәргән иде. Мескен картның артыннан да мыскыллап көлеп кала башладылар. Бер редактор, икенчесен кызык итәргә теләсә, «Шул гына хәл итә инде аны»,— дип, бүлмәсен өйрәтеп, бабайны шунда җибәрә иде.

Бераздан ул юкка чыкты. Үлгән, дигән хәбәр таралды. Күрәсең, әҗәлен сизгәнгә үзенең соңгы һәм өметсез «кампаниясен» башлап җибәргән инде ул.

Ярый, нишлисең, өлкәннәр әйтмешли, хәерле каза булсын. Карт иде бит, сиксәнне тутырган булгандыр. Әмма минем никтер бүтәннәр кебек гамьсез генә: «Урыны күптән шунда иде»,— дип кабатлыйсым килмәде. Бу үткән заман илчесенең сөйләгән сүзенә, үз-үзен тотышына, төскыяфәтенә дә җиңел генә кул селтәргә, аларны онытырга мөмкинлек бирми торган нидер бар иде. Ниндидер сагышлы бер тәвәккәллек, имгәтелгән ихлас өмет димме... Үзенең асылын ачарга курыккан, заты төсмерләнмәгән кайбер замандашларымнан аермалы буларак, аның чын шәхес булуы сизелә иде. Күз алдында җансызлана барган күлнең язмышын кайгырту, аның өчен әрнү бар иде бу карт кешедә. Ни булса булды, шуннан соң гаргарә хәлендәге күлгә дә, шәһәребезнең үткәненә дә, күптән таныш легендалар һәм риваятьләргә дә бүтән күз белән карый башладым.

Сөйләшүебезне кайта-кайта искә төшерә торгач, бер тапкыр кинәт кайнап торган, киеренке вакыйгалар белән тулы тормышыбызга нәрсә җитмәгәнлеген аңлап алдым. Үткәнне сиземләү, заманның заманга тере кешеләр, әрнүләр һәм сөенечләр аша ялгануын тою җитми безгә! Күбебездә бу хис җуелган инде. Ләкин... исебез китми,— типтереп яши

бирәбез. Шушы мизгелдәге хаҗәтебезне кайгыртып, чын яки уйдырма файда артыннан куып чаба бирәбез... Якты кояш астында дөньяга килеп, миллионлаган олтан ялтыратып бетергән урам ташларына басып йөргән, алсу таңга карап сокланган һәм... озын кичләрне «зәңгәр экран»га кадалып үткәргән кешеләрнең беренчеләре дә, соңгылары да гүя менә без, бары без генә!

Берничә ел үткәч, картның сөйләгәннәрен бер таныш тарихчыга әйттем. Исе китмичә тыңлады. Кәгазьләр турында ишеткәч, җан керде үзенә керүен. Тик, аларның җуелуын белгәч (карт берьялгызы яшәгән булса кирәк), «алайса, бигайбә» дигән сыман кулларын гына җәйде. Тарих фәне бары документларны, конкрет матди дәлилләрне генә санга суга. Алардан башка, нинди генә ышандыргыч тоелмасын, картның сүзләре мәгълүм легенданың мең дә беренче варианты гына булып кала. Өстәвенә, галим әйтүенә караганда, яшерелгән хәзинәләр турында легендаларның исәбе-хисабы юк икән. Безнең Казан гына легендар «хәзинәсез» калмас бит инде.

КИТАП ЯЗУНЫҢ СЕРЕ

Чынбарлык илһам бирде.
Югалтулар.
«Сасы театр».

Менә, укучым, синең алда Кабан күле турындагы китабым ята. Бәлки, газета-журналларда шул темага язылган мәкаләләремне дә искәргәнсеңдер. «Теге бабай салган оетты тәки үз эшен эшләгән»,— дисең инде син. Алай ук түгел шул. Дөресен генә әйткәндә, бу проблемага тотынырга мине кырыс чынбарлык мәҗбүр итте.

Мин яшәгән йорт — Париж Коммунасы урамында, Кабан күленнән аны нибары йөз метр чамасы ара аерып тора. Заманында моның рәхәт яклары да бар иде. Коеныйм, кызыныйм дисәң — рәхим ит. Гаиләбез белән көймәдә йөргән чаклар да аз булмады. Кышын чаңгыда йөрим дисәң дә Кабаннан да шәп урын юк. Бала-чага текә ярдан чана шуып та рәхәтләнә.

Еллар узу белән күл әлеге кызыктыргыч сыйфатларын бер-бер артлы җуя торды. Башта — су керүләр, аннары көймәдә йөрүләр тукталды. Яр буйлап җәяү йөрүнең дә кызыгы калмады. Промышленность предприятиеләреннән һәм шәһәр канализациясеннән агып төшкән пычрак сулар

белән агуланган күл кышын боз белән капланмый башлады — шуңа да чаңгы походларының да урыны үзгәрде. Хәер, югалтуларның зуррагы да озак көттермәде.

Көндәлек дәфтәремә мөрәҗәгать итик әле.

1976 ел, 27 апрель. Бүген иртәдән үк эш бармый. Баш чатный, тиктомалдан бөтен нәрсәгә ачу килә. Язган кәгазьгә — саргылт булганы өчен, каләмгә — карасы кипкәнгә. Бераздан алар бер-бер артлы чүп савытына очалар... Иң ошамаганы — язганнарым. Дөресрәге — язам дип интеккәнем. Югыйсә бүген кулъязманы тапшырасы көн. Өлгертмәсәм, күпме кешене кыен хәлдә калдырам. Әмма... бүлмәндә сасы йомырка исе килеп торгач — нишләмәк кирәк?.. Исенә күнегер дә идең аның. Башыма әйтерсең лә чуерташ тутырганнар — бер генә фикер юк. Ичмасам, тәрәзә ачарлык та түгел — ис үзе тыштан керә. Урамдагы халык, әнә, авыз-борынын томалап, бу урыннан җәһәт кенә үтеп китү җаен карый.

Ишек кагалар. Күршебез Тося түтәй икән. Телефоннан шалтыратырга дип керүе. Йөзенә сары иңгән, хәрәкәтләре сүлпән. Поликлиника номерын җыйган арада уртак бәлабез турында сөйләп, эчен бушата:

— Сездә ярый әле. Безнең якта бөтенләй чыдар әмәл юк. Ниткән эш инде бу? Гомер буена шушында яшәп, мондый хәлне күргән юк иде. Бүген төнлә үләм дип торам. Җил үзгәргән, күрәсең. Минем әле кан басымы да шаяра бит. Больницага булса да салсыннар иде, ходаем. Хәер, бу көннәрдә анда да чиратның иге-чиге юктыр.

Күрше апа чыккач, санэпидстанциягә шалтыраттым. Ягымлы тавыш түбәндәгеләрне аңлатып бирде. Боз эрегәч, күлдән күкертле водород бүленеп чыга башлаган. Ә ул — тын юлларына һәм нерв системасына тәэсир итә торган агулы газ. Аз микъдарда булганда, конъюнктивит, баш авырту, бронхит кебек чирләргә сәбәпче була, күбрәк булса, аңны җуярга мөмкин, плеврит, күзән җыеру, ис аву кебек авыруларга китерә.

1978 ел, 12 май. Хатыным ягыннан туган тиешле кешеләргә кунакка бардык. Кабан күле буенда үз өйләре белән яшиләр. Сүз дә, табигый ки, Кабан турында булды.

— Хәзер ярый әле,— ди Галимҗан абый.— Апрельдә — боз ачылгач ни күргәнне белсәң иде. Бәдрәфтә яшәгәннән ким булмады. Чыдар әмәл калмагач, малайларга китеп бардык. Тик аларның да шул үз хәлләре хәл: яшь бала белән, өчәүләп шырпы тартмасы хәтле бүлмәдә яшәп яталар...

Галимҗан абый — Ватан сугышы инвалиды. Контузия

ОПАСНО
ДЛЯ
ЖИЗНИ

алган кеше. Сасыган су исе аңа бик тә начар тәэсир итә, кайчак һушын да җуя икән... Фәһимә апаның да үз кайгысы: боз ачылыр алдыннан гына бәкедә улының эш киемен чайкаган,— икенче көнне ике кулы терсәк тиентен кыпкызыл булып чыккан. Бернинди дару да алмый, ди.

— Су түгел бу, агу,— ди Галимҗан абый.— Ун еллап элек санэпидстанция су коенуны тыйды. Яр буендагы «Сәламәтлек өчен куркынычлы!» дигән язулы такталарга малай-шалайның башта бер дә исе китмәгән иде. Аннан күрәләр: берсенең тәне чабырып чыккан, икенчесенең тиресе бозылган... Хәзер үзләрен суга куалап та кертеп булмый.

Галимҗан абыйның бөтен гомере Кабан күле буенда үткән. Яшь чакларын искә төшерә.

— Илле ел элекме? Балыкчы көймәләре бөтен күлне каплап алыр иде. Мин үзем дә менә мондый-мондый (кулларын җәеп) сазаннар каптыра идем. Шушында — өй янында гына!... Гармуннар уйнатып, утлар балкытып, егетләр, кызлар көймәләрдә төннәрен күңел ачалар иде. Шатлыклы авазлар ишетелеп тора иде. Суга мәтәлүчеләр дә була. Шифа гына!

Улым Равил дә кармак салгалый иде. Тик аңа сазаннар тәтемәде инде. Оныкларны менә судан ераграк тотарга тырышабыз. Хәер, үзләре дә бик атлыгып тормыйлар... Соңгы балык бер биш ел элек әләкте. Бака «концертлары» туктаганга да өч еллап. Бака бака инде ул, балык тотарга корт табам димә. Кара син ә! Сасы суда гына үрчи торган кортка кадәр үлеп беткән инде.

Галимҗан абый мине редиска утыртылган түтәлләрне карарга алып китте. Бер түтәлдә сусыл сабаклы редиска үсеп утыра. Икенчесенең сабаклары саргаеп-көеп беткән.

— Тәҗрибә үткәрәм әле менә. Фән өчен түгел, хатын өчен. Кайчагында колонкага барырга иренә. Фәһимә апа ачык тәрәзәдән төзәтмә кертә: «Иренмим лә, кулым авырта». Гомер-гомергә күл суы сибә идек, берни булмый иде, имеш. Менә нишләтә ул Кабан суы. Кислота сипкәннәрмени!

Каралып беткән көймә яныннан үткәндә абзый аның коргаксыган такталарына кагылып узды. Пөхтәлек белән төзекләндерелгән көймә гадәттә бу вакытта күптән суда булыр иде. Заманында бу көймәдә хатыным белән без дә аз йөрмәдек. Хәзер менә күз алдында череп ята.

Галимҗан абый өен сатып бүтән урынга күчеп утыру турында хыяллана инде. Җәл, әлбәттә. Ни дисәң дә, гомер иткән җир бит. Ике катлы иркен өй. Сарае, бакчасы, гара-

жы дисеңме. «Тик... кем генә килсен икән монда? Юләрләр юк бит хәзер».

1980 ел, 21 май. Кичә Татар академия театры төзелешенә сугылдым. Үле күл өстендәге зур кирпеч бинаны кабер ташына охшатасың. Төзелешнең үзендә дә бер генә җан иясен күрмәссең.

— Куркынычсызлык техникасы сәбәп моңа,— ди прораб В. Коротков.— Кранчыбыз күкертле водород белән агуланып, егылып төшә язгач, биектә эшләүне тыйдылар. Ике бригаданы бүтән участокка күчерергә туры килде. «Сасы театр» төзүдә эшлисе килми кешеләрнең. Төзелешне бөтенләй туктатмасыннар дип куркабыз менә.

Прораб тәмам кызды.

— Менә сез язучы инде. «Халык вөҗданы». Нигә дип дәшми йөрисез? Нигә чаң сукмыйсыз? Былтыр бу яр буйларын тазартуга миллион сум ярым акча тоттык. Алдагы елларда тагын дүрт миллионнан артык сарыф ителәчәк. Ленинградта да юк бит мондый яр буйлары! Тик... ни пычагыма бу? Сасы күл буена кем килсен ди!.. Аңлыйм инде, вакыт тимидер. Тик, шулай барыбыз да күл буеннан борын җыерып кына үтсәк, ни булыр?

КҮЛНЕҢ ҖАНЫ

«Бу төбәк шулкадәр дә ямьле вә уңдырышлы, балга, яшелчәгә дисеңме, ул киеккә, балыкка, адәм баласына кирәкле башка нәрсәләргә дисеңме — шулкадәр бай ки, андый ямьле, вә уңайлы урынны бөтен рус җиреннән таба алмассың, чит тарафларда да бар микән әле».

«Казан елъязмачысы» [1].

Эт күмгән җирдә корылган кала.
Монастырьның «балык биләмәләре».
Аккошлар булганмы?
Төньяк джунглилары.

Күл буенда басып торам.

Тонык соры су. Соры болганчык күк. ТЭЦ морҗаларыннан ургылып чыккан төтен белән аралашкан болытлар «Татарстан» кунакханәсе түбәсенә ышкылып үтә.

---

[1] «Казан елъязмачысы» — XVI гасыр уртасында, Казан ханлыгы Рус дәүләтенә кушылгач язылган «Казан тарихы» исемле әсәр авторының шартлы исеме. Аның турында шул гына мәгълүм: рус рухание булган, егерме ел буена, әле ханлык буйсындырылганчы ук, Казанда яшәгән, җирле халыкның телен, гореф-гадәтләрен яхшы белгән, хан сараена кереп йөри алган, хәтта мөселман диненә дә күчкән.

Яр буе буш — кемнең канализация агынтылары хуш, буен иснисе килсен ди. Баш очымда тузгыган каурыйлы ала каргалар каркылдый. Тавышлары шыгырдавык, ачулы — мин аларны ияләшкән җирләреннән куркытып җибәргәнмен булса кирәк. Ә урыны чыннан да «шәп»: төрле-төрле ташландык нәрсәләр, чүп-чар, ачып-күпереп яткан азык-төлек калдыклары. Бераз арырак, суны ярдан аерган сызыкка тияр-тимәс, иеп беткән эт үләксәсе ята.

«Қала салу өчен урын сайлаганда киңәш сорап сихерчегә килгәннәр, имеш, сихерче әйткән: җиргә күмгән казанның суы кайда утсыз кайнап чыкса, шәһәрне дә шунда салыгыз, дигән. Қала озын гомерле булсын өчен, шул урында беренче очраган адәмне дивар астына күмеп калдырырга кушкан.

Хан хезмәтчеләре мондый урынны бик озак эзләгәннәр. Бер урында казан суы чыннан да кайный башлаган. Шул урында шәһәр төзергә уйлаганнар. Дивар салырга керешкәндә беренче күргән кешеләре этисенең йомышы белән килгән хан углы була. Кызганалар, аның урынына эт үтереп күмәләр. Моны белгәч, хан сөекле улы өчен сөенгән, әлбәттә. Әмма әйткән: «Димәк, минем шәһәрем дә озак яшәмәс, этләр кулына калыр»,— дигән...»

Ала каргалар батырайды. Мине санга сукмыйча, инде аяк очымда ук арлы-бирле йөренәләр. Эт үләксәсе янындагы чүпрәк-чапрак өеме тирәсеннән кыштырдау, чинаучыелдау авазлары ишетелеп куя, анда ниндидер хәрәкәт бар кебек. Дикъкатьләбрәк карасам — күселәр. Симезләр. Мыеклы, очлы танаучыкларын минем тарафка төбәгәннәр, сәйлән кебек кенә бәләкәй, салкын күзләре усал елтырый.

Яңа театр бинасы яныннан узам. Әле кайчан гына монда уйсу, сазламык җир булган. XIX гасыр азагынача, шәһәрнең беренче электр станциясе төзелгәнгә кадәр, бу тирәне «Мүкле саз» («Моховое болото») дип йөрткәннәр.

Менә шуларны искә төшергәч мин үзенә күрә бер ачыш ясадым. Қорылык елларында, сазлыклар кипкәч, торф үзеннән-үзе кабына алган бит. Урман төпләп-яндырып, ышна ачып иген иккәндә, ботак-сатак, агач төпләре әледән-әле яндырылып торганда мондый хәлләр аз булмагандыр. Су үзеннән-үзе кайнап чыга торган хикмәтле казанның серe ләбаса бу!

Инде эт күмүгә килсәк, монысында гайре табигый нәрсә бөтенләй дә юк: Қазан каласы җиде-сигез гасыр элек — корбанга кеше чалу гадәте бетеп барган чакта төзелгән.

Хәер, легендаларга гадәттә берничә мәгънә салынган

була. Монысына да бүген бөтенләй башка яктан карап була.

Кеше шәһәр нигезенә эт үтереп салган... Галимнәр уйлавынча, эт — хайваннардан кеше тарафыннан иң беренче булып кулга ияләштерелгән җан иясе. Беренчесе һәм иң турылыклысы да. Кешенең иң якын дусты.... Табигать хәзер бу борынгы хыянәтебез өчен үч алмый микән? Борынгы гына булса бер хәер әле.

...Кул буенда басып торам.

Баш очымда җете зәңгәр күк гөмбәзе. Каршымда чиксез-кырыйсыз су. Кул сафлыгын, саз үләннәренең төче буын сеңдергән тыгыз җил җылы вак дулкыннар куа. Салмак кына әйләнеп, кул өстеннән тилгән очып йөри. Кояш шәүләләре суда аллы-гөлле тасмалар булып балкып китәләр. Яр сызыгы буйлап симез энә каракклары куышып оча. Өзми-куймый черки безелди. Яр буенда яшел дивар булып калкып торган әрәмәлекләр һәртөрле кош авазлары белән тулы. Бераз гына колак салып торсаң, тартар кычкыруын да, урман күгәрчене гөрләвен дә, чуллыкның сарык бәэлдәвенә охшаш өзек-өзек җырын да аерасың.

Һаваны сызгыртып ярып, бер көтү кыр үрдәге очып уза. Алар кул камышы, җикән камыш һәм күрән сарган сайлыкка төшеп утыра. Шундук эшкә дә керешәләр: озын муеннарын суга тыгып, тәпиләре белән ярдәм итеп, томшыклары белән ләм сөзә башлыйлар. Кояшта елкылдап торган яшел муенлы матур зур ата үрдәк, кайгыртучан бакылдап, тирәләп йөзеп йөри. Менә ул хәбәр салды, көтү шундук һавага күтәрелде. Бераздан мин камыш арасында җирән-сары төлке койрыгын күреп алам.

Чип-чиста яшькелт суда агым тирбәтеп-селкетеп торган суүсемнәр арасында эре балыклар ялкау гына йөзеп йөргәне күренеп тора. Менә бер урында кинәт борчак сипкәндәй булды — йөзләрчә маймыч, көмеш җилпәвеч хасил итеп, төрлесе төрле якка атылды: чуртан ауга чыккан, күрәсең...

Тукта! Хыялның да чиге була микән?..

Бу төбәк табигатенең кул тимәгән матурлыгы һәм байлыгы турында сөйләгән күп кенә таныкламалар безнең замангача килеп җиткән.

Казан каласын салу турындагы риваятьләрнең менә монысында да сихерчедән киңәш сорыйлар. Ул исә болай ди: «Кармак салгалап елга буйлап барыгыз. Кайда алтын чабак эләксә: шунда шәһәр корыгыз...» Алтын чабак хәзер Кремль торган үр янында каба.

Алтын чабакны кулдә күп булган бик тә тәмле балык

дип тә аңларга була: Кабан күлләре тезмәсен Казан суы белән тоташтырган Болак Казан елгасына нәкъ менә Кремль тавы янында коя бит. Риваятьне күчерелмә мәгънәдә дә, туры мәгънәсендә дә аңларга мөмкин. Хәзер аквариумнарда йөзә торган алтын балыкның нәселе гап-гади кәрәкәгә барып тоташа ләбаса! Күлләрдә әле хәзер дә тач кызылсу алтын төсендәге балыклар очраштыргалый. Миңа калса, риваятьнең асыл мәгънәсе шуннан гыйбарәт: кала салганда күлнең балыкка бай булуы да искә алынган.

Казан ханлыгы буйсындырылгач ук диярлек төзелгән сан алу кенәгәләрендә («Писцовые книги») Кабан күлендә корбан балык, сазан, чуртан, судак, мәрсин балыгы, кырпы кебек иң һәйбәт балыклар тотылуы әйтелә. (Кызыл балык күлгә язгы ташу вакытында Иделдән керә.) Кышын балыкны Мәскәүгә тундырып, җәй көнне тозланган, кипкән, какланган-ысланган килеш тә йөге-йөге белән озатып торганнар. Уылдыкны, балык бавырын мичкә-мичкә сатарга алып киткәннәр.

«Казан суы белән Кабан күлләр арасында 750 дисәтинә болын бар,— диелә шул кенәгәләрдә.— Воевода, бояр балалары, стрелец йөзбашлары, дьяклар һәм подьячийлар моннан 21 240 чүмәлә печән чабып ала. Кабан аръягында, Кече Утар авылы янында, Еналиев болыны бар, анысыннан 2100 чүмәлә чабалар».

Ханлык буйсындырылып күп тә үтми, Урта Кабан буенда Яңа Иерусалим монастыре (соңрак Воскресенский) салына. Күлләр монастырьның балык биләмәсе дип игълан ителә, балык сату исә монастырь керемнәренең төп өлешен тәшкил итә башлый. Монахлар балыкны Казан халкына сатып кына калмый (Рыбнорядский урамында монастырьның махсус балык кибетләре була), тозлы һәм какланган балык белән бөтен Казан губернасын тәэмин итеп торалар.

Хәер, бу ганимәт XIX гасыр башына «кадәр генә» җитә. Шуннан соң төп табыш чыганагын җуйган монастырьның эшләре түбән тәгәри башлый, тиздән ул ябыла.

...Кичке шәфәкъ офыкны һәм төньяк ярдагы биек наратларны алтын төскә манды. Тирә-як төн үткәрү урыннарына юнәлгән меңләгән кыр казлары, торналар, челәннәрнең сузынкы авазлары белән тулды. Яшел яр борылмасыннан күл уртасына патшаларча мәгърур бер пар аккош йөзеп чыкты...

(Скептикларга махсус аңлатма. Аккошларның элек Казан тирәсендә яшәгәнлекләре мәгълүм. Аккош күленең исеме дә шул заманнардан килә. Аккошларның Кабанда

дөнья көткән булу ихтималы да зур, ярда шау-шулы олы шәһәр барлыкка килү генә аларны яшәү урыннарын алыштырырга мәҗбүр иткәндер.)

...Зирек куаклыгында көчле чытырдау, авыр мышнау һәм түземсезләнеп мыркылдау авазлары ишетелә: кабан дуңгызлары су эчәргә төшеп бара. Алар белән очрашмавың хәерле.

Монда тагын бер аңлатма урынлы булыр. Каюм Насыйри язып алган риваятьләргә караганда, Кабан күле буендагы урман һәм әрәмәлекләр сарган юеш аймакларда заманында исәпсез-хисапсыз кабан дуңгызы йөргән. Алар, игеннәрне, түтәлләрне таптап, казып, кешеләргә күп зыян салганнар. Шундый да зур һәм явыз булганнар ки — хәтта алыплар да күл буена ялгызлары гына төшәргә җөрьәт итмәгән. Сан алу кенәгәләрендә дә Кабан күлләре тирәсенең кабан дуңгызы, аю, поши, селәүсен, төлке, бүре, куян кебек җәнлекләр белән мыжгып торганлыгы әйтелә. Кондыз «хуҗалыклары» да, чолыклар да күп була. Күлләр тирәсе тикмәгә генә ханның аучылык урыны булып саналмаган.

Әлеге таныкламаларның дөреслеген геологик тикшеренүләр дә раслыйлар. Күлләрне әрәмәләр — юеш, үтеп йөргесез таллыклар, зирек куаклыклары, камышлыклар,— чыпчын төньяк джунглие уратып алган булган. Кабан дуңгызлары өчен җәннәт инде. Каюм Насыйри язуынча, Татар бистәсендә башлап яшәүчеләргә балта белән юл ачарга туры килгән. Хәтта җәйге чилләдә дә монда куе күләгә хакимлек иткән, аяк астында саз суы чапылдаган. Бер яктан язын су баса торган болыннар, икенче яктан нарат урманлы сөзәк тау битләре белән чикләшкән әрәмәлек уннарча чакрымга сузылган.

КАСЫЙМ ШӘЕХ БИШМӘТЕ

(Килеп чыгу табышмагы)

Риваять ни әйтә?
Галимнәр фикере.
Мондый тирәнлек каян килгән?
Шайтан почмагы.
Сулар кирегә акканда.
Җавапсыз калган сораулар.

Казан су киңлекләренә бик тә бай. Баһадир Идел безнең янда чын бер диңгез — данлы Куйбышев сусаклагычын хасил итә. Идел суы терәп-этеп торган Казан елгасы

да үзенә күрә бер диңгез булып җәелгән. Монысының суы алай мул түгел түгелен, аның каравы, шәһәр эчендә Кабан да шәһәр сызыгына керә. Казан халкы дөньядагы шундый зур эчке сулыкка ия дүрт шәһәрнең берсендә яшәве белән мактанырга ярата. Федор Иванович Шаляпинның Кабанны дөньяда иң матур күл санавын, аның хәтта данлы Женева күленнән алда торуын да искәртергә онытмыйлар.

Кабан системасы өч күлдән тора: Түбән (яки Якын) Кабан, Урта Кабан һәм Югары Кабан.

Әйдәгез Г. Камал исемендәге театр яныннан кузгалып, көймәдә үзенә күрә бер сәяхәткә чыгыйк.

Кузгалып китүгә иркенлеккә җитәсең, монда киңлек 320 метрлап. Уртага җитәрәк күл 180 метрга кадәр тарая, соңрак 120 метрга кала. Ишеп барсаң, күнекмәгән килеш тирләп-пешеп чыгасың — Якын Кабанның озынлыгы ике чакрымлап (турыга — 1850 метр).

Вахитов күперен узгач, ике яктан автомобиль һәм тимер юл дамбалары белән чикләнгән сай гына бугазга килеп керәбез. Сулда Ботаник бакча кала (халык телендә— Ботан бакчасы). Кайберәүләр аны, белмичә, «Урта Кабан» дип йөриләр. Бугазның озынлыгы — 750, киңлеге йөздән алып ике йөз метрга кадәр.

Суны беркадәр күтәрә төшкән Куйбышев сусаклагычы төзелгәнгә кадәр бугаз күпкә таррак булган. Гасыр башында бугаз Урта Кабанга бераз төньяктарак тоташкан булган. Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан тимер юл дамбасы салына, шул чакта дамбада махсус су юлы ясап калдыралар, бугазның үзен турайталар. Бораулап карагач, бугазның элекке, табигый эзендә 10—11 метр калынлыкта торф һәм ләм ятуы беленә. Димәк, бугаз кайчандыр шактый тирән булган (хәзер аның уртача тирәнлеге ике метрдан артмый), ике күлнең үзара су алмашуы да көчлерәк булган.

Тимер юл күпере астыннан йөзеп үткәч, системаның иң зур күле булган Урта Кабанга килеп керәбез. Кайберәүләр аны Ерак Кабан дип тә йөртә. Монда ярлар аз-азлап читенә: киңлек 170, 320 метрга һәм, ниһаять, 580 метрга җитә. Җылылык энергоүзәге коймасы яныннан, аннары өч предприятиенең кайнар сулары агып төшә торган ясалма канал яныннан йөзеп үтәбез. Бу тирәдә күл өсте иң салкын көннәрдә дә боз белән капланмый... Сул кул якта күмәк бакчалар кала. Иң биек урында — элеккеге Архиерей дачасының ак ташлы корылмалары (без монда җәяүләп әйләнеп кайтырбыз). Ишәсе дә ишәсе эле — күл өч чакрым-

нан артык (3300 метр) сузыла. Уңда, күлнең аргы башынд түгәрәкләнеп килгән бәләкәй култык («Шайтан почмагы» дигәннәре шул инде) хасил иткән текә яр күренә. Ул т рыда киңлеге 10—12, тирәнлеге 1,5—2 метр булган М настырь бугазы башлана. Риваятьләргә караганда, ан монахлар үзләре казыган.

Урыны-урыны белән ишеп яисә колга белән этеп бар ике чакрымлап юл үткәч, күлләр тезмәсен Куйбышев с саклагычыннан аерып торган саклагыч дамбага килеп т рәләбез. Сунын артыгын сусаклагычка суырта торган н сос станциясе шушында урнашкан. Насослар эшләвен Ур Кабаннан дамбага таба хасил булган көчле агымнан ч малап була.

Ярты чакрымлап кире кайтып, йөз илле метр чама җәяү үтик әле. Күзне сөендереп, тагын бер киң сулык ач ла. Бусы — Югары яки Борисково Кабаны. Озынлыгы бер чакрым чамасы (930 метр), киңлеге өч йөз метрл Күл өстән, каршы яктагы текә ярдан караганда, кав формасында дияргә була.

Югары Кабан калган ике күл белән тоташмый. Та гатьнең бу «хатасын» төзәтер өчен Яңа Иерусалим м настыре монахлары без әле генә йөзеп килгән канал-буг ны казыганнар. Әмма, Югары Кабанның суы кимендә б саженьга биегрәк икәнлеген аңлагач, экологик тигезле бозарга базмаганнар.

Якын Кабанның өслеге 56 гектар булса, Урта Каб ныкы нәкъ ике мәртәбә зуррак — 112 гектар, Югары ныкы исә — 25 гектар... Тулаем алганда, каналлар һ бугазларны да кертеп, ике йөз гектардан да арта.

Кабан системасына кергән күлләр белән беркадәр нышкач, шундый сорау туыы мөмкин: бу күлләр кайч барлыкка килгән соң?

Каюм Насыйри бер борынгы риваять китерә. Бу ларга беренче кешеләрне күп-күп еллар элек «Касы шәех» дигән изге карт алып килгән, имеш. Тирә-якта ба камышлы сазлыклар, ерып йөргесез әрәмәләр, чытырма лыклар булган. Син безне сусыз җиргә, чебен-черки а сына алып килдең, дип, халык сукрана башлаган. Шу изге карт, бишмәтен җәеп, дога кылган, аннан бишмә сөйрәп киткән. Бишмәт тиеп үткән җирдә саф һәм сихә сулы бер күл хасил булган, имеш.

Өстән карасаң, Якын Кабан чыннан да ике җиңе җи җәелгән бишмәтне хәтерләтә. Бу риваятьтә күлгә мил ядкар, халкыбызның мөкатдәс байлыгы итеп карау зелә.

Билгесез авторның XVII йөздә язылган «Дәфтәри Чыңгызнамә» дигән әсәрендә (кайбер галимнәр уйлавынча, анда безгә килеп җитмәгән борынгырак татар елъязмаларындагы мәгълүматлар да чагылыш тапкан) хәзер шәһәр булган җирдән Әтил суы аккан,— диелә.— Соңрак, ул көнбатышка чигенгәч кенә, монда кешеләр килеп утырган.

Нәрсә бу, даһи фаразмы әллә күзәтүчәнлек нәтиҗәсеме? Галимнәр сүзенә колак салыйк әле.

Кабан күлләре системасына җитмештән артык фәнни хезмәт, берничә монография багышланган, бу темага ике кандидатлык диссертациясе якланган.

Кабан турындагы беренче хезмәтләрдә үк күлләр тезмәсенең Идел белән һичшиксез бәйле булуы турындагы фикер әйтелә. Күлләр тугайдан өстәрәк икенче террасада, ягъни борынгы Идел үзәнендә урнашкан. Галимнәрнең күпчелеге чыннан да Кабанны Иделнең борынгы юлы дип саный. Күлләрнең җиңелчә бормаланган сузынкы формасы да, төпнең елга үзәнен хәтерләткән кисеме дә шушы фикерне куәтли. Галимнәр уйлавынча, Идел бу юлдан 30—40 мең еллар элек, бозлыклар бик нык эрегән чорда аккан. Ул чакта елга әлегедән 15—20 мәртәбә киңрәк һәм мулрак сулы булган. Соңыннан Идел үзенә, берничә чакрым көнбатышкарак, бүтән юл яра. Әгәр бу чыннан да шулай икән, Кабан системасының яше 25—30 мең еллап булырга тиеш.

Идел үзе юлын үзгәртсә дә, аның элекке үзәнендә сулы горизонтлар сакланып калган. Кабан суы нык пычрангач, аның тирәсендәге промышленность предприятиеләре бер-бер артлы артезиан коеларыннан файдалануга күчә башладылар. Эзләп интегәсе дә юк: борау тишкән һәр җирдән тирән катламнар сөзгән саф, салкын чишмә суы бәреп чыга. Үзе тагын — «Иясез мал», кайбер хуҗалык әһелләре уйлавынча, иксез-чиксез дә.

Соңгы елларда уздырылган тикшеренүләр күлләрнең үткәненә тагын беркадәр ачыклык өсти. Әйтик, 1957 елда Кабан ярларын борулаган «Гипрокоммунтранс» белгечләре мәгълүматларына караганда, берничә мең ел элек күл ким дигәндә ике тапкыр зуррак булган. Якын Кабанның төньяк-көнчыгыш яр сызыгы Куйбышев мәйданыннан да арырак, аннан Свердлов урамы артындагы элекке биек яр буйлап Суворов тыкрыгынача һәм, калкулыклар тезмәсе буйлап, Борисковога кадәр сузылган. Суконный бистәсе, хәзерге Һади Такташ урамы кебек урыннарда аерым утраулар калкып торган. Шулай итеп, күлнең элекке чикләре

тулысынча диярлек борынгы Иделнең яр сызыгына тур
килә.

Күл буйлары аз-азлап камышлыклар, таллыклар, төр
ледән-төрле яшеллек белән каплана, кысыла бара. Мон
якын-тирәдәге калкулыклардан тау токымнарының юылы
төшүе дә ярдәм итә (таулардагы агач киселеп беткәч, б
процесс бигрәк тә көчәя). Архангельск зираты тирәсе, мә
сәлән, кайчандыр бер тоташ күлнең уртасында була. Мең
ләгән еллар буенча үсә барган торф катламы биредә биш
метрдан да артып китә. Аның өстенә балчыклы токымна
утыра.

Су өслегенең кимүе әлегәчә дәвам итә, әмма хәзер ин
де — яшеллек һөҗүм итү сәбәпле түгел, бәлки кешене
максатчан эшчәнлеге нәтиҗәсендә. Сайлыклар, тирән бул
маган култык-бугазлар күмелә, яр бормалары тигезлән
бара. Яр буйларында ике метрдан алып сигез метрга ка
дәр калынлыкта туфрак тупланган инде. Соңгы ун ел эчен
дә генә дә Якын Кабанның мәйданы берничә гектарга
озынлыгы 50 метрга кимеде. (Башлыча, театр һәм ныгы
тылган яр буе төзү нәтиҗәсендә.)

Җылылык энергоүзәгенең юшкын чүплеге урта Кабан
ның ун гектар чамасын, башка чүплекләр тагын берничә
гектарын тартып алды. Күлгә һөҗүм дәвам итә...

Әмма инде барлык галимнәр тарафыннан да диярле
танылган әлеге фаразга туры килеп бетмәгән нәрсәлә
бар.

Аларның берсе күлнең бик тә тирән булуыннан гый
барәт.

Баһадир елгабыз үз юлында «чәчрәтеп» калдырган ту
гай һәм үзән күлләренең тирәнлеге гадәттә нибары өч-дүр
метр була, ара-тирә генә, анда да бары иң тирән җиренд
генә биш-алты метрга җиткәннәре очрый. Ун метрлы ти
рәнлек исә — бөтенләй сирәк күренеш. Ә менә Урта Ка
банның үзәк өлешендәге чоңгылның тирәнлеге 1902 елда
үлчәгәндә 31,3 метр тәшкил иткән! 1976 елда бу күрсәт
кеч 24 метрга калган, 1986 елга исә егерме метрдан д
кимегән. Ләм утыру тизлеген күрсәтә торган гыйбрәтл
саннар бу.

Якын Кабандагы иң тирән урын 1902 елда — 16,5,
1976 елда 15,5 метр булган. Бу турыда боздан торып бо
раулаганда күлнең табигый төбеннән шул чактагы төпк
кадәрге 15 метрлы ләм катламы алынган. 1986 елга у
тирәдәге тирәнлек 12 метрга калган, ләм катламы ис
18 метрга җиткән. Әгәр күлнең табигый төбенә хәзерге ту
гыз катлы йортны утыртсаң, ул түбәсе тиентен күмелер иде

Күлнең чын төбе Куйбышев сусаклагычы төбеннән унбиш метрга диярлек түбәнрәк. Ничек болай була алган соң бу? Әшсөяр Иделебез юкса үзенең яңа юлын меңнәрчә ел буенча казып-тирәнәйтеп торган лабаса!

Моны бары карст процесслары, ягъни җир асты горизонтларында су йөрү үзенчәлекләре китереп чыгарган күл төбе юылу һәм җирнең убылып торуына бәйләп кенә аңлатып була.

Бораулау чыннан да юка гына ком һәм кызыл балчык катламыннан соң тиз юыла-ашала торган токымнар: көпшәк утырмалар белән аралашкан известьташ һәм гипс ятуын күрсәтте.

Мондый юл белән хасил булган күлләр Казан тирәсендә аз түгел. Әйтик, һәркайсыбыз белә торган Зур Тирән күл, Кече Тирән күл, Зәңгәр күл. Алар барысы да тирән, салкын һәм чиста сулы булулары (пычратылмаганда, әлбәттә) һәм бүрәнкә сыман чоңгыллары белән Кабан күленә охшашлар.

Кабанда ашалу-юылу процесслары әле хәзер дә дәвам итә. Менә моны раслаучы бер тарихи факт.

Урта Кабанның куе катнаш урманлы гаҗәп матур яр буйлары шушы гасырның егерменче-утызынчы елларына кадәр шәһәр халкының иң яраткан ял итү урыны булган. Ни гаҗәп, адәм кулы тимәгән бу кыргый, саф матурлыкны үз күзләре белән күргән кешеләр дә исән әле. Үткән гасырда биредә рестораннары, бильярд бүлмәләре, берсеннән-берсе матуррак беседкалары булган «Аркадия» паркы төзелә. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, монда ял итүчеләр кими. Аның каравы, армиягә товар сатып баеган һәртөрле эшмәкәрләр тагын да җиллерәк итеп кәеф-сафа коралар. Биредә, хезмәт кешесенең нәфрәтле күз карашыннан читтә, алар җилдән килгән акчаларын эчеп, картага оттырып, «сылу»лар куенында назланып тотып бетерәләр.

Һәм менә көннәрнең берендә әлеге «бозыкханә»ләр торган Шайтан почмагының текә ярлары ишелә башлый. Чатыр-чотыр килеп беседкалар янтая һәм суга авып төшә, павильоннар, челтәрле нәфис корылмалар иңә, җимерелә, пыран-заран килә. «Ходай орды»,— ди халык...

Сүз уңаеннан, нигә «Шайтан почмагы» әле? Бу атамага карата ике версия бар. Берсе күлнең бу тирәсенә хас табигый үзенчәлекләргә бәйле. Текә, бүрәнкәсыман яр, хәтәр чоңгыллар хасил итеп, ун-унике метр тирәнлеккә төшеп китә. Чын-чынлап шайтан почмагы инде! Икенче вер-

сия исә үтә гади: революциягә кадәр монда алпавыт Чертов утары булган...

Шулай да, карст теориясе алдарак бәян ителгән карашларга каршы килми, ә бәлки аларны аныклый, тулыландыра гына кебек. Күпчелек географлар бу ике фаразны берләштерәләр. Кабанны үзен — карст күлләре исәбенә кертәләр.

Әмма... бу, инде киңәйтелгән гөманга да сыймый торган бер факт бар әле. Хәер, башта шул ук күлләр системасына кергән Болакка хас үзенчәлекләрне карап үтик.

«Болак — Кабанны Казан суы һәм, аның аша, Идел белән тоташтыру өчен казылган канал ул»,— дигән фикер киң таралган. Болакның җеп белән сызган кебек туптуры һәм махсус авыш итеп тигезләнгән ярлы булуы шушы фаразга су коя. Тарихи чыганаклар да шуны күрсәтә.

1883 елда Казанда нәшер ителгән «Тәварихе Болгария» дигән китапта татар тарихчысы Мөхәммәтзариф Хөсәен углы тарафыннан язып алынган борынгы риваять тә китерелә. Анда шул да әйтеп үтелә: Габделлатыйф хан заманында (Казан белән 1497—1502 елларда идардә итә) ташу шулкадәр көчле була ки, Кабан, ярдан чыгып, халыкка күп бәла-каза китерә. Күл Идел суы белән тоташа. Ул чакта Болакның казылмаган, сай үзәне генә була әле. Габделлатыйф хан казытып, Болакның бер башын Кабанга, икенче очын Казан суына тоташтырта. Шуннан соң шәһәрнең Болак башындагы ягы «югары як» дип Болак тамагындагы очы исә «түбән як» дип йөртелә башлый.

Әлеге факт рус елъязмаларында да чагылыш тапкан. Алардан күренгәнчә, канал 1499—1501 елларда казылган аннан бу эш 1530 елда дәвам иттерелгән. Озынлыгы — ике чакрым чамасы, өске киңлеге — 60, су өсте турында 25—30 метр булган каналны казып чыгу өчен меңләгән куб метр җир алырга кирәк булган. Чыганакларда ун мең нугай һәм «күп меңләгән чирмеш»нең канал казуда катнашу телгә алына. Шулай да, шундый зур каналны бу арада казып бетереп булмас иде,— тарихчы Н. Ф. Калинин әнә шундый фикердә торган. Канал урынында элек озынча күл — үзенә күрә бер кече Кабан булган, дип саный ул. Кайбер хәзерге белгечләр дә шулайрак уйлый.

Әмма риваятьләрдә бәләкәй елга турында әйтелә бит. «Болак» үзе дә төрки телләрдә «елгачык» дигән сүз. Мәсәлән, Раифа урманчылыгында Казаннан егерме биш чакрымда тына Сер-Болак елгасы бар. «Болак» атамасы башка җирләрдә дә очрый.

Соңгы елларда үткәрелгән геологик һәм гидрологик тикшеренүләр канал казылганга кадәр ул урында кыска, ләкин шактый мул сулы елга акканлыгын бәхәскә урын калмаслык итеп раслады. Аның киңлеге 60—70 метр, тирәнлеге урта тирәдә 6,5 метр булган (монысы ләм катламыннан беленә). Якын Кабаннан су алган елга тармакланып Казан суына койган. XVI гасыр башында аның ике тармагы булган, Черек Болак дигәне Кремль үре янынннан ук агып үткән. Зур Болак дигән икенче култык хәзерге цирк урыныннан аккан. Бораулау нәтиҗәсендә Болакның 300—400 метр чамасы киңлектәге ачык беленеп торган үзәнендә камышлыклар, таллыклар каплаган сазлыклы киң дельтасы булганлыгы ачыклана. Риваятьләрдә, дошман сиздермичә генә килеп җитә алмасын өчен, бу камышлык-таллыкларның әледән-әле чабылып-яндырылып торганлыгы әйтелә.

Кайбер риваятьләрдә исә Болак төбендә, яр буйларында чишмәләр күп булуы искәртелә. Шуңа да аның йомшак һәм саф суын эчәргә тоталар. Хан табынына да куела торган, бик тә уңган-кабарган калачлар өчен камырны нәкъ шушы суда изәләр.

Болакның мул сулы булуы күлләр системасының су җыю мәйданы зур булу (йөз квадрат километрдан артык) белән аңлатыла. Кабан күлләре тирәсендә кыргый урманнар шаулап торганда күлләргә һәр тарафтан исәпсез-сансыз чишмәләр, инеш-елгалар койган. Әйтик, XVI гасыр уртасында хәзерге Пушкин һәм Куйбышев урамнары булган җирдәге ерымнан шактый ук мул сулы инеш аккан. Куйбышев мәйданы булган җирдә ул Гүзәй күленә кергән, аннан, хәзерге Тукай бакчасы булган урындагы сазлык буйлап боргаланып ага торгач, Болак башланган җирдәрәк Кабанга килеп койган. Тагын да зуррак икенче агым, Әмәт тавындагы күлдән агып чыгып, Кабанга «Спартак» берләшмәсе тирәсендә тоташкан.

Чишмәле Түбән күлдән агып чыккан бер инеш, икенче яктан килеп, турыдан-туры Болакка коя. Сүз уңаеннан, җитмешенче еллар азагында күптән онытылып беткән күл урынында магистраль җылылык үткәргече салдылар. Күрәсең, сулы катламга да кагылганнардыр, трасса гел су белән тула. Трассага тоташтырылган йортларның идән асларын су баса, торбалар тутыга, җылылык күпләп әрәм була. Судан котылу әмәле берничек тә табылмый. Үткән белән исәпләшмәүнең бер гыйбрәтле мисалы бу!

Болакның төп үзенчәлеге — агышын үзгәртә торган сирәк елгаларның берсе ул. Болак үзенең бу сәер гадәтен

канал казылгач та — безнең гасырның илленче елларын кадәр саклап калган.

Ел әйләнәсендә Болак, тиеш булганча, Кабанның Казан елгасына таба ага (урам исемнәре дә шуны ук сөйли «Уң Болак урамы», «Сул Болак урамы»). Ә менә язгы ташу вакытында Казан елгасының һәм Иделнең суы Кабан суыннан ныграк күтәрелә торган булган. Мондый чакта Болак нишләгәнме? Бераз гына аптырап туктап торгач кирегә сыптырган.

Бу хәл су өсте биеклекләренең төрлелегеннән килеп чыга. Куйбышев сусаклагычы төзелгәнгә кадәр Якын Кабан яссылыгы диңгез өсте биеклегеннән 49,5 метрга, Ерак Кабанныкы исә 52,5 метрга артыграк булган. Кыш азагын су тагын берничә метрга кими. Ташу вакытында исә Идел суының биеклеге 56 метрга җитә. Менә шуңа су Болакка ыргыла, аны тутыра да, бөтерчекләр хасил итеп, ярсулы шарлама булып Кабанга сикереп төшә. 4—5 атна буен дәвам итә бу хәл. Июнь урталарында Болак яңадан «акылга утыра».

Кайбер елларда исә Болак үзенең агышын берничә тапкыр үзгәрткән. Башта — Казан елгасы ташыгач. Аның суы кайту белән Болак та элеккечә ага башлый. Аннан бер-ике атна үтүгә, Идел ташый, Казан елгасының су[ы] яңадан күтәрелә — бар да яңабаштан кабатлана.

Идел суы белән мөлдерәмә тулган Кабан ярыннан та[шып] чыга, күлнең суы яңарып, сафланып ала. Ташу көчл[е] булган елларда күлләрнең суы икешәр, хәтта өчәр тапкы[р] алышына. Арткан су Урта Кабанга, аннан исә ике буга[з] аша Иделгә чыга. Югары Кабан бу күлләр белән тоташ[ма]маган, әмма ул да, Дәүләкәй чокырыннан аккан кар су[ы] тулып ташый, арткан су бугаз аша Иделгә күчә. Шулай ите[п] өч күлдә дә елга бер мәртәбә агым барлыкка килә. Б[у] исә үсемлек һәм хайваннар дөньясы өчен менә дигә[н] шартлар тудыра. Кабанның әкияти балык хәзинәләре баш[]лыча нәкъ менә шуннан. Суның әледән-әле чистарыну[ы] күлне кешенең хуҗалык эшчәнлеге тәэсиреннән дә ко[]карып килгән. Әмма мондый хәл илленче еллар уртала[]рына кадәр генә дәвам итә шул.

Башта әйтелгәнгә әйләнеп кайтыйк әле: шулай да, Бо[]лак нигә көньяктан төньякка аккан соң? Беренче карашка җавап гап-гади кебек: күлләрнең үзәне Казан суына таб[а] авыш булганга. Әмма Идел бит капма-каршы юнәлештә ага. Һәм, әгәр дә Кабан Иделнең иске юлы икән, киресенчә бу[]лыр иде. Югары Кабан калган икесеннән түбәнрәк тор[]

иде (димәк, ул Түбән Кабан була), су, күлләрнең көньяк чигеннән агып чыгып, көньякка агар иде.

Бу хикмәтне ни дип аңларга соң? Елга үзәне үзенең авышлыгын үзгәртә аламы? Әллә күлләр системасы барлыкка килүнең бөтенләй башка төрле аңлатмасын эзләргә кирәкме?

Бәлкем, җавап менә бу сәер хәлгә бәйледер: тыныч кына көнбатыштан көнчыгышка агып яткан Идел, Казанга җиткәч, ниндидер диварга килеп бәрелгәндәй, көньякка текә борылыш ясый. Мондый дивар Казан елгасы һәм аның кушылдыкларының борынгы үзәнендә су һәм казылма материалларның мул чыгып торуы була ала. Бәлкем, күл үзәненең авышлыгын дә нәкъ менә шушы хәл үзгәрткәндер? «Елгалар падишаһы»ның бу «маневры»на буш вакытта рифма белән шаяргалаган бөек математик Н. И. Лобачевский да игътибар иткән булган.

И падишаһ елга, борыласың,
Тыя төшеп мәгърур агым көчең,
Татар калаларының карт анасы —
Казан белән очрашыр өчен.
Чын дус күреп аны, кочасың син
Бистәләрен, тугай-болыннарын.
Бүләкләрең тезеп тып-тын гына,
Сәламлисең син чал Болак ярын...

КҮҢЕЛСЕЗ СӘЯХӘТ

Кабан — Казанның моңлы бер күзе...
Равил Фәйзуллин

Күрсәтмә шундый булгач.
Сумы, әллә агумы?
Кабанны иң нык пычратучы.
72 миллион куб метр шакшы су.
Табигатьне алдый алмыйсың.

Бу эшкә рөхсәт алу җиңелдән булмады. Дөрес, берәү дә: «Ярамый!», «Мин каршы!» дип сөрән салмады, киресенчә, бар да биш куллап риза кебек иде. Тик менә көне килеп җиткәч кенә... Берсенең вакыты юк, икенчесе командировкада, өченчесе стажировкада булып чыкты. Азмыни ул санэпидстанция хезмәткәрләренең эш-мәшәкатьләре! Тегендә дә, монда да чакырып кына торалар, планлы һәм планнан тыш тикшерүләр, объект кабул итүләр, киңәшмәләр дисеңме... Бер тапкыр инде, ниһаять, җыелышып беттек дигәндә, моторчы килмәде...

Менә бу юлы да тәмам көйләнгән эш шул моторчы ар-
касында тагын өзелә язды. Инде кузгалабыз дигәндә генә:
«Бензин юк»,— дип әйтмәсенме! Ай ахыры, лимит беткән,
имеш. Санэпидстанциянең баш врачы да, хәтта райбаш-
карма комитеты председателе урынбасары да берничек яр-
дәм итә алмады. Әмма, тормышта булгалаганча, бу юлы
да четерекле мәсьәлә иң гади ысул белән хәл ителде.
Баш врач, киләсе ай исәбенә лимит даулап, югары ин-
станцияләргә шалтыратып маташкан арада мин моторчы-
га бер бишлек «төрттем».

Шундук табылды бензин.

Менә без көймәдә Кабан буенча йөзәбез. Без дигәнем —
шәһәр һәм район санэпидстанцияләреннән ике санитар врач,
гидрохимик лаборатория инженеры, лаборант кыз һәм без
фәкыйрегез. Рейдта катнашучыларның исем-фамилияләрен
язып алырга омтылуым һич көтмәгәндә кире кагыла.

— Нигә болай? — дим, аптырый калып.— Мин бит сезне
тәнкыйтьләргә җыенмыйм. Хәтта берни язмаячакмын да
әле. Һәрхәлдә, якын арада. Бурычыбыз уртак лабаса —
пычратучы чыганакларны ачыклау.

Ихтирамлы дәшмәүдән гайре җавап ала алмадым. Төп-
ченүнең ахырында бары ике сүз генә ишеттем: «Күрсәтмә
шундый». Нишләмәк кирәк. Шуның аркасында гына рейдны
өзмәссең бит инде! Моның әйбәт ягы да булды тагын: «фа-
милиясез» кеше кыюрак икән.

Юк, күңеллеләрдән булмады бу йөзү. Дегет кебек кап-
кара су әледән-әле шомлы гына пычтырдап та куя. Төптән
күтәрелгән күкертле водород куыклары канализация ис
алып чыга. Төрле урыннардан су алабыз. Суда таркалып
өлгермәгән нәҗес кисәкчекләре, корым-сөрем, кер поро
шогы күбекләре йөзеп йөри. Лаборант кыз нәфис борынын
җыера. Чыннан да, кулда мондый су тутырылган пробир
каны тотуы гына да җирәнгеч. Врачлар аңлаталар: кис
лород суның өстәге бик юка катламында гына табыла икән
калганы күкертле водород белән тәмам тончыккан. Димәк
су чистартылмаган канализация суыннан бернәрсәсе бе
ләп дә аерылмый инде.

Планктон бөтенләй юк диярлек. Бу инде суның «үлгән
леген», ягъни үз-үзен чистарту сәләтен тәмам җуйганы
аңлата. Аның караву, соңрак үткәрелгән бактеорологи
анализ мәгълүматлары күрсәтүенчә, һәртөрле авыру та
раткыч микроблар «рәхәтләнеп» үрчи икән. Һава кисло
роды тәэсирендә күкертле водород, аз-азлап кислородк
кушылып, караңгы болганчык масса хасил итә, ул исә эк
ренләп төпкә утыра.

Менә пычрату чыганакларының берсе — «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсе тирәсеннән Кабанга «коя» торган агынты. Болай да җирәнгеч күл суы бу урында сары-җирән төстә күбекләнеп кайнап тора. Агынты шактый еракка сузылган.

Моторчы әллә көймәне артык кинәт борды, әллә тизлекне чамалап җиткермәде инде, проба алам дип иелгән лаборантның битенә су чәчрәде. Кызый чырылдап кычкырып җибәрде. Куркудан да бигрәк, җирәнүдән булса кирәк. Ярый әле бер бидон чиста суыбыз бар иде. Кыз юынды, ләкин бер күзе кызарып, күз кабагы да шешмәкләнеп калды.

— Саграк кыланырга кирәк! — дип әрләп куйды врач ханым.— Күзсез калуың да бар.— Нәрсә белән ничек юарга, нинди дарулар салырга икәнлеген аңлатканнан соң, ярга төшәргә тәкъдим итте. Әмма кызыбыз баш тартты. Аннан башка экспедициябезнең бер мәгънәсе дә калмый иде шул. Кичкә таба шеш кайтты. Аның каравы, икенче күзе дә кызарып чыкты. Хәер, бу вакытта бөтенебезнең дә күзләребез куян күзенә охшап калган иде инде.

Әлеге вакыйгадан соң юлдашларым, үзара пышылдаштылар да, канализация агынтылары белән маташмаячакларын әйттеләр.

Нигә алай? Алар күлне пычратмыймени? Кайдан нәрсә күпме акканын безгә төгәл белергә кирәк! — дим.

Күтәрелеп бәрелмичә генә түбәндәгеләрне аңлаттылар: иң катлаулысы — промышленность агынтылары, тулы бер көн эшләр өчен анысы да баштан ашкан. Хозфекаль агынтыларны анализларга махсус лаборатория җиһазлары соралмый — аларын бүтән вакытта да тикшерергә була, янәсе. «Бүтән вакыт»ның булмаячагын белеп торсам да, ризалашырга мәҗбүрмен. Төшендерү рәвешендәге тыныч катгыйлыктан бу юлы да артта Күрсәтмә торганлыгын чамаларга мөмкин иде.

Бу «маҗара», бәхеткә каршы, соңгысы булды. Промышленность агынтыларын тикшерүгә бәйле бөтен эшне рейдта катнашучылар төгәл иттереп, үз-үзләрен аямыйча башкардылар.

Моторчы көймәне каршы ярга бора. Элекке сыра заводына йөзеп киләбез (хәзер алкогольсез эчемлекләр заводы). Тутыгып беткән торбадан черек арпа исе бөркелеп торган болганчык су ага. Янында бер ермак, анысы заводның ишек алдыннан агып чыга. Шуның буйлап атлый торгач, чыганакны — мөлдерәмә тулы чокырны табабыз. Анда нан юган су, барда һәм нидидер чүп-чар калдыклары җыела һәм агып чыгып тора... Шунда ук — янып-парла-

нып яткан арпа өемнәре, алар эчендә симез-симез күселәр кайнаша. Ермакка файдаланылган кальций карбидының шомлы-дәһшәтле төстә парланып торган эремәсе дә өстәлә.

Акт төзибез. Әлбәттә инде, кул куяр кеше табылмый — администрация вәкилләрен җир йоткан диярсең. Цех башлыкларыннан берәрсенең имзасын алмакчы булабыз, әмма бездән, ваба белән авыручы кешедән качкан кебек, таюлагын карыйлар: «Юк-юк, бернинди имза турында сүз була алмый! Бары начальство рөхсәте белән генә». Дөресен әйтим, моңарчы мин санэпидстанция хезмәткәрләрен эшсезлектә гаепләп йөри идем. Хәзер менә алар хезмәтенең бөтен катлаулылыгы ачыла башлады...

Без кайтуга лаборант беренчел анализны өлгерткән. Агынтыларда органик кушылмалар СЧК — соңгы чик концентрациядән йөзләрчә тапкыр күбрәк икән. Күләме — тәүлеккә сиксән куб метр чамасы...

М. Вахитов исемендәге химия комбинатының майланып ысланып беткән карасу-көрән корпусларына якынаябыз. Илленче елларда «Спартак» комбинатының агулы агынтысын туктатканнан соң химкомбинат Якын Кабанны иң күп пычратучы предприятие булып калган. Торбадан бәрепторган су күрер күзгә чип-чиста кебек. Әмма рейдта катнашучыларны бу алдый алмый. Алар эшлеке кыяфәт белән иснәнәләр, пробаны яктыга тотып карыйлар, бармаклары белән угалыйлар (болар бар да органолептик анализ дип атала икән). Аннан реактивларны эшкә җигәләр. Химик анализ суда төрле майлар, органик кислоталар һәм синтетик актив матдәләр булуын күрсәтә. Дөрес, алары СЧК дан узмый диярлек.

— Артык борчылырга урын юк югын,— дип аңлаттылар миңа.— Ләкин биредә әледән-әле авария агызулары булып тора. Бөтен күл өсте ак күбек белән каплана. Тәүлегенә меңәр тонна җибәрәләр...

Күлгә хәлиткеч «һөҗүм»не нәкъ менә вахитовлылар ясый.

Шуннан соң күлдәге соңгы балык та, күл буенда яшәгән берәү әйтмешли, скипидар сөрткәндәй ярга атыла, ләмгә күмелеп котылмакчы була, бахыр, тик ахырда барыбер корсагын өскә куеп калкып чыга...

Эшне прокуратурага тапшыралар. Тикшерү берничә ай дәвам итә һәм, моңарчы каралган башка күп эшләр кебек үк, бернинди нәтиҗәсез төгәлләнә. 1978 елның 29 ноябрендә Казан шәһәр Советы башкарма комитеты, химкомбинатка Кабанга чистартылмаган су агызуны тулысынча тыяр-

га! — дигән карар кабул итә. Әмма пычрак су ага да ага... Юк, үчлектән-дошманлыктан да түгел. Бердән, өстәмә канализация коллекторы тармагын сузучы төзелеш оешмасы инде ничәнче мәртәбә срокны өзә. Икенчедән, комбинатта авария очракларында сабынлы су туплау өчен кирәкле, буфер буасы дип йөртелгән махсус чокыр юк. Соңгы «юклык» үзе берничә «юк»ка тарәлгән: ни акча, ни проект, ни буаны төзергә алынырлык тиешле профильдәге оешма юк.

Ә бит югыйсә Кабанга агып торучы майлар һәм органик кислоталар — комбинат өчен кыйммәтле чимал. Тиешенчә чистартканда, боларның барысын да яңадан файдаланып, күпме өстәмә табыш алып булыр иде.

— Бу хәл озак дәвам итәчәкме соң?

Соравыма санэпидстанция хезмәткәрләре: «Чистарту корылмалары төзелгәнче»,— дип җавап бирделәр.

— Төзү өчен ни эшләргә мөмкин соң?

— Без аларны күп тапкырлар кисәттек инде. Актлар да яздык, штрафка да тарттык. Инде бер генә чара калды — производствоны туктату.

Ярты айлардан мондый документ та төзелде. Күпләгән имзалар, мөһер-штамплар белән «ныгытылган» кәгазь миңа бик тә тәэсирле күренде. «Комбинат бер ай вакыт эчендә шәһәр Советы башкарма комитеты карарын үтәмәсә, Кабанга чистартылмаган су агызуга чик куймаса, производство туктатылачак!» — кисәтүдә акка кара белән әнә шулай дип язылган иде.

Әлеге документның язмышы кызыклы. Анда күрсәтелгән сроклар имин генә узып китте, комбинат исә элеккечә «залп»лар ясый торды. Шуннан соң «Советская Татария» газетасы хәбәрчесе Майя Канторович комбинатның ул чактагы директоры Степанов янына кереп, әлеге кисәтү турында сүз кузгаткан. Хәбәрченең әйтүенә караганда, директор шактый вакыт... сүзнең нинди документ турында барганлыгын аңламыйча торган. Директор бу кодрәтле документка... игътибар да итмәгән икән! Чыннан да, ниндидер бер күл аркасында кем инде йөзләрчә кешене — акчасыз, ә илне сабынсыз калдырсын ди!

М. Канторовичның «Кабан күленең бәла-казалары» дигән мәкаләсе («Советская Татария», 1980 ел, 8 август), җәмәгатьчелектә зур яңгыраш тапты, директорны эшеннән алдылар. Әмма «залп»лар дәвам итте. Тагын бер газета күлне яклап чыгыш ясарга мәҗбүр булды, бу юлы — «Вечерная Казань» (1986 ел, 19 июль, «Үлчәү тәлинкәләре» дигән мәкалә). Мәкалә уңаеннан ТАССР Министрлар

Советы Карар кабул итә, анда, аерым алганда, болай дип тә әйтелә: «Кабан күленә промышленность суларын агызуга юл куюы һәм чистарту корылмаларын канәгатьләнерлек төзетмәве өчен М. Вахитов исемендәге химкомбинат директоры иптәш А. М. Рәхмәтуллинга шелтә белдерергә һәм, авария агызулары кабатланса, катырак җәза кулланылачагы турында кисәтергә».

...Вахитов күпере яныннан үтәбез. Бу турыда күлгә диаметрлары берәр колачлы ике торба төбәлгән. Икесеннән дә шаулап-гөрләп сасы «шулпа» агып тора. Әмма бусы хозфекаль агынтылар булганга, тукталмыйча узып китәбез.

Тимер юлга җитәрәк ике күлне тоташтырган бугаз нык саега,— винт төптән зәңгәрсу-соры ләм өермәләре кузгата башлады. Иң сай җирдән ишкәк белән этенеп үтәбез.

Урта Кабанда әлегә бәдрәф исе юк. Әмма күл буеннан-буена бака ефәге белән капланган. Бу инде пычрануның тизләнүе һәм күлнең үлеп бару билгесе. Пробалар метр ярым-ике метрдан башлап аска таба күкертле водород белән тулысынча агуланган «үле зона» ятуын күрсәтә. Кислород исә өске катламнарда да нормадагыдан шактыйга аз.

Менә берьюлы өч предприятиедән — 1 нче җылылык энергоүзәгеннән, резина-техник әйберләр заводыннан һәм синтетик каучук заводыннан чыккан агынтыларны берләштерүче мул сулы каналга килеп җиттек.

— Каршы килмәсәгез, ТЭЦны калдырып торыйк,— ди гидрохимик лаборатория инженеры.— Үзенә бер көн кирәк аның. Эш болай да баштан ашкан.

Лаборант синтетик каучук заводы суының беренчел анализын өлгерткәч, санэпидстанция хезмәткәрләре үз күзләренә ышанмыйча тордылар. Дүрт контроль пробада фенол (куркынычлы канцероген матдә) соңгы чик концентрациядән ун мәртәбәдән утыз ике мәртәбәгә кадәр артыграк булып чыкты. Пробаларның берсендә бакыр кушылмалары әлеге чиктән 820 мәртәбә күбрәк иде. Ә бит авыр металларның тозы кешенең акылына зыян итү, авыр чирләр китереп чыгару, киләчәк буыннарны зәгыйфь итү һәм, гомумән, кеше организмында алдан күреп бетереп булмаслык үзгәрешләр хасил итү сәләтенә ия.

— Эшне прокуратурага тапшырырга кирәк булыр.— Үзара киңәшеп алгач, санэпидстанция хезмәткәрләре эн шундый карарга килделәр.

(Алар сүзләрендә тордылар. Өстәмә күп кенә анализлар һәм тикшерүләр үткәргәннән соң материаллар пр

куратурага бирелде. Бу эш белән шәһәр прокуроры, өлкән юстиция советнигы Қ. Садриев үзе шөгыльләнде. Анализ мәгълүматлары раслануга да карамастан, гаепле кешеләрне ачыклау мөмкин булып чыкмаган. Прокуратура предприятие җитәкчелеген суны агызмыйча файдалануга күчүне тизләтергә һәм алдагы бер-ике елда Қабанга чистартылмаган су агызуны бөтенләй туктатырга мәҗбүр итүче аерым билгеләмә чыгарды. 1989 елга ул үтәлмәгән иде әле.)

Резина-техник әйберләр заводы агыза торган су исә барлык параметрлар буенча да... күлнекеннән берничә тапкыр чистарак булып чыкты! Сәбәбе гади: завод артезиан коесыннан су ала һәм, бер тапкыр файдалану белән, күлгә агыза икән. «Димәк, алар күлне чистарталар булып чыга!» — дип шаярттым мин. Ләкин санэпидстанция хезмәткәрләре көләргә ашыкмадылар. Қөләрлекме: Қабан суын шундый хәлгә китереп җиткергәнбез ки, хәзер промышленность агынтыларыннан да пычраграк булып калган. Икенчедән, суда, аз микъдарда булса да, таркалмый да, парга да әйләнмичә, төпкә утырмыйча тупланучы матдәләр бар икән. Заводның 1980 елда гына да Қабанга 274 мең куб метр су агызуын исәпкә алсаң, күлгә эләккән бу агулы матдәләрнең микъдары да аз булып чыкмый.

ТАССР Министрлар Советының шул ук Карарында болай дип әйтелә: «Қазан резина-техник әйберләр берләшмәсе, 1 нче җылылык энергоүзәге, С. М. Қиров исемендәге синтетик каучук заводы (директорлары Григорьев В. Д., Галиев И. Г., Сафин З. З. иптәшләр) су белән тәэмин итүнең йомык цикл системаларын төгәлләү өчен тизләткеч чаралар күрергә һәм аларны, Қабанга су агызуны 1990 елга тулысынча туктату максатында, 1987 елда төзи башларга тиешләр». Бу карар бүгенге көнгә Қазанның резина-техник әйберләр берләшмәсендә генә үтәлде. Қалган предприятиеләрдә эш элекке хәлендә кала бирә.

Бу озын һәм гаять авыр көн дәвамында (иртәнге уннан кичке җидегә кадәр), без күлгә «койган» җиде промышленность агынтысын ачыкладык һәм тикшердек. (Җылылык энергоүзәге өчен тагын бер көн кирәк булды.) Аларның гомуми дебиты тәүлеккә ике йөз мең, яисә елына 72 миллион куб метр тәшкил итә икән. Күлләрнең гомуми күләме 12 миллион куб метр икәнен искә алсаң, промышленность предприятиеләренең ел дәвамында Қабанның бөтен суын үзләре аша алты мәртәбә үткәрүләрен исәпләп чыгаруы кыен түгел. Нинди күл моңа түзә алсын ди!

Мәгълүматларны эшкәртү берничә көн дәвам итте. Ана-

лизлар кабатланды һәм анықланды, нәтиҗәләр кат-кат тикшерелде. Отчетлар, доклад язмалары, гаризалар һәм соңгы тапкыр кисәтүләр язылды. Рейд нәтиҗәләре буенча, «Теплоконтроль» берләшмәсе баш инженеры Р. Даутовның хакыннан тотып калынды: предприятиедән аккан суда цианийлы матдәләр белән ярыша алырлык агулы цинк кушылмалары бар иде. Хәер, цианийлылары да табылды. Моның өчен электрохимик заводның баш инженеры Р. Гыйльфанов белән директор урынбасары Л. Рыковка штраф салынды. Башка күп кенә җитәкчеләр дә җәзага тартылды.

Санэпидстанция хезмәткәрләре — төпченүчән халык. Суны пычрату очракларын ачыклау белән генә чикләнеп калмадылар, группаларга бүленеп, цехларны да йөреп чыктылар. Күп очракта аеруча агулы матдәләрнең күлгә эләгүе һич тә житәкчеләр аңлатканча «производство ихтыяҗы» түгел, ә бәлки гап-гади мәнсезлек, игътибарсызлык яисә ялкаулык нәтиҗәсе икән.

Әйтик, резина-техник әйберләр заводы ишегалдында агулы булганга шәһәр чүплегенә кабул ителмәгән техник калдыклар өеме табылды. Ни генә юк иде анда! Кислоталар, селтеләр дисеңме, зәһәр матдәләр салынган ватык шешәләр һәм мичкәләр, химик реагентлар тулы ертык капчыклар дисеңме. Болар бар да кар-яңгыр астында ачык тора һәм ахыр чиктә Кабанга агып төшә.

«Теплоконтроль» берләшмәсендә махсус нейтральләштерү цехы бар юкса. Тотылган электролит шунын аша узарга тиеш. Әмма канализациягә агызу җиңелрәк шул. Сизмәсләр әле, янәсе.

Чыннан да, еш кына сизми дә калалар. Табигатьне генә алдап булмый! Табигатькә кизәнеп, экологик тигезлекне бозып, без яшәешебезгә балта чабабыз. Кызганычка каршы, күпләр моны аңламыйлар яки юри аңламаганга салышалар.

Әлегә күл суының бер өлешен Иделгә суырту коткарып килә. Әмма Идел үзе дә шундый ук язмышка дучар сулык, илебезнең мөһим кан тамыры ич!

Кешенең көч-куәте чиксез арткан бу заман кеше белән табигать арасындагы үзара мөнәсәбәтләргә яңача карауны, яңача уйлауны таләп итә. Әлегә исә әйләнә-тирә мохитне саклау өчен көрәш, асылда, бары шуннан гыйбарәт: берәүләр (санэпидстанция хезмәткәрләре) инде булган пычрату очракларын теркәп торалар һәм ара-тирә гаепләләргә штраф салалар. Икенчеләре исә (шундый ук җаваплы урыннарда утыручы, властька һәм техникага ия

кешеләр) ничек тә булса беренчеләрне алдарга тырышалар.

Менә бер мисал. Кабан тирәсендәге предприятиеләрне туктаусыз тикшереп торып, актлар һәм штрафлар белән теңкәгә тия башлагач, күрсәткечләр кинәт яхшырды да куйды. Мондый үзгәреш шикле иде. Тиздән исә шул мәгълүм булды: атна буенча тупланып килгән иң агулы калдыкларны контроль хезмәткәрләре ял иткәндә — шимбә һәм якшәмбе көннәрне агызалар икән. Моны Казан химия-технология институтының инициатив группасына кергән студентлар ачыклаган. Әмма, аларның анализлары рәсми көчкә ия түгел дип, эшне тагын йомып калдырдылар...

КҮЛ БУЕНДАГЫ ШӘҺӘР

(Исемнең сере)

Анда һәртөрле гаҗәпләр бар да бар:
Кып-кызыл алтын шәһәр, җиз карьяләр...

Г. Тукай

«Кабан»нар ничәү булган?
Кабанбәк әмир турындагы риваять.
Н. Ф. Калинин үткәргән казылмалар.
Тагын бер версия.
Шулай да, барыбер кабан дуңгызы...

Казанның яңа аэропортыннан ерак түгел «Кабаннар» («Кабаны») дигән автобус тукталышы бар. Янда гына — «Олы Кабан» һәм «Кече Кабан» дигән рус авыллары. «Кабан» дигән өченче авыл ун чакрымда булыр. Бутамас өчен, монысын «Татар Кабаны» дип йөртәләр.

Кызык. Нигә дип әле Кабан күлләреннән егерме биш чакрымлап читтә утырган бу авылларның өчесенә дә шундый исем кушканнар икән?

Иске географик карталар һәм белешмәлекләрне каткат карый торгач, әлеге рус авыллары урынында Казан ханлыгы чорында «Зур Кабан» һәм «Кече Кабан» дигән татар авыллары булганлыгын ачыкладым. Татар Кабаны исә «Каракчы Кабан» дип йөртелгән. Сан алу кенәгәләреннән күренгәнчә, Казан ханлыгы чорында бу төбәктә авыллар күбрәк булган, аларның барысының да исемендә «Кабан» сүзе кергән: Кабан-Селик, Иске Кабан, Өч Кабан, Ташкабан һәм, ниһаять, гап-гади Кабан. Тагын

шунысы кызык: бу авыллар һич тә күл тирәли урнашм
ган, алар күлләрдән көньякта 15—40 чакрым ераклык
урнашканнар. Моның хикмәте нәрсәдә соң?

Хәзерге «Кабан»нарда яшәүчеләр авыл исеме турын
сорагач, аптырап калалар яисә заманында тирә-якта мы
гып йөргән кабан дуңгызлары турында сөйләп китәлә
Бер уйлаганда, бу Кабан күленең үткәне турындагы р
ваятьләр белән туры да килә һәм алдарак сөйләгән л
генданы куәтли кебек. Ләкин хикмәт шунда, «Кабан»л
авылларның бөтенесе дә диярлек калку һәм коры уры
нарга утырган. Алар тирәсендә элек-электән игелеп ки
гән кара туфраклы басулар, чабыла торган болынна
көтүлекләр җәйрәп ята. Кабан дуңгызлары көн итә то
тан аймаклар исә бөтенләй юк диярлек һәм, күрәсең, бу
магандыр да. Димәк, башка аңлатма эзләргә кирәк. Сту
дент чакта үк күлнең исеме турында бик борынгы риваят
ишеткән идем. Аны миңа бөтен гомерен Иске Бистәд
Мәрҗани мәчете янында үткәргән апам (әниемнең апасы
сөйләгән иде.

Күп гасырлар элек, татарлар «болгарлар» дип аталы
шанлы Шәһре Болгар тирәсендә көн итмәктә булганна
Менә бер заман исәпсез-хисапсыз чиру белән кансыз А
сак Тимер Җиһангир килә. Каланы яулап алгач, яшен
картын, хатын-кызны, бала-чаганы — берсен-бер аямыйч
кырып бетерә. Бик азлар гына котылып кала. Алар ара
сында соңгы болгар ханы Габдулланың Кабан атлы ул
да була. Бәк булганга, аны, олылап, «Кабанбәк» ди
йөртәләр.

Эзәрлекләүдән качып, канга баткан Кабанбәк мул сул
Чулманны кичә, карурманнар һәм сазлыклар аша үт
Менә ул зур вә гүзәл бер күл буена килеп чыга. Кү
суы белән җәрәхәтләрен юуы була — алар төзәлә. Сун
эчүе була — тәнендә дәрман арта, күңелендә өмет уяна
кеше аяк басмаган бу кырагай төбәккә мәхәббәт бөрө
ләнә.

Апам күл тирәсендә үтеп чыккысыз урманнар, әрәмә
ләр җәйрәп ятуы, аларның аю, бүре, селәүсен, кабан кебе
киекләр белән мыжгып торуы турында мавыктыргыч ите
сөйли иде. Ләкин Кабанбәк белән килгән кешеләр курк
калмыйлар. Алар урман кисә, өй сала башлыйлар, иге
игәләр, балык тоталар, кыргый бал кортлары балын җы
лар. Кабанбәк артыннан аның дуслары, туганнары киле
җитә. Тиздән күл буенда гүзәл сарай, ә аның янында зу
гына авыл үсеп чыга. Сарай «Бостан» дип аталган җә
нәти бакчага күмелә. Шул бакча исеме буенча авыл

Бистә» дип аталып китә. Күл исә, Кабанбәк исеме белән, «Кабан» дип йөртелә башлый.

Монда бер «ябышып җитмәгән» урын бар. Үз-үзенә карышы килеп, апа «Бистә» сүзе килеп чыгышын бүтәнчә дә аңлатты. Татарларны шәһәрдән сөргәндә Иван Грозный, Болак артындагы аулак урынга күрсәтеп, «Вот отныне ваше место!» дигән. Үзгәртелә-бозыла торгач, «место-мисгә», «бистә»гә әйләнгән, имеш. Әмма «бистә» татарча шәһәр янындагы авыл яки яңа авыл дигәнне генә аңлата бит, аның «бостан» («бакча») дигән гарәп сүзенә бернинди катнашы юк. Өстәвенә, Кабан буенда Татар бистәсе XVI гасырның икенче яртысында, ягъни Казан алынгач кына барлыкка килә әле. Мәрҗани мәчете янындагы археологик казулар вакытында исә бернинди борынгы корылмалар да табылмаган. (Апам сөйләвенчә, Кабанбәк кешеләре нәкъ менә шул тирәгә килеп утырганнар.)

Кайчакта апам, шул ук риваятьне тәфсилләбрәк сөйләгәндә, яр буендагы иске зиратны телгә ала иде. Укымышлылар кабер ташларындагы язулардан биредә Мөхәммәт пәйгамбәр дәвамчылары — суфилар күмелгәнлеген беләләр, имеш. Кабанбәк кешеләре монда килеп гыйбадәт кыла башлыйлар, соңрак бу урында җомга намазлары өчен мәчет тә салалар. «Элек беркем дә булмагач, зират каян килгән соң?» Минем бу «көфер» соравым апаның ачуын китерә: «Ә син сөйләгәнне тыңла. Халык белми әйтмәс. Булган булгач, булган инде. Үзем уйлап чыгармадым кана!»

Кабанбәк кешеләре салып, аның исеме белән аталган «алтын кала, бакыр авыллар» турында да сөйләштергәли иде ул. «Бакыр» — гади, зиннәтле-бай түгел дигәнне аңлата булса кирәк.

Казан алынгач, бу шәһәр, мәчетләре, алтын гөмбәзле сарайлары, бакчалары, ташпулатлары белән, күл төбенә киткән, имеш. Әгәр ап-аяз көндә, эңгер иңгән тып-тын сәгатьтә көймәдә күлнең уртасына йөзеп керсәң, төптәге гаҗәеп матур биналарны күрә аласың, су астындагы манарадан әйтелгән кичке азанны ишетә аласың, имеш.

(Су төбендәге Китеж шәһәре турындагы легенда белән охшашлык зур. Әмма бу күчерелмә риваять кенә булмас. Күрәсең, мондый мифлар төрле халыкларда бер-берсенә бәйсез, параллель рәвештә яшәгәннәрдер.)

Мин бу хикмәтләрне ис китеп, әкият тыңлаган кебек тыңлый идем. Казан тарихчысы Н. Ф. Калинин тикшеренүләре белән танышкач исә, бу борынгы риваять миңа бөтенләй башкача тәэсир итте.

Кабан тирәсендә казу эшләре алып барганда, Калини
Урта Кабанның ерак ярында борынгы кала урыны — кала
тау тапкан. Галим таш корылмалар, кала тирәсендәге у
ларның аермачык эзләрен ачкан, кала-тауның мәйданы
үлчәгән, ул 7,5 мең квадрат метр тәшкил иткән. Ка
үрдә (күл өсте биеклегеннән 20—25 метрлар югарырак
соңрак Архиерей дачасы (хәзер анда авыл хуҗалыг
фәнни-тикшеренү институты) урнашкан җирдә салынга
Саклавы җиңел булгандыр. Бер якта — тирән күл. Т
гын ике яктан махсус тирәнәйтелгән табигый ерынтыла
уратып алган. Дүртенче якта — 7,5 метр тирәнлектәг
очлы казыклар ыржаеп торган сулы чокыр. Чокыр ар
тында — шундый ук биеклектәге үр, аның өстеннән ис
почмакларда манаралары булган имән дивар үткән.

Кала урыны риваятькә туры килеп бетми бетүен. Га
җәп түгел. Телдән телгә күчә торгач, мәгълүмат үзгәрм
калмый лабаса. Ә бәлкем, риваятьнең бүтән, борынгыра
вариантлары да булгандыр әле, аларда каланың урын
да башкача күрсәтелгәндер? Тукайның «Кисекбаш»ын
күз салыйк. Аның герое Карәхмәт Диюнең су асты шәһә
ренә... трамвайда бара. «Зур завод Крестовниковны» (хә
зерге М. Вахитов исемендәге химия комбинаты) үтә, «на
гляһан [1] бер сахрая» ирешеп, «азрак җәяү алга табан» бар
гач, Кабан күленә җитә. Сүзнең Урта Кабан турында икән
леге бәхәссез булса кирәк.

Кала өчен шәп урын булган бу. Бердән, Урта Кабанна
көньякка таба үзләштерергә җайлы гаять уңдырышлы
җирләр җәйрәп ята. Икенчедән, чакырылмаган кунаклар
дан, күчмә урдалардан саклану өчен бик уңайлы. Калан
Иделдән ерып чыккысыз әрәмәлекләр, вак күлләр, сазлык
лар һәм инешләр челтәре аерып торган. Казан суы тама
гыннан аны урман сарган, атлы гаскәр үтә алмаслык ти
рән-тирән чокырлар ермачлаган, үр-калкулыклар аеры
торган. Шәһәрчеккә бары күл аша — көймәдә генә килеп
җитеп булган.

Кала-тауның культуралы катлавындагы чүлмәк ватык
лары, корал, аяк киеме, көнкүреш әйберләре калдыклары
тикшергәч, галим аларда болгар әйберләре белән тулы ох
шашлык таба. Димәк, каланың я борынгы Болгар белә
бәйләнешы әйбәт булган, я аны Болгардан чыккан ке
шеләр салган.

Калинин үзе исә, калада тимерчеләр дә, коралчыла
да, тукучылар һәм чүлмәкчеләр дә булган, табылган әй

[1] Нагляһан — көтмәгәндә.

берләр шушында ясалган, дигән фикердә тора. Тарихчы Кабанбәк турындагы риваятьне дә телгә ала. «Бик тә дөрескә охшаган», дип бәяли ул аны. «Биредә, Кабан күле буенда, хәзерге Казан территориясендә, шәһәрчек булган,— дип яза ул.— Һәм бу шәһәрчек кораллы отряд торган хәрби кальга гына түгел, торак пункты да булган».

Галим кала-тауның яшен тагын да төгәлрәк аныкларга мөмкинлек биргән борынгы зират калдыкларын таба. Известь-таштан юнып ясалган ике кабер ташы гына сакланып калган. Алар, болгар ташлары кебек үк, нәкыш төшереп, өске ягын михраб рәвешендә гөмбәзләп-уентылап ясалганнар. Бормалы-сырмалы гарәп хәрефләре монда Бөек Әмир, хөрмәтле солтан, солтаннарның ярдәмчесе, җиңүче, ыругның мактанычы... Мир Мәхмүт углы Хәсәнбәк күмелгәнлеге турында сөйли. Елын аерып булмый — әллә үзе ашалган, әллә соңрак кырып-юнып ташлаганнар. Уеп язу техникасына карап, Калинин әлеге таш XIII гасырда куелган дип исәпли. Икенче таш асыл нәселдән Алтын Бөртек атлы хатынга куелган. Монысындагы саннар аермачык укыла: һиҗринең 696 елы, зөлхиҗҗә аеның сигезенче көне, ягъни хәзерге вакыт исәбе белән 1297 елның 27 сентябре.

Бу таш астында нинди генә серләр күмелмәгән икән? Тарихчыларның: Болгар дәүләтендә хатын-кызлар күренекле урын тотканнар, политик тормышта да, сугышларда да катнашканнар, тигез хокуклы һәм мөстәкыйль булганнар дигән фаразын расламый микән ул? Бер шигырендә Гамил Афзал әнә шул турыда уйлана:

Гүзәл-гашыйк җисмең булган,
Ташка язар исмең булган...
Тагын ни дип фикер йөртик,
Алтын Бөртек, Алтын Бөртек?

Кылыч тотып дан алдыңмы,
Илне саклап, гаскәр йөртеп
Дошманнардан камалдыңмы,
Алтын Бөртек, Алтын Бөртек?

Моң булырлык, җыр булырлык
Хәлләреңнән хәбәр көттек.
Ташларга уеп язарлык
Ниләр кылдың, Алтын Бөртек?

Бу ташлар хәзер Татарстан дәүләт музеенда саклана.

Шундый бер риваять бар: бүтән кабер ташлары, ханлык яулап алынгач, борынгы корылмаларның ташлары белән бергә, Яңа Иерусалим монастыре нигезенә салына. Ә бу икесе монастырь башлыгы Гурий кушуы буенча кал-

дырыла — ташларның матурлыгы, бизәлешенең камиллег анын исен китәрә.

Кала янында гүзәл бостан-бакча да була. Аның турын дагы риваять XIX гасыргача килеп җиткән һәм татар та рихчылары тарафыннан язып алынган. Казанлылар ан Сөембикә бакчасы дип йөрткәннәр.

Бакчада берсеннән-берсе матуррак биналар булган, га җәеп агачлар үскән, туп-туры аллеяларда гүзәл болан нар йөргән, имеш. (Риваятьнең кайбер вариантларынд мәрмәр боланнар, ягъни скульптур сыннар турында әйтел Әмма монысы, ай-һай, мөмкин эш микән — ислам сын ясау ны тыйган лабаса.) Бу бакчада җәйге айларда хезмә челәре һәм гүзәл җенестән булган күпсанлы тумачалар белән Сөембикә дә ял итәргә яраткан. Бу хакта язм чыганакларда да әйтелгән.

Калинин шундый нәтиҗә ясый: гади торак пункт кын түгел, дәүләтчелек үзәге, әмир резиденциясе булган бу Шәһәрчек Болгар иленең төньяк чикләрен саклау макса тында салынган булса кирәк. Башта бәләкәй булып, сон рак, Болгар илен монголлар яулап алгач, аннан күче килүчеләр исәбенә үскән булуы да бар. Кала-тауның куль туралы катламыннан каланың озак яшәмәгәнлеге күренә Янда гына салынган Казан (аралары нибары алты ки лометр) ханлыкның башкаласы буларак ныгып җиткә шәһәрчек сәүдә юлларыннан читтә калган, кальга булара та хәрби әһәмиятен җуйган, күрәсең. Шәһәрчек үзе хан нарның җәйге ял урынына, ә Кабан әмирлеге аларның нә сел мирасына әйләнә.

Ханлык буйсындырылганнан соң, ханның мирас җир ләре Яңа Иерусалим монастырена бирелә, анда яшәгә халыкның күпчелек өлеше сөрелә. Князь Василий Шуйский 1555 елда архиепископ Гурийга биргән грамотасында бүлә ителгән җир турында мондый сүзләр бар: «Ике мең чирек (ике мең гектар чамасы) сөрү җир, элекке патшалардан килгәнчә (ягъни Казан ханнары заманында булганча), бар ча урманнары, болыннары, күлләре, чолыклары, кондыз аулау урыннары белән өч Кабан» монастырьга бирелә.

Монастырь биләмәләренең чикләрен картага төшерсәк, «Кабан» исемен йөрткән авыллар тупланган урын килә дә чыга. Хәер, соңрак мондый исемдәге авыллар бүтән төбәкләрдә дә барлыкка килгән, әмма алары элекке «Ка баннар»дан күчкән халык салган дип уйланыла.

Шулай итеп, борынты риваять соңгы ноктасына хәтле диярлек раслана түгелме соң? Күлләрнең генә түгел, күп кенә авылларның исемнәре килеп чыгышы да ачыклана.

Шунысын да истән чыгармыйк: кала-тау шайтан почмагына, ягъни ашалу-убылу процесслары актив барган урынга бик якын. Егерменче гасыр башында булганча, яр буендагы кайбер корылмаларның чынлап та күл төбенә киткән булуы бар. Каланың мантый алмавы, ташлануының бер сәбәбе, бәлкем, шулдыр да әле. Су асты археологлары монда кайчан да булса «Татар Атлантидасы»н тапмаслар микән?

Тагын бер сорау кала: болгарларда «Кабан» дигән кеше исеме булганмы?

Кабер ташларындагы язулар һәм язма чыганакларга таянып моңа да: «Әйе, булган»,— дип өзеп җавап бирә алабыз. Шактый киң таралган бу исемнең төрле үрнәкләре очрый: Кабан, Кабанбәк, Кабанай, Ташкабан һ. б. Әлеге исемнәрнең кайтавазы булган фамилияләр хәзерге көннәргәчә килеп җиткән: Кабанаев, Кабанбаев, Кабанбиков һ. б. «Кабан»нарга бу кадәр муллыкны шуның белән аңлатып була: күп кенә тарихчыларның фикеренчә, болгарларда үзенә күрә кабан дуңгызы культы яшәп килгән. Бу куәтле киек батырлык, куркусызлык символы булып саналган.

Шулай да... Риваятьнең ышандырып җиткермәгән яклары да бар. Беренчедән, Кабан яки Кабанбәк атлы әмир бер генә тарихи чыганакта да теркәлмәгән. Иске Казан салыну турындагы риваятьләрдән шул ук Габдулла ханның Алтынбәк һәм Галимбәк исемле уллары гына булганлыгын беләбез. Болгар тар-мар ителгәндә алар могҗиза белән генә исән калалар, төн иленә качып китеп, анда иске Казан каласын салалар.

Икенчедән, даталарның туры килеп җитмәве шикләндерә. Риваятьнең иң борынгы вариантларында шәһре Болгар Аксак Тимер тарафыннан һиҗринең 700 елында, ягъни 1300—1301 елларда тар-мар ителде диелә. Ә бит Аксак Тимер[1] ул вакытта тумаган да була әле. Тарихчылар фикеренчә, бөек каланы җир белән тигезләгән Алтын Урда ханы Мәңге Тимер күздә тотыла булса кирәк. Моныңише бутау-алыштырулар — була торган хәл. Әмма, шул ук кабер ташларына карап фикер йөрткәндә, Кабан күле буедагы кала моннан да элегрәк салынган. Кабан атлы бәк, чыннан да, булып, күл буена килеп чыккан очракта да, анда аны шау-гөр килеп яшәп яткан кала каршылаган булыр иде. Шәһәр халкы күлне берничек тә атап йөрт-

---

[1] Аксак Тимер (1336—1405) — Урта Азиядә башкаласы Сәмәрканд булган дәүләт төзегән, Европа һәм Азиянең күп кенә илләренә яу чапкан дәһшәтле җиһангир. Аның Болгарга җимергеч походы 1361 елда булган дип уйланыла.

мәгәнмени? Әгәр ул чакта ук, ягъни XII—XIII гасыр-лардан, күлнең үз исеме булган булса, киресенчә, кала-ның да, аннан чыккан кешеләр салган авылларның да бөтен әмирлекнең дә бәк исеме белән түгел, бәлки күл исе-ме белән аталуы мөмкин.

Мәсьәләгә бүтән яктан карап карыйк. Топонимика бел-гече Г. Саттаров «Кабан» сүзе борынгы төрки телдәге «Каб-куб» тамырларыннан ясалган дип исәпли (моннан «кабу», «кубару» һ. б. сүзләр чыккан). Ә бу — җирдәге уентыны, чокырны аңлата. Димәк, «Кабан»ның борынгы мәгъәсе «кабылган», ягъни уелган, убылган җир булып чы-га. Ул заманнарда күлләрне генә түгел, кайбер елгаларны да «Кабан» дип атап йөрткәннәр. Мондый атамаларны кайберләре безнең көннәргәчә килеп җиткән. Соңрак кыр дуңгызларын да «кабан» дип йөртә башлаганнар. Бу сүз шул ук «каб» тамырына «ан» (җан иясе, җанвар) кушып ясалган.

Шулай итеп, күл исеменең килеп чыгышын аңлаткан өч версия бер үк сүздә өч төрле мәгънә күрүгә бәйле: 1. Су-лык. 2. Кыр дуңгызы. 3. Кеше исеме.

Миңа калса, икенче мәгънә дөрес. Ник дисәң, төрки ка-биләләр күл буена килеп чыкканда (моннан мең еллар чамасы элек) сүзнең борынгы асыл мәгънәсе («сулык») җуелып өлгергән булгандыр инде. Кыр дуңгызы мәгънә-сендә кулланылган ялгызлык исемнәре күп очрау да шул хакта сөйли булса кирәк. Иң борынгы рус чыганакларын-да да «Кабан күле» «Свиное озеро» дип тәрҗемә ителгән. Соңрак «кабан» сүзе рус телендә ныклап урнашып өлгер-гәч кенә, «Кабанье озеро» дип, тагын да соңрак исә «Ка-бан» дип кенә яза башлыйлар.

«КАБАН ҖИҢЕЛДЕ»

Абдулла Алиш Кабан турында.
Җылылык пычрануы.
Кем гаепле?
Чистарту корылмаларында.

Бүлекнең исеме тырнаклар эченә киная булганга алын-маган. Кабан сүзнең туп-туры мәгънәсендә җиңелгән, но-каутланган, аркасына сузып салынган. Тырнакларның ва-зифасы исә бу сүзләрнең өземтә икәнен күрсәтүдән гыйба-рәт. Ул Абдулла Алишның шул исемдәге очеркыннан алынды.

ОБУЗДАЕМ
КАБАН

Балалар язучысы, Муса Җәлилнең көрәштәше, аның белән бергә гильотинада җәзаланган Абдулла Алиш яшь чакта КазГРЭС (хәзерге җылылык энергоүзәге ул чакта шулай дип аталган) төзелешендә десятник булып эшләгән. Әлеге очерктан тыш Алиш шул ук темага «Якты күл буенда» дигән повесть та яза. Ул беренче бишьеллыкларның иң зур төзелешләренең берсендәге хезмәт күтәренкелеген, тиңсез штурмнарын тасвирлый. Ямаулы чикмән, ыштырлы чабата кигән егетләр, агайларны — кичәге крестьяннарны күрәбез... Ачлы-туклы килеш кәйлә һәм көрәк белән ут уйната алар, таштан каты туң җиргә учакта кыздырып тимер чөйләр кага, җил уйнап торган барак идәненә тезелешеп ятып йоклый...

Язын Кабан суы берничә метрга күтәрелә, буаны ерып, котлованга ыргыла. Ташу суы белән көрәшергә алдынгы бригаданы куялар. Төзүчеләр буаны кызыл балчык тутырган чыпта каплар белән томалыйлар. Тездән, кайчакта хәтта бил тиентен бозлы суда торып эшләргә туры килә...

«Кабан, ачулансаң да, котырсаң да, син җиңелдең. Удар бригадалар, корыч кешеләр барыбер сине авызлыклый алдылар».— Очерк әнә шулай тәгәлләнә.

Ул чорның әдәби документын укыганда бүген каршылыклы хисләр кичерәсең.

Ата-бабаларыбызның фидакарьлеге, ихлас хезмәт күтәренкелеге сокландыра, әлбәттә. Икенче яктан... табигатьне буйсындыру, елгаларны, күлләрне, хәта диңгез кадәр диңгезне дә «авызлыклау», «табигатьтән рәхимлекләр көтмәү», аны кеше ихтыярына буйсындыру омтылышы инде шундый нәтиҗәләргә китерде ки, хәзер чәчебезне йолкырга әзербез.

Электростанция салу өчен урын сайлаганда мәсьәләне Урта Кабанның суы саф кына түгел, йомшак та булуы хәл итә. Ул вакыттагы шкала буенча күл суының катылыгы биш градустан артмый. Казан елгасыныкы исә туксан градуска җитә. Станциянең казаннары өчен катылыгы ун градустан артмаган су кирәк була.

Экономия максатыннан, градирнялар төзү һәм суны кабат файдалану кебек «вак-төякләр» искә алып торылмый. Станция күлнең бер башыннан сап-салкын, чип-чиста суны суыртып ала да, үзенең «ашказаны», «эчәкләре» аша үткәреп, 40—50 градуска кадәр җылытып, икенче башына агызып чыгара. Шулай итеп, күл станциянең производство циклына катыштырыла.

Утызынчы еллар башында станция ел дәвамында күл-

нең уннан бер өлешен файдаланса, сугыштан соң аны тулаем «эчеп эшкәртеп чыгара» башлый. Ә хәзер Урта Кабан суы аның ут кайнап торган казаннары аша елына әллә ничә тапкыр үтә.

Нәрсәгә китерә соң бу?

«Җылылык пычрануы»ның хикмәте зур түгел. Күрер күзгә су нәкъ шундый ук. Ләкин ул, беренчедән, кислородсыз кала. Икенчедән, анда балыкларга иң кирәкле җим — планктон үлә. Әлеге иң нәни организмнарның һәлакәтеннән соң күл үзен-үзе чистарту сәләтен җуя, анда зарарлы бактерияләр үрчи башлый. Һәм, ниһаять, җылы су зәңгәрсу-яшел «чүп» суүсемнәр өчен җәннәт була. Чик-чама белмичә үрчегән бу суүсемнәр, кислородның төп өлешен йотып барып, күлнең башка тереклекияләренең үлемен якынайталар. Үзләре үлгәч исә төпкә төшәләр, күкертле водород бүлеп чыгарып, чериләр.

Бусы гына җитмәгән, станция күлгә тәүлек саен дүрт мең куб метр чамасы пычранган су агыза. Казаннарны һәм башка җиһазларны химик юл белән чистартканнан калган юынтык бу.

Менә су инспекциясе хезмәткәрләре 1980 елның 14 маенда ясаган анализлар: бер литр суда 54 миллиграмм нефть продуктлары табылган. Рөхсәт ителгән иң соңгы чик — 0,3 миллиграмм. Балык сагы инспекциясе таләбе исә тагын да кырысрак — 0,03 миллиграмм. Эремәгән кисәкчәләр микъдары 20 миллиграмм урынына 1391 миллиграмм булган. Бу хәл миллион сум чамасы акча тотып төзелгән чистарту корылмаларының насос станциясен кар суы басып китү сәбәпле эшләмәвеннән килеп чыккан.

Чистарту корылмалары эшкә җигелгәч, күрсәткечләр беркадәр яхшыра, әмма нефть продуктлары барыбер соңгы чиктән уннарча мәртәбә күбрәк була.

Урта Кабанны күптән инде берәү дә Якты күл дип атамый. Суы көнкүреш яки хуҗалык хаҗәтләре өчен генә түгел, хәтта промышленность производствосы өчен дә яраксыз. Табигый чисталыгын һәм йомшаклыгын югалтып, елга суына якынаеп килә ул. Хәтта аның өске катламнарында да күкертле водород, суга болганчык төс бирә торган эремәгән кисәкчәләр, бәдрәф исе арта тора. Санэпидстанция хезмәткәрләре Кабан суына, начар ис беткәнче, дистилляцияләнгән су кушып караганнар. Моның өчен аны... 250 тапкыр «сыегайтырга» кирәк булган!

Су инспекциясе хезмәткәрләре бик кызыклы бер документ күрсәттеләр. 1 нче җылылык энергоүзәгенең шикаяте бу. (Документка «Татэнерго» идарә баш инженеры

В. М. Полтавец кул куйган.) Кабан суының пычраклыгыннан разый түгелләр! Ак эт баләсен кара эткә ягуның соклангыч үрнәге булган әлеге кәгазьдә соңгы өч-дүрт елда Урта Кабан суында нефть продуктлары 1,4 млг/л дан 7,5 млг/л га, тозлар 1050 млг/л дан 1800 млг/ л га җитүе әйтелә, пычрануның башка шундый ук «тәэсирле» параметрлары санала. Болар бар да суыту конденсаторы торбаларының ашалу-тутыгуына, казаннарда юшкын хасил булуга китерә һәм станциянең авариясез эшләү мөмкинлеген, димәк, шәһәр торак йортлары һәм промышленность предприятиеләренең өчтән берен җылылык һәм электр энергиясе белән тәэмин итүне куркыныч астына куя, янәсе!

Су инспекциясе хезмәткәрләре аңлатуынча, бу документ Кабанны пычраткан өчен җылылык энергоүзәге җитәкчеләренә штраф салыначагы турындагы кисәтүгә җавап төсендә әзерләнгән. Үз гаепләрен су инспекциясенә сылтарга тырышу көлкеле, әлбәттә. Әмма станция җитәкчеләре, шуп исәптән, аның директоры И. Г. Галиев белән сөйләшкәндә, алар хәл начарлануны Якын Кабаннан пычранган су агып чыгу, башка предприятиеләрнең әшәке су агызуы һәм бүтән төрле сәбәпләр белән аңлаттылар. Станциянең үз гаебе турында гына әйтергә онытты‌лар.

Урта Кабанда вак-төяк балык күренгәли әле. Яр буенда яртылаш көйгән камыш, очына хәтле диярлек мазутка баткан зәгыйфь таллар үсә. Бака тавышлары да ишетелгәли. Ялгыз акчарлаклар очып үтә. Ләкин үләксә эзләп бөтерелүче козгыннар күбрәк. Ара-тирә эти-әниләреннән качып су читендә чупырдап яткан бала-чага да очрап куя. Аллергик авыруларның нык артуы мохит пычрану нәтиҗәсе булуын, бу коенуның кыйммәткә төшәчәген белеп җиткерми шул алар. Күл әлегә тормышның соңгы чаткыларын саклап калыйм дип чәбәләнә. Әмма иртәгә биредә йөз гектарлы мәйданда канализация пычрагы гына торып калуы мөмкин...

Бүген ни эшли алабыз соң? Җавап күптән мәгълүм: судан файдалануның йомык циклын кертергә, чистарту корылмалары төзергә кирәк. Иң катгый карарлар да, штрафлар да, тантаналы вәгъдәләр дә бу үтә зарур, мәҗбүри чараларны алыштыра алмаячак.

Шунысын ассызыклап әйтәсе килә: Кабан проблемасы техник якка яки финанс мәсьәләләренә генә кайтып калмый. Иң әүвәл бу — аңлылык, вөҗдан мәсьәләсе.

...Балык сагы инспекторы, майланган зәңгәр спецовка кигән, яшенә күрә артык җитди егет — Володя Чекирин белән 1 нче җылылык энергоүзәгенең чистарту корылма-

ларын карап йөрибез. Менә нефть агып, кара тасма эз
сузган зур гына резервуар. Тирәсендә мазут күле җәел-
гән — түмгәктән түмгәккә, таштан ташка сикереп кенә
нкын килә алабыз. Су тонарга һәм өске пычрак катлам-
нан арынырга тишле буфер савыты бу.

Володяның очлы күзе шунда ук җитешсезлекне күреп
алды. Су берничә сәгать тонарга тиеш, ә монда ул, ариф-
метика дәреслегендәгечә, бер торбадан агып керә дә икен-
чесеннән агып чыга. Өстәвенә, калкып чыккан нефть кал-
дыкларын агыза торган бүрәнкә тыгылган.

Ягулык-транспорт цехы начальнигы ип. Охлопчиковны
эзләп табабыз — чистарту корылмаларының эше өчен ул
җавап бирә икән.

— Әйе шул,— дип килешә цех башлыгы.— Резервуар
бәләкәйрәк булып чыкты. Проектчылар ялгышкан.

— Алай булгач, тагын берне куегыз,— дип ярсый Во-
лодя.— Бакларыгыз аз мәллә? Тондырганда гына да нефть
продуктларының туксан процентлабын аерып алып була.
Ә сездә бу стадия әллә бар, әллә юк...

Флотатор дип аталган җайланманы карыйбыз. Монда
төп эш судагы нефтьне махсус химик өстәмәләр — коагу-
лянтлар ярдәмендә аера торган бик кечкенә һава куык-
ларына йөкләнгән. Әмма, Охлопчиков әйтүенчә, бу хик-
мәтле коагулянтларны чистарту корылмалары кабул ител-
гәннән бирле күргәннәре юк икән — дефицит мал.

Өченче стадиядә су фильтрлар аша уза. Ләкин, баш-
тагы ике стадия тиешенчә үтәлмәгәч, нефть продуктлары-
ның калдык кисәкчәләренә генә исәпләнгән фильтрлар ты-
гыла, үзләренә йөкләнгән бурычны үтәми башлый. Менә
шуннан соң инде Кабан суында аллы-гөле таплар, хәтта
мазут төерләреннән оешкан кара утраучыклар йөзеп йөрүе
гаҗәп түгел.

Сүз уңаеннан, нәкъ шундый ук корылмаларны мин
республикабызның көньяк-көнчыгышында, нефтьчеләрдә
дә күрдем. Файдаланылган суны чистарту дәрәҗәсе анда
99,9 процентка җитә. Җылылык энергоүзәгендә бу күрсәт-
кеч күп дигәндә 70 процентка тарта. Анда да — смена
эшчеләре фильтрларны әледән-әле пар белән өрдереп,
аларны алыштырып торганда гына.

Кабан мисалында табигать тирәлегенең, бигрәк тә йо-
мык экологик системаның үзенә бик тә сизгер, сак мөнә-
сәбәт таләп итә торган чәрексез, нечкә организм булуы
күренә. Көчләүгә бер ел, ике ел, кайчакта хәтта уннарча
еллар буена түзә ул. Әмма соңыннан аны элекке хәленә кай-
тарыр өчен дөньяның бөтен алтыны да җитмәскә мөмкин...

КАБАН КҮЛЕНДӘ АЖДАҺА БУЛГАНМЫ?

Елан йөз яшәсә — аждаһ
мең яшәсә — юха булы
Татар халык мәкал

Аждаһа — (*миф*) әкиятлә
дә сөйләнә торган, берни
башлы, гаять зур һәм би
куркыныч елан.
*Татар теленең аңлатмал
сүзлег*

Канатлы аждаһа. Легенданы ничек дип аңларга
Казан гербы каян килгән?
Күл төбендәге хан кызы.
Моңсу хикәят.

Көннәрнең берсендә минем кулга бер гыйльми кита килеп керде. Анда Казан һәм Кабан күле, легендалар һә риваятьләргә таянып, динозаврлар яшәгән булуы ихтима урыннар рәтенә кертелгән. Китапның исемен дә, авторы да хәтерләмим (чит ил галиме булса кирәк). Бер рәсе генә аермачык хәтердә калган: арткы планда — Сөембик манарасы, алда — тыныч кына җәйрәп яткан күл, суда тешләрен ыржайткан аждаһа башын сузып тора.

Чыннан да, легендаларның берсендә безнең шәһәр урынында кайчандыр берсе-берсе «бүрәнә хәтле» еланнар яшә гәнлеге сөйләнә. Аларның башлыгы өч башлы, оча тор ган елан — Аждаһа булган, имеш. (Хәер, баш саны төрл вариантларда төрлечә йөри — бердән алып уникегә кадәр. Бу төбәктә кала салырга уйлаган ханның хезмәтчеләр ярдәм сорап сихерчегә мөрәҗәгать итәләр. Ул исә бола ди: агачларны кисегез, күп итеп салам, чыбык-чабык ки терегез. Язын, җир кипкәч, еланнар салам астына керер — ут төртәсе генә кала... Шулай эшлиләр дә. Еланнар янга да «шундый яман ис тарала ки, кешеләр, атлар, дөялә тынсыз авалар». Һәрхәлдә, Казан елъязмачысы әлеге ле генданың иң борынгы вариантын әнә шулай язып калдыр ган.

Еланнарны юк итәләр, башлыклары Аждаһа исә ка кара төтенгә уралып очып китә дә Кабан күленә төш Әнә шул заманнардан бирле ул күл төбендә яши, каза лыларга үч итеп, я әледән-әле аларның үзләрен, я бал ларын алып тора, имеш. Кайбер вариантларда Аждаһа төбе патшалыгы төзегән явыз Диюгә әйләнә. Тукайны «Кисекбаш»ында да әнә шул вариант уйнатыла:

Әй дулый мәлгунь Дию, әй тартыла!
Акыра ямьсез каты — җир селкенә.

Халык фантазиясенә хас котылгысыз арттыруларны алып ташласаң, легенда шактый ук реалистик төс ала. Казан иң әүвәл салынган үр «Елан тавы» дип йөртелгән. Хәзер анда — монастырь корылмалары. Ул да шул «елан» сүзенә бәйле рәвештә «Зилантов монастырь» дип йөртелгән. Үр белән янәшә бәләкәй генә Елан күле булган. Тугайлар, сазлыклар, әрәмәлекләр диңгезендә коры утрау булып калкып торган үр үзе Иделнең борынгы яры калдыгы булган. Асылда бу уннарча чакрым җирдә елан (күрәсең, зәһәр еландыр, бәлкем, аеруча зур төредер) яшәү өчен, бигрәк тә, кышлау өчен бердәнбер уңайлы урын булгандыр.

Легендада шул чаклардагы игенчелек тә чагылыш тапкан: яңа җирләрне үзләштерү — ышна ачу, урман төпләүяндырудан башланган бит. Әлбәттә, инде, моның өчен тимер хезмәт кораллары булу шарт. Безнең якларда алар мең ел чамасы элек барлыкка килгән дигән гипотеза яши. Күрәсең, нәкъ менә шул вакытларда Елантаудан ерак түгел Биш Балта дигән татар саласы барлыкка килгәндер дә. Исемгә керерлек булгач (бу исем безнең көннәргәчә килеп җитте), ул чакта шул кадәр (биш!) балтаның никадәр зур байлык булуын чамаларга була.

Әлбәттә, легендаларның барыннан да элек халыкның иҗат җимеше булуын, турыдан-туры, рационалистик аңлатуга кайтып калмавын истән чыгармыйк. Әйтик, оча торган елан турындагы легендалар борынгы Болгарда да, Суварда да, Биләрдә дә таралган булган. Чистай янындагы Юкәтау, Алабуга янындагы Шайтан каласын әнә шундый әкәмәт зур еланнарның яшәү урыннары дип исәплиләр. Болгар иленең Чишмә елгасындагы чик буе шәһәрчеге Елантау дип аталган. Хәзер дә анда — Елантово дигән рус авылы бар. Болар бар да аждаһаның (руслар аны Зилант дип йөрткән) бик борынгы һәм тирән тамырлары булуы турында сөйли.

Кайбер галимнәр, Аждаһа, Змей-Горыныч кебек әкияти персонажлар турындагы бөтен дөньяда киң таралган легендаларда кешелекнең оча торган кәлтә яисә башка төрле динозаврлар турындагы тарихи хатирәләре чагылыш таба, дип исәплиләр. Динозаврлар инде тарих сәхнәсенә гакылга ия кеше чыкканчы ук үлеп беткәннәр дип санаганда да, аларның галәмәт зур скелетларын борынгы бабаларыбызга очраткаларга туры килгәндер әле. Әлеге китап авторы да шундыйрак фикердә тора. Безнең якларда

булган очракта да, динозаврлар зур бозлык чорын, ай-һа кичә алдылар микән? Әлеге легендаларның җеп очын и әүвәл көнчыгыш мифологиясеннән эзләргә кирәктер.

Зирәк акыл һәм үлемсезлек символы булган оча тор ган елан Идел Болгарының гербын бизәп торган. Со рак ул башта Яңа Болгар дип йөртелгән Казанга да күч кән. Иван Грозныйның бабасы Иван III, хан гаскәре җиңеп, Казанны алгач, үзенең титулларына «Болгар кня зе» исемен дә өсти, байрагына борынгы Болгар гербы да төшертә. Бу сурәт ялган Дмитрийның мөһерендә һә патша Алексей Михайловичның байрагында безнең көн нәргәчә килеп җиткән. Шуннан күренгәнчә, аждаһаның бе башы, тавыкныкы төсле гәүдәсе һәм дүрт тәпие булга Кош гәүдәсенә бөтерелгән елан койрыгы тоташкан, зу итеп ачылган томшыгыннан елан теле чыгып тора.

XVIII гасырда аждаһа сурәте тагы да үзгәртел 1730 елда аны Казан губернасының рәсми гербы ите раслаган указда болай диелә: «Елан — кара, башында - Казанның алтын таҗы, канатлары кызыл, төп төсе — ак Мондый бизәлеш борынгы болгарларның күзаллауларын ни дәрәҗәдә туры килгәндер — анысын әйтүе кыен. Һәр хәлдә, Елан бүген казанлыларның күбесенә күп төрл значоклар, открыткалар, сувенирлар аша әнә шундый «кыя фәттә» таныш.

Тик нигә әле аждаһа нәкъ менә Кабан күленә «төшкән» Күлнең ел саен берәр яки хәтта берничәшәр кешенең ба шына җиткән усал холкы хәлиткеч роль уйнагандыр мон да. Күл төбендәге сап-салкын чишмәләр, мәкерле чоңгыл лар, су асты агымнары турында риваятьләр күп. Кабанны бу үзенчәлеге төптә яши торган усал көчләр турында төр ле-төрле легендалар туугa да сәбәп булгандыр.

Андрей Протопоп үзенең 1560—1563 елларда язга «Патшалар шәҗәрәсенең дәрәҗәләр китабы»нда[1] казан лылардан ишеткән тагын бер легенда китерә. Мөхәммә Әмин ханның Гәүһәршәркат исемле искиткеч чибәр һә акыллы сеңлесе булган, имеш. «Татар гыйлеменә» һә «төрле җен күрәзәсенә» өйрәнгән бу кыз Казанның алы начагын берничә ел алдан әйтеп бирә. Күрәзәсе рас бул гач, җиңүчеләр кулына эләкмәс өчен, Кабанга ташлан һәм су анасына әйләнә. Айлы төннәрдә ул судан чыга да шәһәр буйлап моңаеп йөри, имеш. Кремль үренә менә, ха сарае хәрабәсен урап чыга, җимерелгән мәчетләр янында

[1] «Книга степенная царского родословия».

озаклап басып тора. Татар бистәсендә яшәүчеләр әле XIX гасырда да сөйли торган булалар: хан кызы җәйге кичләрдә алтын тарагы белән чәчләрен тарап утыра, берәрсе күрә калса, сөякчел йодрыгын янап, суга чума, имеш. Балаларны да шул гына батыра, заманында аның киңәшен тотмаганга, үзара ызгышларны туктатмаганга үч ала, янәсе.

Г. Тукайның мәшһүр поэмасында бу легенда да чагылыш таба:

Су анасы,— бик явыз, йөзе кара,—
Ел да бер угъланны йә кызны ала.

Легендада чынбарлык белән «шагыйранә ялган» бергә үрелгән. Мөхәммәд Әмин ханның (1518 елда үлгән) чыннан да Гәүһәршәркат исемле сеңлесе булган (рус чыганакларына я Коршенда, я Горшанда, я Ковкошад булып кергән). Абыйсы үлгәч ул Казанга нигез салган Олы Мөхәммәт династиясенең бердәнбер вәкиле булып калган. Гәүһәршәркат Мәскәү белән тыныч яшәү тарафдары була, халык та ярата үзен. Берзаман ул хәтта ханлык белән дә идарә итеп ала. Әмма сарай фетнәсе нәтиҗәсендә тәхеттә аны Җан Гали алыштыра.

Бер сорау туа. Кабан җир асты су юллары аша Иделгә тоташкан микән әллә? Мондый фикергә су асты агымнары турындагы риваятьләр генә түгел, XVIII гасыр азагында ук Кабанда үткәрелгән беренче фәнни тикшеренүләр дә этәрә. Күлнең ярлары үзгәрү процессларының гаять тиз баруы да шушы фикергә куәт өсти — моның өчен су циркуляциясе кирәк бит.

Ләкин соңгы елларда Н. М. Минһаҗева үткәргән тикшеренүләр вакытында Кабанда бернинди су асты чишмәләре дә, су асты агымнары да табылмады. Моның сере гади — күлләрнең төбе сасы ләм белән капланган: Якын Кабанның бөтен күләменең өчтән ике өлеше, Урта Кабанның өчтән бере, Ботан бугазының күпчелек өлеше, Болак — йөз процентган артыграк (хәзер Болак төбе элекке су өсте биеклегеннән дә өстәрәк!). Кипкәндә мондый ләм тоташ бер таш булып ката.

Ләм гаять дәрәҗәдә күкертле водород, авыр металл кушылмалары белән агуланган, глист күкәйләре белән тулы. Мондый күлдә хан кызы түгел, пәри үзе дә чыдамас, сикереп чыгар!

ФӘНГӘ МӘГЪЛҮМ БУЛМАГАН ҚУШЫЛДЫКЛАР

Күлне шулай тончыктырып
агулап үтергәнче,
Кодрәтең җитсә, Кеше,
аны Күккә элсәңче!
Бәлки, Күк катына менгәч,
күл сулу алыр иде!
Бишектәй тибрәнер иде дә,
яңгырлап явыр иде!
Җирдән ияргән зәхмәтен,
бәлки, җил алыр иде...
...Күлне Күккә аскан егет тә[1]
моңа куаныр иде!

Равил Фәйзуллин

Иң изге җирдә.
Чыганакны эзлибез.
Җир астындагы сер.
Кушылдыклар кими...
Карар барын бар да...

Географик белешмәләр раславынча, Кабан күлләре тезмәсенең хәзер бер генә кушылдыгы да юк.

Әмма 1979 елның җәендә Якын һәм Урта Кабаннарның яр буйларын тикшереп чыккач, мин фәнгә билгеле булмаган биш яңа кушылдык таптым (бу исәпкә элегрәк телгә алынган промышленность агынтылары керми).

БЕРЕНЧЕСЕ шаулап-гөрләп, «хуш ис» аңкытып, Кабанга Татар академия театрының яңа бинасы тирәсендәрәк килеп коя. Күлнең бу өлешен шакшы су чокырына әйләндереп, төзүчеләрнең иң нык теңкәсенә тигәне шул иде.

Бу кушылдыкны тикшерү күп вакыт алмады. Шаккаткыч маҗаралар да, хәтәр мизгелләр дә булмады. Исе генә менә... Җилгә каршы яктан барырга тырышып, ташкын инде тирән эз ярырга өлгергән калку җиргә мендем. Комсомольская урамындагы сасы баткаклыкны кичтем (бу яр буе урамы архитекторларның рәсемнәрендә нинди матур булып күренә иде!), Аркылы (Поперечная) Насыйри — урамы буйлап киттем. (Сүз уңаеннан, урамның исеме «Поп. Насыйри» дип язылган иде, шәһәр башкарма комитетына шалтыраткач, язуны алыштырдылар тагы.) Сасы елга башын мин... Мәрҗани мәчете яныннан эзләп таптым. Канализация коллекторыннан чаптырып аккан бол-

[1] Татар халык әкиятендәге «күлегезне күккә асам!» дип җеннәрне куркытып җиңгән егет күздә тотыла.

ганчык агынты инде тирән чокыр ясап өлгергән. Чокыр аннан-моннан киртә белән әйләндереп куелган.

Киртә тирәсендә ләчтит сатып утырган әбиләр бөтен сорауларыма да бик теләп җавап бирделәр. «Чишмә» инде бер ел чамасы ага икән. Шалтыратмаган, язмаган җирләре калмаган. Туганнан туган энесе Мәскәүдә яши торган ниндидер Фая атлы сатучы «Чаян»га җибәреләсе хатка имза да җыеп йөргән. Әбекәйләрнең берсе өч айлап элек кенә чокыр янына «Водоканал» дип язылган ябык машина килеп туктаганын да күргән. Машинадан төксе кыяфәтле, кырынмаган өч ир заты төшкән. Тәмәке тартып, таптанып, чокырга төкергәләп бераз торганнар да... китеп барганнар...

Сүүткәргечләр һәм канализация хуҗалыгы идарәсендә эшләр гадәти тәртип белән бара иде: язу машинкалары тыкылдый, телефоннар чылтырый. Коридор идәнендә, аркаларын стенага терәп, иренеп кенә тәмәке пыскытып, майланып беткән телогрейка кигән берничә ир-ат утыра. Алар яныннан биек үкчәле туфлиләре белән тек-тек басып, кәгазьләр тоткан, буялган тырнаклы кызыйлар үтеп йөри. Башлык, әлбәттә инде, кайдадыр киңәшмәдә, урынбасары — ялда. Ярты сәгатьләп көтеп утыргач, баш инженер Җиһаншин кабинетына үтә алдым. Дамил Дәүләтович мине дикъкать белән тыңлады. Бары бер урында гына: «Бер ел ук булмас, арттырырга яраталар инде бездә»,— дип куйды. Яңалык ачмыйм, димәк. Соңыннан, үз иткәнгә генә серне чишкәндәй, тәэсирле итеп, кыенлыклар турында сөйләп китте: акча аз, техника юк, эш хакы кечкенә, халык эшләргә атлыгып тормый...

Мин инде кызганудан елап җибәрергә җиткәндә, баш инженер киң күңеллелек күрсәтте: «Төзәтербез... Борчыласыгыз юк. Проект төзелгән. Акча бүленгән. Якын арада коллекторга ремонт төлгәлләнәчәк».

Белмәгән кеше өчен канцелярия теле (Корней Чуковский аны «канцелярит» дип атаган) үзе бер табышмак... Син әле ремонтны башлау турында кайгыртып йөрисең, ә сиңа аның төгәлләнәчәге турында сөйлиләр! Хәер, бәлкем, аларның кәгазьләрендә ремонт инде бөтен көчкә барадыр, шактый гына күләмдә акча да «үзләштерелгәндер». Әмма мин вакчылланып-төпченеп тормадым. Бары «якын арада»ны ничек аңларга икәнен ачыклый төшүләрен генә үтендем. Гади телгә күчергәндә, бу — бер ай эчендә, күп булса, ай ярымда була икән. Җитәкче иптәшнең авызыннан шул сүз чыгу белән, «егетләрчә килешү» тәкъдим иттем: шушы срок үткәнче үземнең «ачышым» турында берни

язмыйм. Әгәр дә мәгәр инде... Ул чагында үпкәләштә[…] булмасын. Редакция белән килешеп куелган. Дамил Дәү[…] ләтович, елмаеп, кулын суза. Елмаюы, шулай да, чыты[…] рак килеп чыкты...

Намазга йөрүчеләр интекмәсен дипме, бер рәхмәт яу[…] гырысы «инеш» аша салып куйган басманы искә алмаган[…] да, бер айдан да, ай ярымнан да Мәрҗани мәчете янын[…] да нинди дә үзгәреш күзәтелмәде.

Тагын ай ярым үткәч кенә (минем материал, инде ка[…] бул ителеп, редакцияләнеп, чыгарга чират кына көтә иде) чыбыксыз телефон кеше әйтеп кеше ышанмаслык хәбә[…] китерде: мәчет янындагы «чишмә» акмас булган. Берни[…] чә минуттан бу гаҗәеп хәл булган җиргә чабып килеп җиттем. Һәм — аһ иттем. Асфальттагы өр-яңа «ямау[…] лык» һәм юлның өслегендәге күрән таплардан гайре, үзем ачкан географик аномалия турында искә төшерерлек бер[…] ни дә калмаган иде.

Шулай итеп, бу кушылдык, борынгы романнарда языл[…] ганча әйтсәк, көтмәгәндә барлыкка килеп, көтмәгәндә юк[…] ка да чыкты. Әмма бер табышмак шулай да калды: ава[…] рияне бетерү өчен бер атна вакыт җиткәчтен, Кабанны ел дәвамында нәҗес суы белән агулау ни пычагыма ки[…] рәк булды икән?

ИКЕНЧЕ кушылдык Кабанга каршы яктан коя. «Ди[…] намо» су станциясенең такта идәне астыннан үтеп, яңгыр суы юлының бетон улагыннан «тәти генә» агып төшә ул. Бу кушылдыкның очына чыгуы җиңел булмады. Монда да махсус телдә «хозфекаль» дип йөртелгән су акканлыгы беренче карауга, дөресрәге, беренче сулышка ук сизелеп тора иде. Тик каян агып килә ул? Канализация суы яңгыр суы юлына, гадәттә, канализация челтәрендә авария бул[…] гач эләгә. Кабан тирәсендәге бөтен урамнарны йөреп чык[…] сам да, бернинди «чыганак» тапмадым.

«Динамо» станциясендә эшләүчеләр, йөз чытып, кул[…] гына селтәделәр:

— Монда гел шул инде — ага да ага. Бәлкем, ун, бәл[…] кем, егерме елдыр, кем белгән аны... Ничек инде: исебез китми? Шалтыраттык та, яздык та... Аннан күнектек тагын. Барыбер берни үзгәрәсе юк ич!

Әйе, кәеф шәптән түгел иде егетләрнең. Кабан күле төбенә хәтле череп беткән, секцияләр таралган-таркалган диярргә була, яшьләр килми. Алар станция менә ябыла, менә ябыла дип яшиләр һәм үзләренә эш хакы түләүлә[…] ренә чын-чынлап аптырыйлар иде.

Водоканалга шалтыраттым. Дежур диспетчер «автор-лык»тан катгый рәвештә баш тартты:

— Без түгел бу. Ул районда безнең тулы тәртип... Әйе, элек чыннан да аккалый иде. Соңгы вакытта ник бер жалоба килсен. Үзегез тикшерә аласыз...

— Әмма каян да булса ага лабаса.

— Яңгыр суы юлы дисезме? Димәк, кайдадыр яңгыр суы җыелган... Ис дип инде... бәлкем, кайдадыр бәдрәфне яки юынтык чокырын юдырып киткәндер. Ә бәлкем, әле берәр завод-фабрика мыштым гына канализация суын агызып ятадыр?.. Чистарту трестына мөрәҗәгать итеп карагыз.

Шәһәрне чистарту трестында минем белән сөйләшеп тә тормадылар. Санэпидстанциягә мөрәҗәгать итәргә туры килде. Коммуналь бүлек мөдире Мария Алексеевна Калашникова яңгыр суы гына түгелдер дигән шигемне раслашты. Әмма Водоканалны да хаклы дип тапты: шикаятьләр, чыннан да, килми башлаган, урамнарның санитар хәле дә шактый яхшырган. Гафу үтенде: эшем күп, берни белән дә ярдәм итә алмыйм. Шулай да, әйбәт кенә киңәш бирде үзе: кыш җиткәч, пычрату чыганагын астан чыгып торган пар буенча табып булачак.

...Һәм менә сүрән, болытлы декабрь иртәсендә серле кушылдык буйлап барам. Икеләнми-нитми атлыйм, чөнки су асты инешен каплап торган плитәләр урыны-урыны белән кузгатылган, тимер рәшәткәләрдән генә түгел, ярыклардан да пар һәм... сасы ис бөркелә. Свердлов һәм Айдинов урамнары кисешкән җирдә ул шундый да куәт ала ки, троллейбус тукталышындагы кешеләр аптырап як-якларына караналар. Башы эшләгәннәре рәшәткәләрдән читтәрәк торырга тырыша.

Дөресен әйтим, бу... миңа бик тә таныш ис булып чыкты. Өч ай элек тә, алты, тугыз ай элек тә борын шәрифләребезне ярып кергәне булды аның. Я, ис килеп тора, шуннан ни? Гүя ул шулай булырга тиеш тә инде. Әйбәткә күнеккән кебек, начарга да тиз күнегә икән кеше дигәнең. Бигрәк тә, үзенә бик үк кагылмаса!...

Уңга борылып, ис тәмам беткәнче барам. Яңгыр суы юллары да коры — йонлач бәс сармаган. Вәт хикмәт, ни булып чыга инде бу? Кире борылып кайтам, һәрбер ишек алдына кереп чыгам, өй арты өйне тикшерәм — эз-фәлән юк кына бит. Эзләнүләрне киңәйтә торгач, ниһаять, инде канализация хезмәте кешеләре уратып алган, авария булган җиргә юлыгам.

Отбой чүкече дөпелди, буы чыгып торган кара чокыр-

дан сасы шулпа суыртучы помпа тырылдап эшли. Пычрак сыланган телогрейка кигән, шәлләрен кашларына ук төшереп бәйләгән апалар лом һәм көрәк тотып эшлиләр. Ис, пычрак, эледән-эле чәчрәгән тамчылар, бозланып каткан кием... Турысын әйтик, кызыгырлык эш түгел.

Чокыр өстендә басып торган төксе генә ир кешене баш дип табып, сак кына сүз кушам: күлгә «Динамо» станциясе янында агып төшә торган су асты елгасы шушында башланмыйммы?

Агай өнәмичә генә мине күзләре белән баштанаяк сөзеп чыга:

— Ә сезне кем дип белик?

Аңлатам.

— Юк,— ди агай теләр-теләмәс кенә.— Моннан башланмый.

Безнең сөйләшкәнгә майланып беткән спецовка кигән яшь кенә егет тә колак салып тора. Моторчы, күрәсең. Сүзнең ни турында барганын белгәч, рәхәтләнеп сүзгә кушыла:

— Кабанга акмый, тагын кая аксын? Тик «Динамо» турысында түгел, Вахитов күпере янына агып төшә... Монда андый кушылдыклар!..

— Ә нигә, нигә соң алай?

Абзый авыз иҗатына караган сүзләр сериясе әйтеп ташлый, аларның мәгънәсе, гади телгә күчергәндә, шуңа кайтып кала: шәһәрнең бу өлешендәге канализация инде әби патша заманында ук салынган, рәтләдең ни, рәтләмәдең ни.

— Коллекторның тузуы бер хәл,— дип аңлата миңа егет.— Көче җитми аның.

— Мин монда Кабан күленнән үк килдем. Ярты көн йөрим, бер генә авария урыны да күрмәдем.

Егеткәй белән абзый мәгънәле генә карашып алалар. Абзый, «ни булса да булыр!» дигән сыман, кул селтәп алды да:

— Ярты куй, корреспондент, куйсаң, серне чишәм! — диде.

Шаяртуга бормакчы булам. Әмма агай шаяртырга уйламый да — сүзнең кызыгы беткәнгә санап, борылды да китеп барды. Егет исә, күз кысып, читкә чакыра. Йомычка белән җиргә гади бер схема сыза:

— Менә сезгә канализация коллекторы. Ике метр ярым тирәнлектә. Ә менә яңгыр суы юлы. Ул өстән, тротуар астыннан ук үтә. Коллектор агынтыларны чистарту корылмаларына куа, яңгыр суы Кабанга ага. Хәзер мен

монда күз салыгыз. Элек ничек иде? Коллектор, төп-төзек булган хәлдә дә, кинәт нык арткан агымны үткәреп бетерә алмый. Әмма дә ләкин төзек вакыты булмый да аның. Нигәме? Чөнки, проект буенча, ул яртылаш кына тутырылырга тиеш, ә без аны шыплап тутырабыз. Агынтылар, канализация капкачларыннан ташып, күлдәвекләр хасил итә, урам буйлап ага. Пычрак, сасы. Халык жалу арты жалу сырлый. Бу хәлдән гарык булган безнең начальствобыз, беләсезме, ни уйлап тапты? Коллекторны яңгыр суы юлы белән тоташтырды. Хәзер агынтыларның бер өлеше гадәти юлдан, икенче өлеше Кабанга ага. Коллектор тыгылса да, куркыныч түгел — тулаем яңгыр суы юлыннан сыптыра. Кабанга нәрсә — Кабан болай да пычранып беткән, артыгын пычрана алмый. Аның каравы, безнең тулы тәртип... Өске якта диюем.

Егет, сүзләренең тәэсиреннән канәгать калып, көлеп җибәрде. Ләкин фамилиясен әйтүдән баш тартты — билгесез калуны хәерлерәк санады.

Шуннан соң ни булдымы? Шәһәр башкарма комитетында да, санэпидстанциядә дә мин сөйләгәннәргә бик җитди карадылар. Энәсеннән җебенә кадәр тикшерергә, очына чыгарга вәгъдә иттеләр. Миннән исә фаш итүләр белән ашыкмауны, шау-шу куптармауны сорадылар.

Чыннан да, телефон көн саен диярлек яңа хәбәр җиткереп торды. Егетнең сөйләгәннәре тулысынча расланган. Санитария нормаларын тупас бозу бер ай эчендә төзәтелгән. Гаеплеләр каты җәзага тартылган. Дөрес, аларның фамилияләрен әйтмәделәр миңа. Тик фамилиядәмени хикмәт — көннәрнең берендә «Динамо» станциясе астыннан үткән агым юкка чыкты. Әйтерсең, бөтенләй булмаган да! «А. Айдинов» тукталышында сасы ис килми башлады. Бактың исә булган канализация челтәре белән дә яңа магистраль-коллектор төзүгә миллионлаган сум тотмыйча да (элек мәсьәлә нәкъ менә шуңа килеп терәлә иде) шакшыны күлгә агызмаска мөмкин икән. Моның өчен Спартак, Луковский, Свердлов урамнарындагы коллекторларга әледән-әле профилактик чистарту гына үткәреп торырга кирәк булган.

Берничә айдан бу искитмәле уңганлыкның да сере ачылды. Шәһәрнең чисталыгын һәм төзеклеген тикшерү өчен югары комиссия көтелгән икән. Ул елны Казан төзеклек буенча Россия Федерациясе шәһәрләре арасында беренче урынны алды. (Дөресен генә әйткәндә, безнең Казаннан чистарак калаларны да күрергә туры килгәләде миңа.)

ӨЧЕНЧЕ, ДҮРТЕНЧЕ һ. б. кушылдыкларның да

үз чишмә башлары бар иде. Элеккеге Жданов урамындагы «А» кварталында канализация коесы иңгән. Һәм... Ботаник, Һади Такташ урамнарындагы, Ерак урамдагы күпкатлы йортларның бөтен хозфекаль агынтылары Кабанга агызыла башлаган. Шаляпин урамында да шундый ук хәл.

Елгачылар больницасы территориясендәге канализация коллекторында булган зур аварияне әле бетерү өчен түгел, кем бетерергә тиешлеген ачыклау өчен генә дә елдан артык вакыт кирәк булды. Водоканал, коллекторның бүлеше елга порты балансында, дип тәкрарлады. Порт исә, ремонтны мех берләшмәсе ясарга тиеш, дип саный иде. Монысы тагын Водоканалга «шудырмакчы» булды. Чынлыкта, Водоканал ремонтларга тиеш булып чыкты да. Ләкин шул вакыт эчендә күпме су акты. Сасы су!

Инстанцияләр буйлап йөрүләрем бөтен кешенең дә күңеленә хуш килә иде дип әйтә алмыйм. Килүемнең максатын белгән күпме җитәкче иптәш биш кенә минут вакытын да минем мәсьәләгә багышлый алмаслык дәрәҗәдә мәшгуль булып чыкты! Теге яки бу объектның смета документлары белән танышу, аны файдалануга тапшыру срогы, җаваплы кешеләрнең фамилияләре кебек гап-гади мәгълүматлар алуның да никадәр кыен, четерекле эшкә әйләнүен белсәгез икән!

Бер тапкыр шулай, исәпсез-хисапсыз киңәшмәләрнең берсендә, шәһәр канализация хезмәте башлыгы белән рәттән, шагыйрь әйтмешли, «туры килде минем урындык». Җитәкче иптәш, карашын читкә төбәп, төксе генә сөйләп китте:

— Менә сез язасыз, чыгышлар ясыйсыз, тәнкыйтьлисез. Игелек эшлим дип уйлыйсыз инде. Ә бит, төптәнрәк тикшереп карасаң, сез — эшкә комачау гына. Нигәме? Хәзер аңлатам. Менә сез санэпидстанция китерттегез, чебеннән фил ясадыгыз. Хуш, бәхәсләшмим, фактлар дөрес. Әмма бер без генә алай эшләмибез ләбаса... Сезнең чыгыштан соң безне призлы урыннан мәхрүм иттеләр, бөтен персоналның премиясен кистеләр. Бездә күпме алалар дип уйлыйсыз?.. Белмисез шул, хикмәт тә шунда. Халык эш хакының премияләр исәбенә бераз адәм рәтенә керүенә күнеккән иде инде. Премиясез аларны монда аркан белән дә тотып булый. Нәҗестә казыну рәхәт мәллә? Болай да кеше җитми — тагын уннарча кеше дәррәү гариза тотып килде. Коллекторлардагы ул аварияләрне кем бетерер дип уйлыйсыз? Алкашлар белән генә әллә ни майтарып булмый шул...

1980 елның 17 маенда Казан шәһәр Советы башкарма комитеты «Кабан күлен пычратуларны булдырмау чаралары турында» карар кабул итте. Үзтәнкыйтьле, гаепле кешеләрне атап күрсәткән, кем кайчан нәрсә эшләргә тиешлеген төгәл билгеләгән үткен һәм дөрес карар иде бу. Башкарма комитетка турыдан-туры буйсынган идарәләргә кагылышлы ике генә пунктны китерәм:

«...Сусүткәргеч-канализация хуҗалыгының производство идарәсе башлыгы вазифаларын башкаручы ип. Г. А. Арутюновка 1980 елның 1 августыннан пычрак агынтыларны Кабан күленә агызуны туктатырга.

...Башкарма комитетның төзекләндерү идарәсе начальнигы ип. Г. М. Цышевскийга 1980—81 елларда яңгыр суларын Кабанга агызу алдыннан тондыру бассейннары төзү өчен документлар проектын эшләргә һәм 1982 елда аларны төзүне тәэмин итәргә.»

Алты елдан соң, 1986 елның көзендә шундый ук яңа карар кирәк булды, бу юлы — ТАССР Министрлар Советыныкы. Анда элекке карарның үтәлмәгәнлеге ап-ачык әйтелгән иде.

Хәзер инде 1986 елгы карарның үтәлмәве турындагы яңа карарны көтәргә кала...

ТӨГӘЛЛӘНҮНЕҢ БАШЫ

> «...Казан елгасыннан баксаң, тау шундый биектер, башны чөеп каравы да кыен. Тау башында шәһәр: патша сарайлары, галәмәт биек таш мәчетләр торыр...»
>
> *Андрей Курбский, XVI гасыр.*

Җир асты чишмәсенең сере.
Казанның су муенсасы.
Беренче реконструкция.

Камалыштагы Казан халкы су алган җир асты чишмәсе турында өлкән яшьтәге казанлылар арасында әле дә төрле имеш-мимешләр йөри. Риваятьләр дә бар.

Камаучылар качып чыккан сатлык җаннан чишмәнең кайда икәнлеген беләләр дә, шартлаталар. Елъязмачылар язып калдыруынча, бу хәл казанлыларны «зур кайгыга сала». Шакшы су эчүдән алар арасында төрле кизүләр баш-

лана. Кешеләр «кубенә иделәр һәм үлә иделәр». Калан
язмышын шактый дәрәҗәдә энә шул хәл итә.

Бу чишмә XIX гасыр башларына кадәр саклана,
күп тапкырлар әдәбиятта да тасвирлана. Ул Кремль
варының тышкы ягында, Ленин районы күпереннән е
түгел, хәзер таш баскыч булган турыдарак бәреп тор
Суы Черек Болакка койган. Утыз меңлек гаскәр бе
тагын шул чама шәһәр халкы өчен асылда бердәнбер
су чыганагы була. Тикшеренүләрдән күренгәнчә, су Кре
тавы астындагы известьташлы катламнар аша үтеп к
гән. Чишмә суы чүлмәк торбадан шул тирәдәге Та
мунчасына да агып торган. Әле XIX гасырның бере
яртысында да моннан кыяр тозларга су ала торган булг
нар. Татар халкы бу чишмәне изге дип, барча чирләр
дә дәвалый дип санаган.

Нургали манарасыннан чишмәгә яшерен җир асты ю
үткән (шуңа да руслар әлеге манараны соңыннан «Т
ницкий» дип атаганнар). Сакланып калган таныкла
лардан күренгәнчә, юлның өсте таш гөмбәз белән ны
тылган булган. Таш баскыч текә генә аска төшеп ки
шәһәр дивары астыннан үтеп, чишмә өскә бәреп чыга т
ган урында туктап кала. Шул юл аша камалган шәһәр
дә чыгып булган.

Чишмә юлын шартлатыр өчен, диварларына ышык
нып, Таһир мунчасыннан икенче бер юл казый башлага
нар. Йөз сажинлап үткәч, суга төшүчеләрнең тавышла
ишетелгән, имеш. Шуннан соң берничә мичкә дары тә
рәтеп керткәннәр. Риваять буенча, мичкә өстендәге шәм
кабызгач, Иван Грозный чатырында да шундый ук шә
ут алалар. Чатырдагы шәм янып бетә, шартлау ишетел
Ярсыган патша шартлату остасының башын кисәргә б
ра. Аның башы патшаның аяк астына тәгәрәп төшүе
ла, көчле шартлау тавышы ишетелә. Патша җир асты
шәмнең начаррак януын исәпкә алмаган, имеш.

Тарихчылар, риваятьнең бу өлешен хыял җимеше ге
булырга тиеш, диләр. Чөнки шартлау эшләренә җитәк
лек иткән Бутлер атлы «немец» (милләте буенча ул
глиз булган, «немец» бу очракта чит ил кешесе дигән
генә аңлата) исән кала, балда-майда йөзә. Шартл
булган урыннан ерак түгел хәзер әлеге Бутлерн
оныкларыннан берсе бөек химик А. М. Бутлеровка һәйк
тора.

Кагыйдә буларак, шәһәрләр кальгадан (крепостьта
түгел, ә бәлки тышкы шәһәрдән башлана. Тарихчылар б
нең Казан да эчәргә суы да булмаган Кремль тавынн

түгел, аның Черек күл ягындагы итәгеннән башланган, халык иң әүвәл шунда килеп утырган дигән карашка күнә баралар. Черек күл, Мунча күле, Пычрак күл һ. б. лардан торган күлләр тезмәсе турында күпләрнең ишеткәне бардыр. Ә менә күлләр түгел, буалар булып, аларны берберсеннән өеп ясалган дамбалар аерып торуын сирәк кеше беләдер. Буалар агымсулы була, су югарыдагысыннан түбәндәгесенә улаклар яки чүлмәк торбалардан агып төшә.

Геология-минералогия фәннәре кандидаты Е. Станкевичның тикшеренүләреннән күренгәнчә, бу тирән батынкылыкта борын заманда эрәмәлекләр басып киткән уйсулык булган, аны инеш ярып үткән. Инешне уң кул якта тибеп торган күпсанлы чишмәләр туендырган.

Шушы инеш һәм чишмәләр, соңыннан — буалар, шәһәр үсешенең беренче чорында аны су белән тәэмин итүнең төп чыганагы булган да инде. Казан халкы арта барган саен, күлләр дә ныграк пычранган. Күл исемнәре әнә шул хакта сөйли.

Пычрак күл... Иң астагы бу күлнең мәйданы ун гектардан артык була. Күл, дөресрәге, аның урынында калган баткак уйсулык (Батурин урамы тирәсе) безнең гасыр урталарына кадәр килеп җитә һәм бары Куйбышев сусаклагычы төзелгәч кенә тәмам юкка чыга. Ул, мөгаен, Казан елгасының иске эзедер: ләм һәм торф катламыннан күренгәнчә, заманында шактый тирән булган. XV гасырга күл шулкадәр пычрана ки, суы малга эчерергә дә ярамый башлый һәм бары Кремльнең төньяк-көнчыгыш өлешен сакларга ярдәм иткән табигый тоткарлык буларак кына күпмедер әһәмияткә ия була.

Мунча күле... Исеменнән үк күренә ки, тирәсендә мунчалар тезелеп киткән була. XVI гасыр урталарында сан алу кенәгәләренә теркәлгәнчә, күпләгән хосусый мунчалардан тыш, монда зур бер казна мунчасы да булган. Ул заманнарда әле күбесенчә селте белән юынсалар да, бу күл дә аз-азлап пычрана бара һәм XVI гасырда шулай ук Пычрак күл (Югары Пычрак күл) дип йөртелә башлый.

Югары Пычрак күл катлам ашалу-юылу юлы белән хасил булган дигән фикер бар. Инде тәмам сасып беткән күлне 1886 елда күмәләр. Күп тә үтми, бу урында янадан уенты барлыкка килә, янадан су җыела. Күл, әйтерсең лә, үләргә теләми. Шәһәрдә бу хәл турында акылга сыймаслык сүзләр йөри... Күл үзен соңгы мәртәбә безнең көннәрдә сиздереп куйды: катлам юылу сәбәпле, Ленин урамындагы Пассаж бинасының төньяк өлеше ишелеп төште.

Черек күл... Н. М. Минһаҗева исәпләүләреннән күре
гәнчә, бу күлнең дә мәйданы ун гектар чамасы булга
Шулай итеп, буалар системасының гомуми мәйданы Юг
ры Кабанныкыннан зуррак булып чыга. Черек күл тир
сендә җирне бораулагач, аның культуралы катламы гаят
зур булуы, егерме, урыны-урыны белән утыз метрга җ
түе беленде. (Кремль тавында исә ул нибары ике-өч мет
лап кына.) Күрәсең, бу шәһәрнең кеше иң тыгыз утырга
үзәк өлеше булгандыр...

Черек күлне *Чишмә күленнән* агып торган инеш туе
дырган.

Зур булмаган бу күл хәзерге Красин урамы тирәсе
дә, ягъни Черек күл батынкысының ян ягында була. Чи
мә күленең суы аеруча тәмле булган, аны ипи салырга то
каннар, дигән риваять бар. XVI гасыр урталарына ул пы
ранып бетә. Бу күлне 1774 елда күмәләр.

XVI гасырда чагыштырмача чиста булып чылбырны
өске буыны — соңыннан Николай күле дип йөртелгән *Чи*
та күл генә кала. Күл тирәсендә тимерче һәм чүлмәк
алачыклары торган, бу да аның пычрануына китергә
Яшерен чишмә шартлатылгач, камалыштагылар су
шуннан алырга мәҗбүр булганнар һәм хәзерге фотоател
турындарак торган камау манарасыннан атулардан уна
ләп-йөзәрләп кырылганнар... Күлне 1812 елда, бүтән мә
лүматлар буенча, 1842 елда күмгәннәр.

Хәзерге Ирек мәйданы тирәсендәрәк Черек күл сист
масына кермәгән тагын бер күл булган. Элекке исеме бе
нең чорга килеп җитмәгән, соңрак аны *Бассейн* дип (якы
дагы Бассейн урамының исеме шуннан алынган) як
Театр мәйданы исеме буенда, *Театр күле* дип атап йөр
кәннәр. Аны да чишмәләр туендырып торган. Арткан с
Касаткин урамы буйлап Казан елгасына агып торган. М
нысын XIX гасыр уртасында күмгәннәр.

Әлеге күлләрнең язмышы безгә, хәзерге буынга, гый
рәтле бер кисәтү булып тора.

Шәһәр дивары яныннан ук Болак агып торган, ул
Казан халкын су белән тәэмин итүдә зур роль уйнага
Болакның уң ягында тыгыз урнашкан Түбән тышкы ш
һәр, сулда Кыраиш бистәсе булган. Болактан төрле-төр
кярханәләр су алган, тотылган суны да Болакка түккә
нәр.

Археологлар Кремль тавында агач улак таптыла
Улак хан сараеннан, Кремльнең башка җәмәгать коры
маларыннан Болакка таба сузылган. Күрәсең, Казанда
беренче «канализация коллекторыдыр» бу. Шәһәрнең тө

әлеше, әлбәттә, мондый «уңайлык»тан мәхрүм була, бөтен пычрак агынтылар ачык канаудан шул ук Болакка яки Черек күл батынкысына агып тора. Менә шуңа Болак инде XV гасырда ук, эчә торган су чыганагы булудан туктап, асылда дренаж һәм канализация канавына әйләнеп кала. Әмма хикмәт пычрануда гына да түгел.

Соңгы елларда үткәрелгән тикшеренүләр шуны күрсәтә: күлләр тирәсендәге үтеп чыга алмаслык карурманнар инде XIII—XIV гасырларда ук тулысынча диярлек кисеп бетерелә, җирләре сөрелә. Шуның нәтиҗәсендә Кабанны туендырып торган иксез-чиксез инешләр, ермаклар, сазлыклар, чишмәләр башта зәгыйфьләнә, аннан бөтенләй кибеп бетә. Бу хәл Болакның да саегуына китерә. Болак ул заманда мөһим транспорт юлы була бит: кораблар Иделдән һәм Казан елгасыннан аның аша Якын һәм Урта Кабанга рәхәтләнеп үтеп йөриләр.

Болак суы элек-электән берничә тегермәннең ташларын әйләндерә торган була. Ике тегермән сан алу кенәгәләренә дә теркәлгән, берсе хәзерге пединститут бинасы янында, икенчесе Болак тамагында булган. Көймәләр үтеп йөри алсын өчен махсус шлюзлар да төзелгән. Шлюзларда су тирәнлеге ике метрдан да ким булмаган, бу исә шактый зур Идел корабларына да керергә мөмкинлек биргән...

Шәһәр үскән саен, Болак саега, аның төбенә ләм утыра — пычрана бара. Болакның Кремль дивары яныннан ук агып үткән бер тармагының исемен генә искә төшерик: Черек Болак.

Болак ярына мунчалар сырышкан. Аларның иң данлыклысы булган Таһир мунчасы элекке чыганакларда кат-кат телгә алына. Ул борынгы болгар мунчалары үрнәгендә төзелә, идәне җылытыла, гөмбәзләре биек ителә, бассейннары, фонтаннары була, балчык торбалардан суның салкыны да, кайнары да килеп тора, махсус «калорифер»дан кайнар һава бирелә. Ял итү өчен шәп кенә җиһазланган махсус бүлмәсе дә була. Таһир мунчасына югары катлау йөри, алар өчен бу үзенә күрә клуб була: яңалыклар алмашалар, мөһим мәсьәләләрне хәл итәләр, җыр-музыка, шигырь тыңлыйлар.

XV гасыр азагына Болак нык кына саега, Кабан күле буендагы Әрмән бистәсенә һәм башка торак пунктларга көймәләр үтү кыенлаша. Елганы чистарту, тирәнәйтү ихтыяҗы туа. Һәм менә XV—XVI гасырлар чигендә Болакка беренче реконструкция үткәрелә. Төньяк урманнарыннан куып китерелгән «меңнәрчә чирмеш» һәм көньяктан

килгән нугайлар, хан назирләре күзәтчелеге астында, яңа су юлы казып, Болакны турайталар. Тышкы шәһәр әйләнәсен дивар белән уратканда Болак ярын бурап ныгыталар, төбен ләмнән арындырып, имән ярка түшиләр. XIX гасырда булган зур янгын вакытында метр ярымлы ләм катламы астыннан көтмәгәндә әнә шул иске, әмма әле нык имән түшәмә килеп чыга.

Елъязмалардан реконструкциянең хосусан хәрби максатта үткәрелүе күренә — Болак кальганың ур чокырына әйләндерелә. Дренаж ягы да күздә тотылгандыр: инешнең түбән, баткак ярлары буендагы урамнар пычракка, мәңге кипмәс күлдәвекләргә күмелеп утыра торган була, Болакны тирәнәйткәннән соң аяк асты кипшерә төшә. Әлбәттә инде, көймә йөртү өчен дә шартлар яхшыра.

Болак турында князь Андрей Қурбский болай дип яза: «...Қөнчыгыш тарафтан — Қазан елгасы, көнбатыш тарафтан Болак атлы инеш агып торыр, бик тә ләмле-лайлы вә кереп булмаслык, шәһәргә терәлеп агып, почмак манара эргәсендә Қазан елгасына кояр, үзе Қабан дигән күлдән агып чыгар, күл кечкенә булмастыр, каладан ярты чакрымда торыр». «Бик тә ләмле-лайлы вә кереп булмаслык» дигәндә Қурбский зур Идел кораблары керә алмауны күздә тоткан булса кирәк, ник дисәң, көймәләр Болак буйлап XX гасырның 20 нче елларына кадәр йөреп торганнар.

Қешенең яман тәэсире эчке сулыклар һәм Болакта гына түгел, шәһәргә терәлеп торган табигатьтә дә чагыла. XVI гасыр башларында Қазан янындагы тугай (Хан болыны, рус елъязмаларында — Царев луг) карап туймаслык була. Анда сабан туйлары, башка бәйрәмнәр үтә. «Қазан елъязмачысы» болай дип яза: «Болактан Идел тарафынача искитмәле, күркле вә олуг Патша болыны җәйрәп ятыр, җиде чакрымнар булыр, мул үләнгә күмелеп ямьяшел булып утырыр, төрледән-төрле чәчәкләр атар...» Борынгы документлардан ханның ат абзарлары өчен бу тугайдан дисәтинәсеннән утызар чүмәлә печән чабып алынганлыгы мәгълүм. Әмма гасыр азагына, Болак аръягында Татар бистәсе барлыкка килгәч, тугай табигый матурлыгын җуя, чүп түгү урынына әйләндерелә. Соңрак әлеге урын чын-чынлап шәһәрнең нәҗес чокырына әверелә, бу бәладән бары Қуйбышев сусаклагычы гына «коткара»: болын су астында кала.

Қабан күле Қазаннан читтә булса да, аның тирәсендә авыл һәм бистәләр шактый күп була.

Якын Кабанның көньяк-көнбатыш ярында (хәзерге Татарстан һәм Париж коммунасы урамнары тирәсе) — ул заманнар өчен шактый зур таш мәчет (сан алу кенәгәләренә Үтәш мәчете дип теркәлгән) торган Кыраиш бистәсе. Төньяк ярда (Свердлов һәм Калинин урамнары тирәсе) — Әрмән бистәсе, анда Әрмәнстаннан килгән осталар — ташчылар, тимерчеләр, зәркәннәр (ювелирлар) һ. б. яши. Археологлар бу урында христиан храмы, әрмән зираты калдыклары табалар. Бераз арырак, хәзерге зоопарк тирәсендә, Колмәмәт дигән татар бистәсе була.

Каршы ярдагы Пләтән дигән зур бер авылның исеме, Казанның шул төбәгенә берегеп, бүгенге көннәргәчә килеп җитте. Урта Кабандагы кала турында әйтеп үткән идем инде.

Кабан күлләре тезмәсе, шул исәптән, якын Кабан да XVI гасырга матурлыгын һәм чисталыгын саклап калган була әле. Әмма беренчел, табигый сафлык түгел инде бу. Кабанның суын эчәләр, төрле хуҗалык ихтыяҗларына тоталар, мал сугаралар, яшелчәгә сибәләр. Һәм... алдын-артын уйлап тормастан, Кабанга ук чүбен-тиресен түгәләр, юынтык су агызалар.

Болак кебек үк, Кабан да мөһим су юлы була. Күл буендагы күп санлы торак пунктлар арасындагы алыш-биреш, авыл хуҗалыгы продуктларын — шәһәргә, һөнәрчелек әйберләрен авылларга илтү рәтле юллар булмаган ул заманнарда тулысынча диярлек елгачыларга йөкләнә. Балык тоту, сал агызу да бар бит әле. Бу — гади саллар, чокып ясалган көймәләр генә булган дип уйлаган кеше ялгыша. Хәрби походлар, борынгы Казанның сәүдә бәйләнешларының елъязмалардагы чагылышына караганда, Идел, Казан суы, Болак, Кабан күлләре буенча төрле-төрле көймәләр йөргән. Кайберләренең озынлыгы 12—14 метрга җитә, аларда җилкән һәм уникешәр ишкәкче булган. Бер һәм ике мачталы корабларда йөзәр пассажир, 30—100 тонна йөк йөртелгән.

Мондый зур суднолар «ләм баскан вә керә алмаслык» Болактан ничек үткән соң? Йөк корабларының Болактан XIX гасыр башларынача йөрүен белгән хәлдә, бер фаразга урын кала: русларның Казанга походы алдыннан казанлылар Болакны махсус шундый хәлгә китергәннәрдер. Моның өчен буаларны ерып суын агызырга гына кирәк ләбаса.

Риваятьләргә караганда, хан һәм аның яраннары Урта Кабан буендагы җәйге резиденциягә бик зиннәтләп эшләнгән махсус көймәләрдә барганнар. Әнә шундый көй-

мәләрнең берсендә Сөембикәне[1] Мәскәүгә алып китәләр. «Казан елъязмачысы» бу турыда болай язган:

«Аны алдан хәстәрләнгән патша көймәсенә алып керделәр. Ушбу көймәдә элгәре патша сафа кылырга йөргәндер. Бик тә тиз, очкан кош кеби барыр иде, бәгъзе урыннары алтын вә көмеш берлән бизәлгәннәрдер. Көймә уртасында пыяладан, янып торган фонарь кеби тирмә эшләнгәндер, алтынлы такталар белән ябылгандыр, анда патшабикә утырыр иде, патшабикәгә юанычка воевода тагын 70 хатын һәм вә күрекле утыз кыз алганнар иде — асыл зат нәселдән, патшабикәне түшәккә хаста килеш салганнар иде».

Мондый «очкан кош кеби» тиз йөрешле кораблар ясар өчен судно төзү эше югары дәрәҗәдә булырга тиештер... Хәер, Көнчыгыш Европаның төп сәүдә юллары чатындагы шәһәр өчен бу бер дә гаҗәп түгел.

Шулай итеп, Кабанның соңгы мең елда кешенең интенсив хуҗалык эшчәнлеге сферасында булуын икеләнми әйтергә мөмкин. XIII—XIV гасырлар чигендә, болгарлар күпләп күчеп килә башлагач, бу тәэсир аеруча көчәя.

ТАГЫН ХӘЗИНӘ ТУРЫНДА...

«Бездә — татарларда... әкият вә җырлар булганнар вә... халык арасында хәзергә кадәр риваять ителеп киләдер».

Ф. Әмирхан

Яшерер хәзинә булганмы?
Казанда сугылган тәңкәләр кая киткән?
Хәзинәне алып чыгу мөмкин булганмы?

Кабан күле турында мәгълүмат җыйганда, ханнар хәзинәсе турындагы легенданың иң борынгы язмаларын да эзләдем. Бик озак эзләдем. Ни гаҗәп, алар табылма-

---

[1] Сөембикә — соңгы ике Казан ханы Җан Гали белән Сафа Гәрәйләрнең хатыны, нугай морзасы Йосыфның кызы. Казанга 1532 елны китерелә. Гаҗәеп чибәрлеге белән, аннан да битәр зирәклеге белән дан тота. Халык арасында абруе, йогынтысы зур була.

Сөембикә турында риваятьләр күп. Кремльдәге манара аның исеме белән аталган. Безнең көннәргә килеп җитмәгән бай китапханә һәм Кабан күле буендагы бакча да аның исемен йөрткән. 1551 елда Казан янына йөз меңле гаскәре белән Иван IV килеп җиткәч, канлы бәрелешне булдырмый калу һәм дә вакыт оту, шул ук вакытта көчле генә тәхет дәгъвачысыннан да котылу өчен, Казан морзалары Сөембикәне русларга бирәләр. Бәләкәй улыннан аерып, әсир итеп, аны Мәскәүгә алып китәләр.

ды. Бер-берсен инкарь итүче аерым истәлекләр генә бар иде. Бу — легенда түгел, гаилә риваяте дию белән Әҗем карт әллә хаклы булды инде?

Чыннан да, легенда — халык авыз иҗатының үз структурасы, сюжеты, образлар системасы булган проза жанрларыннан берсе. Күп кенә легендаларның нигезендә чыннан да булган, әмма хыял тәэсирендә үзгәртелгән вакыйгалар ята. Ә менә бу легенданың сюжеты да, образлары да, фантастик төсмерләре дә юк. Асылда бу — имеш-мимеш, тикшерелмәгән мәгълүмат кына.

Әмма «имеш-мимеш»нең гомере озын булып чыккан — ул дүрт йөз елдан артык яши бирә. Пугачев восстаниесеннән соң кайберәүләр Кабан төбендә яткан хәзинәләрне «Пугач патша килүдән куркып байлар яшергән» дип сөйли башлый. Октябрь революциясеннән соң, аны чит илләргә качкан байгуралаларга китереп бәйлиләр. Егерменче елларда нык кына баеп калган нэпманнар яшергән, дигән сүзләр дә йөри.

Хәер, боларның да реаль җирлеге булуы бик мөмкин. Кырык еллап элек, тәрбиячеләре белән Кабан буенда йөргәндә, бакча балалары яр буе комында алтын тәңкә һәм бизәнү әйберләре тулы чүлмәк табалар. Шундый башка табылдыклар турында да сүзләр бар, әмма аларның чынлыгын тикшерү мөмкин эш түгелдер инде.

Болак аръягы халкының ханнар хәзинәсенә ышанычы шундый зур була ки, НЭП елларында Остап Бендер кебегрәк бер җилкуар аны табу өчен акционерлар ширкәте дә оештыра. Фаш ителгәнче, күп кенә Казан нэпманнарының акча янчыкларын җиңеләйтеп тә өлгерә. Фатих Хөснинең «Алтын эзләүчеләр» повестеның сюжеты шул вакыйгага карый.

Моныңише һәр мәгълүмат җентекләп тикшерүгә, анализлауга мохтаҗ. Әйдәгез без дә, тарихи чыганакларга таянып, Әҗемов сөйләгәннәрдән соң туган кайбер сорауларга җавап эзләп карыйк.

БЕРЕНЧЕ СОРАУ: Казан ханлыгында яшерер мал булганмы?

Алтын Урда хәрабәләрендә калкып чыккан Казан ханлыгы Көнчыгыш Европаның иң зур мөстәкыйль дәүләтләреннән була. Хәзерге Идел буе татарларының бабаларыннан тыш, ул Урта Иделдәге күп кенә башка халыкларны да берләштергән. Рус елъязмаларының берсендә 1469 елда Казан ханы Ибраһимның «Үзенең бөтен илләре — Кама, Чепья, Костяк, Идел, Вотяк һәм Башкорт иле белән» яу чабарга җыенуы язып калдырылган. 1552 елда Казанны

алуда катнашкан воевода Андрей Курбский болай яза: «Ушбу патшалыкта татар теленнән гайре биш төрле тел бардыр: мордва, чуваш, чирмеш, вотяк яки ар телләре, бишенчесе башкорт теле булыр».

Әлбәттә инде, һәрбер феодаль дәүләттәге кебек үк, Казан ханлыгында хезмәт халкын аяусыз изү дә, авыр салымнар да, фетнә-чуалышлар да булган. Хан ялчыларының зур бер катламы казнага акча кертүне кайгыртып торган: ясак, гошер (пошлина) җыючылар, тамгачылар (таможнячылар), үлчәүчеләр, бахшилар (язу-сызу эшен башкаручылар) һ. б. Ханлыкта яшәгән һәрбер кеше исәпкә алынып, бер яки берничә төрле салым түләргә тиеш булган. Сәхип Гәрәй ярлыгында хан казнасына керә торган җыемнарның унөч төре саналган: ясак, салым (җан башыннан түләнә торган налог), клан (имана), сала хәреҗе һ. б. Шулай итеп, хан казнасына зур гына суммалар агылып торган.

Тарихтан беләбез: Мәскәү белән Казан дәүләтләре арасында феодаль сугышлар тукталып тормаган. Хәзер, ярты мең ел узгач, гаепләләрне эзләү, җаваплылык йөген теге яки бу халык иңенә салу ахмаклык булыр иде. Гади халык каны түгелсә дә, сугышны феодаллар игълан иткән. Иң элек ганимәт мал табу өчен алып барылган ул. Ганимәт исә аздан булмаган. Никон елъязмасында, 1551 елгы солых буенча, Казаннан Зөя аркылы 60 мең әсир алып чыгылуы теркәлгән. «Казан тарихы» авторы исә Казандагы рус әсирләренең санын йөз меңгә җиткереп түгәрәкли (тарихчылар фикеренчә, арттыра төшә). Казан ханлыгында әсирләрне кол буларак файдаланмаганнар. Бер өлешен, җир биреп, ясаклы крестьян иткәннәр, бер өлешен Кырым аша коллыкка сатканнар. Бу чыганак казна керемнәренең шактый өлешен тәшкил иткән, зур хәрби башлыклар, феодаль югары катлау — солтаннар, әмирләр, карачылар, шәехләр, имамнар һ. б. өчен менә дигән баю чарасы булган.

Әмма иң күп керемне сәүдә биргән. XV—XVI гасырларда Казан, Көнчыгыш белән Көнбатыш арасындагы актив транзит сәүдәсенең үзәге буларак, асылда борынгы Болгар урынын ала. Иделдәге утрауда (соңрак «Маркиз утравы» дип атап йөртелде, Куйбышев ГЭСы төзелгәч су астында калды) ел саен Көнчыгыш Европада иң зур ярминкә үткәрелә. (Тора-бара бу роль күпмедер дәрәҗәдә Нижний Новгород янындагы Мәкәрҗә ярминкәсенә күчә.) Монда Төркиядән — аш тәмләткечләр, Иранннан — китап, Урта Азиядән — чикләвек, йөзем, өрек, Әрмәнстаннан,

Шәмахадан (Азәрбайҗан) корал һәм бизәнү әйберләре, Ширваннан (Баку) — нефть, Көнбатыш Европадан кәгазь, дары китергәннәр. Казаннан исә затлы мех, кызыл балык, бал, икмәк, ат, күн аяк киеме һәм башка шуның ише әйбер алып киткәннәр.

Казанның төп сәүдәсе Русь белән барган. Шунысы игътибарга лаек: тыныч еллар һәр ике як өчен дә күп отышлырак булган. Бу хакта Р. Фәхретдиновның «Ташлар моңы» (Казан, 1986) китабында китерелгән бер факттан гына да нәтиҗә ясап була. Бервакыт казанлыларга үч итеп, аларның сәүдә багланышларын бозарга теләп, Мәскәүнең бөек князе Василий III рус сәүдәгәрләрен Казан ярминкәсенә барудан тыя. Әмма, Көнбатыш Европа сәяхәтчесе С. Герберштейн сүзләренә караганда, моннан Мәскәү күргән зыян казанлыларныкыннан ким булмый. «Чөнки, моның нәтиҗәсе буларак, Идел буйлап Каспийдан, Әстерхан базарыннан, шулай ук Ираннан һәм Әрмәнстаннан китерелә торган товарларга җитмәүчелек һәм кыйммәтчелек сизелде». Шул ук Герберштейн Казан җиренең икмәккә, мал-туарга, балга, балыкка, кыйммәтле мехларга гаять бай булын да әйтеп китә.

Ярминкә елга бер үткәрелсә, Казандагы Кәрвансарайда, Арча кырында, күп кенә башка базарларда сәүдә шаушуы тынып тормый. Мәскәү сәүдәгәрләренең Казанда үз кибетләре була, анда тукыма, тоз, корал, дирбия, балтапычкы, чалгы, энә, көзге кебек нәрсәләр сатыла. Шәрык сәүдәгәрләре исә Ширван ефәге, Димәшкъ корычыннан эшләгән кылыч-хәнҗәр, шәраб, тәм-том саталар. Читтән килгән сәүдәгәрләрнең санын шуннан да чамаларга була: сәүдә өчен кулай булмаган хәвефле 1552 елда, шәһәр ныгытмаларын рус гаскәрләре камап алгач, рус елъязмаларыннан күренгәнчә, казанлылар белән бергә анда биш мең чит ил сәүдәгәре: бохаралылар, шәмахалылар, төрекләр, әрмәннәр һ. б. да бикләнгән.

Хәрби һәм политик низаглар сәүдәгә зур зыян салган чаклар да булгалаган. «Казан елъязмачысы», әйтик, 1505 елда рус кибетләренең талануы турында яза: «Патша рус сәүдәгәрләренең барча кыйммәтле товарын, хисапсыз байлыгын үз казнасына алды, пулатын түшәменә кадәр рус алтын-көмеше белән тутырды». Ләкин бу хәл кагыйдә түгел, бәлки кагыйдәдән чыгарма гына булган. Ханнар гадәттә сәүдә кеременең уннан бер өлешенә канәгатьләнә торган булганнар, анысы да шактый суммага җыела бит.

Кыскасы, тарихчылар йөз елдан артык вакыт эчендә хан казнасында зур хәзинә тупланганлыгына шикләнми

лэр. Ханбикэ Сөембикәне 1551 елда Мәскәүгә озатканда князь Василий Серебряный төзегән исемлек әлеге байлыкның бер өлеше турында беркадәр мәгълүмат бирә. Ул вакытны Сөембикә белән «алтын-көмеш, алтын вә көмештән савыт-саба, зиннәтле урын-җир, төрледән-төрле киемнәр вә сугыш коралы төялгән унике зур көймә» алып киткәннәр. Күрәсең, бу Сөембикәнең шәхси милке булгандыр[1].

ИКЕНЧЕ СОРАУ. Яшерелгән хәзинәнең ниндирәк булуын безгә килеп җиткән чыганаклар буенча чамалау мөмкинме? Мин Әҗем картның Кабан төбендә акча сугу йорты байлыгы — алтын, көмеш тәңкәләр һәм коелмалар ятуы турындагы сүзен күздә тотам.

Казанда акча сугу йорты булганмы?

Сорау җиңелдән булып чыкмады.

Нумизматлар бер мәсьәләдә уртак фикердә торалар: Болгар дәүләтендә акча сугу эше нык алга киткән булган. Табылган күп санлы хәзинәләр шуны күрсәтә: тәңкәләрнең саны буенча да, сыйфаты һәм төрлелеге ягыннан да Көнчыгыш Европа дәүләтләренең бик азы гына борынгы Болгар белән ярыша алган. Р. Фәхретдинов фикеренчә, Алтын Урданың соңгы, Казан ханлыгының беренче чорында Урта Иделнең акча сугу үзәге элек Казан әмирлеге башкаласы булган Иске Казанга күчкән. Бер Светино хәзинәсендә генә дә 7779 тәңкә табылган. Шуларның 640 ында «Болгар әл җәдид», ягъни Яңа Болгар дип (ханлыкның яңа башкаласын ул чакта шулай дип атап йөрткәннәр), калганнарына — «Болгар» дип сугылган. Фәхретдинов, сугу үзенчәлекләре буенча, алары да иске Казанда чыгарылган дигән фикердә тора. Татар нумизматикасы буенча иң зур белгеч, берничә монография авторы Ә. Г. Мөхәммәдиев исә бүтән караштa. Ул хәтта «Болгар әл җәдид» тәңкәләре дә яңа Казанда сугылган дип бара: «Казан, кайбер тарихчылар фикеренчә, борын заманда башка урында булганмы, әллә юкмы, моңа бәйсез рәвештә, XV гасырда эшли башлаган акча сугу йорты хәзерге Казан урнашкан җирдә булган[2]».

Фикерләрнең тегесендә дә, монысында да хаклык бардыр. Фәхретдинов Иске Казан территориясендә, унбишенче гасырга караган туфрак катламында табылган көмеш тәңкә коелмасын һәм тәңкә әзерләнмәләрен тасвирлый,

[1] Бу байлык Мәскәүгә исән-имин барып җитә, әмма соңыннан эзсез югала.

[2] А. Г. Мухамадиев, Булгаро-Татарская монетная система. XII—XV в.в., 1983, 20 с.

Мөхәммәдиев исә Казан ханлыгы тәңкәләре XV гасырның беренче яртысында хәзерге шәһәр сызыгында урнашкан акча сугу йортында чыгарылуга дәлилләр китерә. Аның фикере белән тарихчы С. Х. Алишев та килешә.

«Казанда тәңкә сугу җайга салына, акча әйләнеше гамәлдә була. Ул елларда Түбән Идел шәһәрләренең акча сугучылары болгар (яки Казан) тәңкәләренең авырлыгын «өлге» итәргә мәҗбүр булалар [1]. Әмма... Фәнгә әлеге XV гасырның уртасыннан соң яңа Казанда сугылган дип кистереп әйтерлек бер генә тәңкә дә мәгълүм түгел.

Икенең берсе: Казан ханлыгы үзенең иң зур үсешкә ирешкән чәчәк ату чорында акча сугу йортына ия булмаган, я... бөтен акча кинәт кенә җыеп алынган.

XV гасырның икенче яртысыннан соң Казанда акча сугу йорты булмаган дип исәпләсәк тә (гәрчә, болай булу ихтималы бик аз), читтән кертелгән акчалардан алтын запасы тупланырга тиеш иде ләбаса. Казан ханлыгында гарәп дирһәме (Багдадта сугылган куфи язулы көмеш тәңкәләр), рус гривналары, Көнбатыш Европа тәңкәләре дә йөргән бит юкса. Ләкин Иван Грозныйның ганимәт булырак акча кулга төшерүе турында бер генә чыганакта да әйтелмәгән. Савыт-саба, корал, затлы кием-салым, әләмнәр санап кителә, ул заманнарда төп хәзинә исәпләнгән акча исә беркайда да телгә алынмый. Хәтерсезлек бәласе генәме бу? Әмма XV гасырның икенче яртысы — XVI гасырның беренче яртысында сугылган Казан тәңкәләре дәүләт музейларында да, хосусый коллекцияләрдә дә юк...

ӨЧЕНЧЕ СОРАУ: Казан ханнарының яшерер байлыгы булсын да ди. Яшерү мөмкинлеге булганмы соң?

Әлегәчә, яшерелгән хәзинә турында сүз кузгалуга, тикшеренүчеләрнең фикере бер генә юнәлештә була: аны камалган шәһәрдән алып чыгу мөмкин эшме?

Мәгълүм ки, камалыш ике ай дәвам иткән. Урта гасыр шәһәрләренең барысында да диярлек, оборона корылмалары төзегәндә, тышкы дөнья белән бәйләныш өчен яшерен җир асты юллары да ясалган. Мондый юллар Казанда да булган.

Нургали манарасы янындагы чишмәгә илткән яшерен юл турында әйтеп үткән идек инде. Воскресенский калкулыгының көнчыгыш ягыннан Черек күл ягына сузылган юл турында да мәгълүматлар бар. XIX гасыр башында

---

[1] «Молодость древнего города». Казань, 1978, 11 с.

шул тирәдә төзелеш эшләре алып барганда, хан заманнарыннан калган, җир асты юлына тап булалар.

Менә шушы фактка нигезләнеп, кайбер тикшеренүчеләр хәзинәне алып чыгу мөмкин булган дип саныйлар. Икенчеләре хаклы рәвештә каршы килә: болай, казнаны алып чыгам дип, аннан колак кагуың да бар. Аннары... Чишмә юлы турында әйткән сатлык җанның бүтән юлларны да белгән булуы ихтимал. Юлларның икенчесен әнә шуңа томаламадылар микән? Хәзинәне шәһәр эчендә яшерү, берәр подвалда күмү җиңелрәк булыр иде бит.

Әҗем картның сүзләрен исәпкә алганда исә фикер үзгәрергә тиеш.

Казанлылар Иван Грозныйның яу белән килүен алдан белеп торганнар. Алар башта Кырым һәм Төркия белән ярдәмләшү турында килешеп куярга омтылалар. 150 меңле гаскәрнең якынаюы беленгәч, оборонаны ныгыту чаралары күрелә: гаскәр җыела, якын-тирә авыллардан халык күчерелә, азык һәм хәрби запаслар туплана. Арча ягында озак камалышка исәпләнгән ныгытма корыла, анда Япанчы әмир кул астындагы атлы гаскәр урнаша (ул соңыннан камаучыларны нык бимазалап тора). Кыскасы, һөҗүм көтелмәгән эш булмый. Казанлылар кулында ким дигәндә берничә ай вакыт булган.

Ханның үз акылы җитмәсә, хакимнәренең зирәкләре бу юлы эшнең ничек бетәчәген чамалаган, әлбәттә. Рус чирүе биш тапкыр зуррак. Корал да аларда күбрәк, дарысы да мулрак. Руслар крепость ныгытмаларын ватыруда зур тәҗрибә туплаган чит ил белгечләре ярдәменә таяналар (шәһәрнең язмышын шактый дәрәҗәдә шул хәл итә дә).

Мәгълүм ки, Казанда ул елларда ике партия була. Берсе Мәскәү белән якынаюны алга сөрсә, икенчесе Төрек солтаны һәм Кырым белән союзга өмет баглый. Ахыр исәптә, соңгылары өстенлек ала. Әмма, ни генә булмасын, алары да «җиңелү котылгысыз» дип кисәтүчеләрнең сүзенә колак салмый кала алмаслар һәм хәзинәне җиңелгән хәлдә дә алып китә алырлык итеп яшерергә тырышырлар иде. Шәһәрдән читтәге берәр аулаграк урында күмүдән дә җиңеле юк, әлбәттә. Тик дошман шымчылары мыжгып торган, халык тыгыз утырган урта гасыр шәһәреннән казна кадәр казнаны сиздермичә генә алып чыгып кара әле! Күмгән җирдә дә эз кала бит!

Кабанга тоташкан Болак исә шәһәр уртасыннан ага. Сүз таралса-нитсә дә, көймәнең (яки көймәләрнең) кайда туктаганын ничек чамалыйсың ди? Аннан, Әҗем карт

әйткән хәйләне белмәгән килеш, хәзинәне ничек күл төбеннән күтәртмәк кирәк? Су өстенә чыгып җитмәгән калкавыч, очлары ярда яшерелгән җәтмә яки бау була ала бу... Гадәттән тыш шартлар хәйлә сораганда ни генә уйлап тапмас адәм баласы!

РАВИЛ БОГДАНОВ ХИКӘЯТЕ

Кайгылы көн.
Бер мичкә алтын.
Кабан үзенең серләрен нык саклый.

Кабан күле серләрен чишкәндә, яңадан хәзинәгә «тап булдым». Бу юлы инде имеш-мимеш тә, очы гасырлар төбендә җуелган риваять тә түгел, ә бәлки күреп торган кешенең таныкламасы иде.

«Спартак» су станциясе өлкән тренеры Равил Богдановны мин студент чактан ук беләм. Кабанда көймәче булып эшли иде ул. Равил абый кырык елга якын гомерен Кабанда үткәргән, аны аркылыга-буйга йөзеп узган. Йөзләрчә спортчы тәрбияләгән, арада спорт мастерлары да аз түгел. Күлнең язмышы аны да борчый. Богданов миңа күп кенә пычрану чыганакларын эзләп табарга ярдәм итте, предприятиеләрдән әшәке су агызу очраклары турында хәбәр биреп торды, күлне тикшерергә кирәк чакта көймәсен дә кызганмады.

Бер көн шулай, сүз иярә сүз чыгып, Исмәгыйль Әҗемев турында сорадым. Равил абый картны белүен белми икән, ләкин аның «әкиятен» бик җитди кабул итте.

— Тач шулай! Хәзинә нәкъ шунда ята!

— Каян беләсез? Тотып караганыгыз булды мәллә?

— Тотып караган идем дә... төшеп китте,— диде ул, җитдилеген җуймыйча. Аннары бер вакыйга турында сөйләде. Равил абыйның хикәятен үзгәртмичә, сүзгә-сүз диярлек бирәм.

— Кырыгынчы еллар азагында, илленче еллар башында булды бугай бу. Җәйнең иң матур чагы — июнь-июль айлары. Казанда баскетбол ярышлары үткәрелгән иде. Спортчыларның берсе миннән көймә алып торды. Озын буйлы, кап-кара чәчле чибәр генә егет. Ярышлардан соң бераз ял итеп аласы килгән, күрәсең. Бик яхшы хәтерлим: якшәмбе, аяз эссе көн. Бер сәгать үтте микән, ике микән, кинәт шау-шу купты. «Батты бит, батты! Коткарыгыз!» — дип кычкыралар. «Кем батты?» «Баскетболчы,



Баку егете!» Көймәгә утырып, шул урынга йөзеп килдем. Көймә капланган икән. Егет белән булган ике кызны инде бүтән көймәгә алганнар. Кызлар, күрәсең, уен өчен көймәне чайкалдырып, суга батырганнар. Егет яки йөзә белмәгән, яки нәрсәгә булса бәрелгән.

Ни хәл итәсең — мәетен булса да табарга кирәк. Ике көн эзләдек — тапмадык. Өченче көнне әтисе килеп җитте. Зур урында эшләүче икән. Җыеп алды безне. «Нишләсәгез дә эшләгез, улымның гәүдәсен табып бирегез, шунсыз кайтып китмим»,— ди. Мең тәңкә акча вәгъдә итте.

Заводта берничә җәпле тимер ыргаклар ясаттык, күпме кирәк бау сатып алдык — шөкер, түләр кеше бар. Тотындык шуннан күлне буеннан-буена алты-җиде көймә белән «сөрергә». Нәрсә генә чыкмады төптән! Солдат термосы, борынгы каеш, тимер шлем, гражданнар сугышыннан калган кораллар. Мәетне генә таба алмадык... Менә шунда булды инде ул хәл. Кинәт бер ыргак нәрсәгәдер эләгеп калды. Көймә шып туктады. Субайдыр, дигән идек башта. Юк, мондый тирәнлектә субай була алмый. Бөтенебез шул урынга җыелдык, тартабыз. Бермәл йөк кузгалган кебек булды. Безгә кызык тоелды — ни булыр микән бу?

Һәм менә судан кечкенә генә бер мичкә күренде... Биеклеге күп булса берәр метр булыр. Тик нигә шул хәтле авыр ул? Баулар шартлап өзелер дәрәҗәгә җитте.

Мичкәне ничек тә көймәгә алып салмакчы булабыз. Астына бау кертер идең — буй җитми. Шуннан арабыздан берәү (хәтерем ялгышмаса, Константин Фролов булса кирәк): «Юк, егетләр, болай булмый, моны күтәрергә көчебез җитмәс. Әйдәгез әкренләп ярга таба ишик. Саерак җиргә җиткәч, ничек тә сөйрәп чыгарырбыз»,— диде. Әмма... кулын ычкындыруы булды, мичкә коточкыч авырлыгы белән безне сөйри башлады. Мичкәгә ике яклап кадалган ыргаклар турайды һәм ул ычкынды. Дөньяда күпме яшәп, бу кадәр авыр әйбер күргәнем юк иде... Ул урынны соңыннан кат-кат «сөреп» чыктык без.

— Эләкмәдеме?

— Кая ул!.. Университеттан бер профессор килгән иде безгә. Кабан төбендәге ләмнең калынлыгы унбиш метрга җитә, ди. Дүрт катлы йорт биеклеге ләбаса бу! Мичкә күрәсең, төпкә хәтле батып кергәндер.

— Су тирәнме соң анда?

— Әллә ни тирән дә түгел — биш-алты метр булыр.

— Ә земснаряд ул урында эшләмәгән идемени?
— Юк шул.
— Кая да булса хәбәр итәргә уйламадыгызмы?
— Хәбәр итмичә торып та әллә кайларга кадәр таралды, мин сиңа әйтим! Үземә генә дә ничәмә-ничә кеше килде... Керәләр, тегесен-монысын сөйләгән булалар. Иң якын дусларым булып кыланалар... Кайберләре ярты да чыгара. Шуннан башлана инде. Бер мичкә алтын тапкансыз икән, чынмы? Кайчан, кайда, ничек? Шул вакыт күзләре яныпмы-яна...

Равил Богданов сөйләгәннәр мине тәмам иләсләндерде. «Әкият»нең чын дәвамы аяк астында гына ята түгелме соң?

Газеталардан шуны белдем: 1949 елның 10—15 июлендә «Динамо» стадионында баскетбол буенча РСФСР беренчелегенә ярыш үткәрелгән. Якшәмбе көн унҗидесенә туры килгән икән.

Газеталарда теге фаҗига турында бер генә сүз дә юк, әлбәттә. Әмма спорт ветераннары бу хакта белә икән.

Равил абый истәлекләрендә телгә алынган Фролов исән-сау булып чыкты. Икесенең сөйләгәннәре сүзгә-сүз диярлек тәңгәл килә иде.

Эзли торгач, тагын бер шаһит — Владимир Сучков табылды. Ул чакта ундүрт яшьтә генә булгангамы, Володя әлеге вакыйганы җентекләбрәк хәтерләп калган. Һәр ике көймә арасына аркан сузылган иде, ди ул. Аларга, 80—90 сантиметр саен, ыргаклар бәйләгәннәр. Алар төптән сөйрәлеп барганга, ишүе бик авыр булган. Ыргакларның берсе эләгеп калгач, бөтен көймәләр дә шул урынга җыелган. Сучков үзе Равил абый көймәсендә булган... Йөкне сөйри башлагач, коточкыч авырлыктан көймәнең койрыгы иңеп, су керә башлый. Володя тиз генә алга күчеп утыра, тигезлекне саклау өчен ныклап ишәргә туры килә. Володяга табылдык сандык булып күренгән. «Буй-буй калайларына хәтле күрдем»,— ди. Ләкин аны үз куллары белән тотып караган Богданов белән Фролов исә һич икеләнмичә «мичкә» диләр.

Бу маҗара В. Сучковка нык тәэсир итә. Кайту белән, этисенә сөйләп бирә. Әтисе көлә генә: «Ниткән сандык ди, ниткән хәзинә ди ул! Әкият сөйләмә әле!» Урынын искәреп калган Володя көннәр буе шул тирәдә бөтерелә. Шул көнне үк аның күз алдында водолазлар төшерәләр. Нык болганган су тонып өлгермәгәнлектән, алар бер ни дә тапмыйлар... Мәет исә берничә көннән калкып чыга —

«Спартак» комбинатының су суырткычы рәшәткәсенә килеп терәлгән була ул.

Богданов сөйләгәннәрне «Вечерняя Казань» газетасында бастырып чыгаргач, ДОСААФның Кабан күлендәге су станциясенең элеккеге директоры Владимир Кириллович Хиблин шалтыратты. Ул нәкъ шундый ук «үз мичкәсе» турында сөйләде.

1967—68 елларда Казанда моторлы көймә йөртүчеләрнең Бөтенсоюз ярышлары уздырылган. Владимир Кириллович ярышны әзерләүчеләрнең берсе буларак, маякларкую өчен җаваплы булган. Ярыштан соң аларны җыйганда, берсенең якоре эләгеп кала. Үзе генә тартып чыгара алмагач, Хиблин алты ишкәкле көймәдә йөзеп йөргән елга техникумы студентларын ярдәмгә чакыра. Тик... якорьны сигез кеше дә кузгата алмый. Тагын бер шундый көймәне дәшәләр. Ике яклап тарта торгач, бау аз-азлап өскә шуыша башлый. «Шул чакта шикләнеп калдым,— ди Хиблин.— Кабель-фәлән түгел микән — алар шундый авыр була торган иде... Егетләр тарта, мин, йөзтүбән ятып, күзәтәм. Менә күренде. Мичкә! Сез язган идегез бит — шундый ук зурлыкта. Имән мичкә, күрәсең; ләкин суда озак яткан имән күк кучкыл түгел, яктырак төстә... Көймә төбенә килеп бәрелүе булды, якорь ыргагы кыршаудан ычкынды да, мичкә төшеп тә китте... Якорьны кире суга томырып, шул урынны тамгалап кына куясы иде дә бит. Мин, җүләр, якорь да чыкты, бау да өзелмәде дип сөенәм. Кармагыннан зур гына чуртан төшеп калган балыкчы күк, бераз аһ-ваһ килгәч, китеп бардык... Мин туп-туры водолазлар янына киттем. Көлделәр генә үземнән. «Башны катырма әле, хәзинә мичкәдә буламыни ул, кургаш-фәләндер»,— диделәр.

Күл төбеннән тапкан әйберләрнең охшашлыгы гаҗәпләндерә. Ике очракта да бу — 8—10 чиләк сыешлы мичкә. Аларны кузгатыр өчен дә бер чама көч кирәк булган.

Газеталарда мәкаләләрем басылгач, миңа пенсионер Җәүдәт Закиров та шалтыратты. Балыкчыларга җим — күл ләмендәге кортны сатып көн күргән татар картын белгән ул. Абзый аңа күл төбеннән алтын балдак, көмеш саплы пычак кебек әйберләр тапкалавын әйткән. Гарәп хәрефләре төшерелгән бәләкәй көмеш тәңкәләр дә күрсәткән. Каян табуын гына әйтмәгән. Ләкин Җәүдәт ага картның кай тирәдә кайнашканын искәргән булган. Хәзинә ята дип исәпләнгән урыннан ерак түгел икән.

Шул турыдарак, күлнең икенче ягында тагын бер «хәзинә каба». Тик бусы да «кармактан» ычкына. Бу туры-

да миңа Герман Глебович Зайцев сөйләде. Аның бабасы, мәшһүр доктор, көймәсен «Пищевик» станциясендә тоткан. Бер тапкыр шулай, йөзеп кайтырга уйлагач, көймәсенең якорен тартып чыгара алмаган. Ярдәмгә иптәшләрен дәшкән. Бишәүләп маташа торгач, чылбыр кинәт җиңеләеп китә. Якорьга эләгеп, борынгы сандык капкачы килеп чыга.

Монысын инженер Николай Колесников сөйләде. Николай — милләте буенча чуваш. 1967—68 елларда экскаваторда эшләгән, Үзәк универмагны (хәзерге «Балалар дөньясы») төзүдә катнашкан. Бер заман Николай төзелеш буласы җирдә иске бинаны ваттыра икән. Кинәт каяндыр түгәрәк каракүл бүрек кигән кәкре аяклы бәләкәй генә бер карт килеп чыккан. «Шул сез язган карт инде ул,— ди Николай.— Кирпеч стена алдына чабып килде дә кулларын бутый-бутый, нидер кычкыра башлады. Моторны сүндердем. «Ни булды, бабай, якты дөньядан туйдың мәллә?» — дим. Бабай тиз-тиз бытылдый, берни аңлый алмыйм. Татарча бераз сукалыйм мин үзе. Бу юлы исә кат-кат әйтелгән «хәзинә» дигән сүзне генә искәреп калдым. «Кайда соң ул, мондамыни?» Бабай Кабан күле ягына күрсәтә. Соң алайса бу стенаның ни катнашы бар икән?.. Бабай бер урында тора алмый, тыз-быз чаба, туктап, стена артына карап куя, аяк астыннан нидер эзләгәндәй итә, адымлап үлчи. Үзе исә: «Җимерергә ярамый, харап була» дип кабатлый. «Нәрсә харап була, аңлатыбрак сөйлә әле»,— диюемә каршы, серле генә карап алды, «Ашыкма, бераз гына көт»,— диде. Сабырым төкәнде. «Юк инде, бабай, бүтән көтә алмыйм»,— дип, чуен тукмакны чайкатып куйдым. Янәсе, хәзер ул торган урынга сылыйм. Сукрана-сукрана китеп барды, бахыр. Икенче көнне иртән ваткан-җимергәнне җыештыра башладым. Бабай басып торган урынга чүмечне тидерүем булды, җир убыла башлады. Куркып, тизрәк экскаваторны артка чигердем. Чыгып карасам, зур гына чокыр хасил булган. Караңгы, тузан — берни күренми. Чокырның Кабан ягына сузылуын гына чамаларга була иде».

Икәүләп «Балалар дөньясы» универмагы ишегалдындагы әлеге урынны барып карадык. Әгәр бушлык, чыннан да, дәвам итсә, Хиблин мичкә тапкан турыга килеп чыгачак икән.

Чокырга чүп-чар, таш ватыклары тутырып, өстенә балчык өеп, асфальтлап куялар.

Чыннан да, ни булган соң бу? Борынгы шәһәрнең җир асты юлымы? Элекке коллектор-фәләнме? Кайчандыр

шушында агып яткан борынгы елганың эземе? Бу сораулар җавапсыз кала бирә.

Әгәр дә Колесников күргән карт чыннан да Исмәгыйль Әҗемев икән, агайның минем янга килүе, бәлки, әнә шул вакыйгага бәйледер? Серне чишәргә аны җир асты юлы томалану мәҗбүр иткәндер. Серне чишеп тә бетермәгәндер әле ул. Аның хәзинә урынын төгәл белүе дә бар бит. Бәлки әле хәзинәне дә бүлеп, берничә урында яшергәннәрдер?

Исмәгыйль ага китереп тоттырган кәгазьләрне кулдан ычкындыруым өчен үз-үземне битәрлим. Хәзер менә иң гади мәгълүматны да интегеп, әллә кайлардан эзлисе. Әйтик, чит ил компаниясенең Кабан күлен чистарту турындагы тәкъдиме басылган газетаны университетның фәнни китапханәсе хезмәткәре, крайның өйрәнүче галим Вячеслав Аристов белән икәүләп эзләп таба алмадык. Хәер, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәре Н. Ханзафаров ярдәмендә, икенче бер хәбәргә тап булдык. «Вакыт» газетасының 1913 елның 8 июнендә дөнья күргән бу хәбәргә ышансак, бер Америка эшмәкәре Кабан күлен чистартырга рөхсәт сораган, моның өчен Казан шәһәре думасына алтын белән миллион ярым сум акча вәгъдә иткән. Дума ризалашмаган... 1926 елны Татарстан хөкүмәтенә дә шундый ук тәкъдим ясалган, дип әйтүчеләр бар. Тик монысын раслаган документлар табылмады әле.

Кайберәүләргә хәзинәнең мичкәгә тутырылган булуы сәер тоела. «Комсомольская правда» газетасы да, әнә, Богдановлар тапкан әйберне «сандык» дип язган. Әкиятләрдәгечә булса чынрак тоела, күрәсең.

Иске газеталарны актарганда, хәзинә табылу турындагы хәбәрләрнең күп булуына игътибар иттем. «Волжский вестник» газетасыннан күренгәнчә, Казанда 1888 елда гына да 17 хәзинә тапканнар. Аларның иң кыйммәтлесен — алтын ком белән тулы бәләкәй мичкәне Катин дигән кеше үз өенең идән астыннан табып алган. Алтын, ул заман бәясе белән, миллион ярым сумга тарткан. Катин яшәгән Большая Проломная (хәзерге Бауман) урамы Казан ханлыгы чорында да булган... «Казанский биржевый листок»ның 1901 елның августында чыккан санында исә «сандыклы хәзинә» табылуы әйтелә. Энҗе муенсалар, алтын балдаклар, сабы асылташлар белән бизәлгән хәнҗәрләр тулы сандыкны Болгин атлы графның бакчачысы алмагач төбеннән казып чыгара. Табылган әйберләрнең кайсы чорныкы булуы әйтелмәгән.

ҚАЙСЫ СУ ЧИСТАРАК?

«Казан каласындагы иң шәп су — төбендә чишмәләр тибеп торган Кабан күлләрендә. Ком белән күмер аша уздырсаң, бу суга табигый сафлыгы кайтачак».

Р. Лангель, дәвалау управасы инспекторы, 1807 ел.

«Аның (ягъни Кабанның) яр буенда тирес вә төрле пычрак нәрсәләр күрәсең».

«Казанские известия газетасы, 1817 ел, 13 сан.

«Казанлылар суны башлыча Кабан күленнән ала, тик ул ел әйләнәсе болганчык, үзендә төрле бөҗәк тулы, хәер, алары сәламәтлеккә әллә ни тәэсир итми тагын. Тәҗрибәләр ясап карагач, төбендә табигый чишмәләр тибеп тору, углекислый газ, алкалик тоз һәм известьле балчык булу сәбәпле Кабан күленең суы иң әйбәт су булып чыкты».

Н. Баженов. «Казан тарихы», 1847 ел.

«Рәсәйнең Мәскәүдән кала беренче шәһәре бу».
Европа белән Азия чигендә.
Кабанны фәнни өйрәнү башлангач.
Шәһәрне төзекләндерүнең иң «нечкә» җире.
Ташаяк ярминкәсе.

XIX гасырның җитмешенче елларына кадәр, ягъни Казанда сууткәргеч төзелгәнче, Кабан күле шәһәр өчен бердәнбер су чыганагы булып торган. Идел җиде чакрым читтән үтә. Өстәвенә, аның суын халык яратып та бетерми. Казан суын яр буенда яшәгәннәр дә эчәргә тотмый — каты.

Шәһәрнең Кабанга таба үсә баруының бер сере әнә шул. Сан алу кенәгәләреннән күренгәнчә, XVI гасыр уртасында шәһәрнең төп капкасы (хәзерге Куйбышев мәйданы тирәсе) янында ук яшелчә бакчалары башланып киткән була. Казан баштарак әкрен үсә, болыннар, калкулыклар, әрәмәләрне ашыкмыйча гына йота. 1708 елда, гаять зур губерна үзәгенә әйләнгәч тә, анда нибары унбиш мең генә кеше яшәгән әле.

XVI гасыр уртасында барлыкка килгән Татар бистәсе белән бераз соңрак салына башлаган Яңа бистә чагыштырмача тизрәк үсәләр. XIX гасыр башында Якын Кабанның көньяк яры Плэтән авылына чаклы шәһәр эченә керә. Төньяк ярда Сукна (Суконная) һәм Кирпеч (Кирпичная)

бистәләре үсеп чыга. Бу бистәләр белән Архангельск авылы (хәзерге Архангельск зиратыннан ерак түгел) арасына чөй булып аерым мәхаллә хасил иткән берничә татар урамы килеп керә...

Аз-азлап Казанның көнчыгыш белән көнбатыш, Азия белән Европа оеткылары кушылудан килеп чыккан үзенә бер төрле рәвеше төсмерләнә башлый. Күккә ашып торган кызгылт-көрән Сөембикә манарасы, алтын гөмбәзле чиркәүләр, очланган карандашлар күк нечкә мәчет манаралары, тау башындагы ак, көяз шәһәр үзәге, уйсулыктагы агач йортлы бистәләр... Өч яктан су белән уратып алынган, көзге кебек күлләр янында ялтырап яткан Казан корабта йөзеп килгән сәяхәтчегә әкияти «алтын кала» булып күренгән. Әмма шул ук вакытта бу күлләр һәм елгалар зур каза да булган, алардан дым-юешлек таралган һәм алар төрле-төрле чирләр чыганагы да булган.

XIX гасыр башында шәһәрнең югары, иң мәһабәт өлешендәге урамнарына бүкән һәм йомры таш түшәлгән, алар буйлап лакланган пролеткалар җилдергән. Ара-тирә дөбердәп арбалар үткән, мичкә белән Кабан суы таратып йөргән йөк атларының дага тавышлары ишетелгән.

Урамнарның күпчелегендә исә пычрак җәен дә кипми. Язын-көзен пычрак тәгәрмәч бүкәненә җитә. Урыны-урыны белән күлдәвекләр, юл читендәге чокырда су тонып тора. Тирес, чүп, язгы ташу алып китәр дигән өмет белән, башлыча Кабан буена түгелә. Бу исә йогышлы чирләр таралу өчен уңай шартлар тудыра.

XVII гасыр уртасында Казанга чакырылмаган дәһшәтле кунак — чума килә. Шәһәр халкының яртысын диярлек алып китә. Корбаннарның төгәл саны мәгълүм түгел. Безгә бары риваятьләр генә килеп җитте: көне-төне дөрләгән учаклар (чирнең таралуыннан шулар ярдәмендә котылып калмакчы булалар), шешенгән-күбенгән, кара көйгән мәетләр, кара киемле монахлар озатып барган исәпсез җеназалар... Шәһәр халкын ваба, тиф эпидемияләре дә онытып бетерми. Хәерчелек һәм дымлы һаваның юлдашы булган туберкулез тынгы бирми Казан кешеләренә. Түбән урнашкан күп кенә кварталларда туган балалардан үлүчеләр күбрәк була. Унтугызынчы гасырның башыннан азагынача Казан халкы бары читтән күчеп килүчеләр исәбенә генә үсә. XIX гасыр азагында статистиклардан берәү исәпләп чыгарган: үлүчеләр темпы шул килеш сакланса, 1960 елга Казанда... бер кеше дә калмаячак.

Хәер, бу яктан караганда Казан башка провинциаль шәһәрләрдән әллә ни аерылып тормаган, зурлыгы һәм төзек-

леге буенча күбесеннән өстенрәк тә булган әле. Екатерина Икенче, мәсәлән, Казанга килеп киткәч, болай ди: «Һичшиксез, бу Рәсәйнең Мәскәүдән кала беренче шәһәре». Екатерина тарафыннан Себергә сөрелгән, 1797 елның маенда Казан аша үткән Радищев исә көндәлегенә язып куя: «Шәһәр буйлап соклану хәлендә диярлек йөрдем». Әдип ул чагында әле мул сулы булган Болакны, Болактагы пристаньны, әрле-бирле йөзгән төрле-төрле көймәләрне тасвирлый, Бишбалтада төзелгән фрегатны суга төшерү турында яза.

Пермьга сөрелгән А. И. Герцен да шәһәрнең онытылмаслык һәм төгәл тасвирламасын калдыра: «Казан унайлы урнашмаган, татарча исемен аклап, чыннан да чокырда утыра; юеш-дымлы урыннар күп, эчәр суы аз. Бина-корылмалары болай ару гына, үзәк урамнар матур; алар шаугөр килеп тора, төркем-төркем булып халык җыела, шаулаша; атлетлардай матур гәүдәле бурлаклар очрый, татарлар күп, яньчек борынлы, кысыграк күзле, хәйләкәр чырайлылар, читек, түбәтәй саталар. Кыскасы, кая гына бакма, тормыш кайнап торган зур шәһәр күрәсең, крайның үзәк, шәһәре, сәүдә шәһәре, иң мөһиме, Европа белән Азия рухын берләштергән үзенчәлекле шәһәр».

Чыннан да, Казан Россиянең экономик, социаль һәм культура тормышында зур роль уйнаган санаулы шәһәрләрнең берсе була. Казанда Россиядәге беренче провинциаль гимназия (1758 ел), өченче (Мәскәү һәм Тарту шәһәрләреннән соң) университет (1804), беренче провинциаль газета («Казанские известия», 1811), беренчеләрдән булып ачылган провинциаль театр әнә шул турыда сөйли. Күпсанлы документлар, хатирәләр шәһәрдә культура тормышы кайнап торганлыгын, арада татар зыялылары да булган белем ияләре катлавының зурлыгын күрсәтә.

Шәһәрнең экономикасы үсүгә, шактый дәрәҗәдә, табигый шартлар да йогынты ясый. Йомшак һәм чиста Кабан суы күп төрле һөнәрләр өчен алыштыргысыз булып чыга. Болгар заманнарыннан ук Казанда күнчелек нык алга китә. Биредә эшләнгән йомшак күн (юфть) һәм сәхтиянны Рәсәйдә, Урта Азиядә, Шәрык һәм Көнбатыш илләрендә кулдан йолкып алалар. Төрле төстәге күннән тегелгән Казан читекләрен рус боярлары яратып кия. Күнчеләр элек-электән Кабанның көньяк яр буенда, хәзерге Сафьян урамы тирәсендә төпләнгән булалар.

Казанга 1436—1452 еллар арасында килеп киткән Венеция сәяхәтчесе Йосифат Барбаро болай дип яза: «Бу — сәүдәгәрләр каласы, аннан Мәскәүгә, Польшага, Пруссия-

гә, Фландриягә бихисап мех әйберләре китә». Гәрчә мехларның кыйммәтле төрләре сарык тиресе белән алыштырыла барса да, мехчылар эше соңрак елларда да үсә. Кабан суы постау җитештерүдә, кирпеч сугуда, сабын кайнатуда, шәм ясауда кулланыла.

XVIII гасырның беренче яртысында Кабанның яр буенда 25 сабын кайнату, 40 күн остаханәсе урнашкан була. Аларның кайберләрендә дистәләрчә кеше эшли. Төрле яктан күлгә агулы чишмәләр агып төшә...

Шәһәр үскән саен, Казанда күп булган эчке сулыклар берәм-берәм юкка чыга бара: Гүзәй күле булган җирдә балык базары ачыла (хәзер Куйбышев мәйданы), Тихвин күле урынында Печән базары гөрли. 1829 елда шәһәр думасы Черек күл белән Мунча күлен чистартырга шактый зур сумма билгели. Күлләрне чүп-чардан арындыралар, ярларын тигезләп, кәс тезәләр, агач утырталар. Әмма күлләр барыбер саега, чөнки туендырып торучы чишмәләр, инешләр калмый. Күпмедер вакыттан күлләр сасып, аларны күмәргә мәҗбүр булалар.

Тирән сулы Кабанга әлегә мондый язмыш янамый янавын. Ләкин сафлыгы турында легендалар чыгарылган күл XIX гасыр башларында «кызлар күз яше күк» чиста булмый инде. Моны шактый төгәл күзәлларга була, чөнки шул еллардан башлап күлне фәнни тикшерү алып барыла. Кабанны фәнни тикшерү Мәскәү янындагы күлләрне тикшерүдән кимендә ярты гасыр алданрак башлана. Бу хәл үзе генә дә аның Казан өчен никадәр мөһим булуын күрсәтә.

Кабан турындагы беренче фәнни хезмәт — Р. Лангельның «Казан губернасына һәм губерна шәһәре Казанга кыска медик-физик һәм топографик күзәтү». Бу хезмәт 1807 елда Санкт-Петербургта «Медицина журналы»нда басылып чыга. Соңыннан ул ике мәртәбә (1817 һәм 1824 елларда) Казанда да басыла. Галим Лиль (яки Лилий) исемле аптекарьның безгә килеп җитмәгән һәм, күрәсең, басылмаган хезмәтенә дә таянуын әйтә. Бу аптекарь XVIII гасыр азакларында ук күлләрне үлчи, аларның режимын өйрәнә башлый.

Р. Лангель Кабан күлләренең физик-географик тасвирламасына аныклык кертә, шәһәрне су белән тәэмин итүдә аларның ролен күрсәтә. Гәрчә галим Якын Кабан суының сыйфатын тулаем алганда әйбәт дип бәяләсә дә, аның хезмәтендә инде яр буйлары пычратылуга, бернинди контроль-фәлән булмауга борчылу да сизелә. Авторны бигрәк тә «өч аршын ләм утырган» Болакның хәле борчый.

Болакны тирәнәйтергә, ләм күмгән чишмәләрне арчырга, агымга юл ачарга кирәк, дип яза ул.

Статистик һәм тарихчы И. Ф. Яковкинның «Казанны Идел һәм Кабан суы белән тәэмин итү, аларның сыйфаты һәм Кабанны мул һәм агым сулы итү турында искәрмәләр, күзәтүләр һәм фикерләр» дигән зур мәкаләсендә («Заволжский муравей», 1833 ел, 16 сан), күлнең һаман пычрана баруы борчуга салса да, чагыштырма анализ ясагач, автор болай дип таба: «Идел суы Кабан суына караганда начаррак — катырак та, сәламәтлеккә тәэсир ягыннан да шиклерәк».

Дәвалау управасы инспекторы Тиль исә моның белән килешми. «Казанның сәламәтлек өчен кулай булмаган шәһәрләр исәбенә керү сәбәпләре турында язма»сында («Заволжский муравей», 1833 ел, 19—20 саннар) ул төп өч факторны атый: 1. Шәһәрнең түбән урнашуы. 2. Пычраклык. 3. Суның чиста булмавы. Инспектор Кабан күленнән (Якынынннан, билгеле) черек исе килүен, җәйге айларда яшелләнүен, суда балык аз булып та суалчан тулып ятуын, суның тәме дә чамалы гына булуын яза. «Суга килеп эләккән пычрак беркая да китмәгәнгә һәм дә күл шәһәрнең төп өлешеннән түбәнрәк урнашканга... аның суы пычрансын өчен бөтен шартлар да бар»,— дип бик дөрес яза ул. Күлнең төбен калын кара ләм каплаганлыгын ачыклый. Әмма бу шәһәр эчендә генә шулай. Шәһәр читендә исә төптә ком һәм үзле балчык була. Инспектор шундый нәтиҗә ясый: Кабан суы Идел суыннан начаррак, шуңа күрә, һичшиксез, Идел суын эчә башларга кирәк.

Берничә дистә елдан бәхәсне бөек химик профессор А. М. Бутлеров хәл итә. Гаять оста үткәрелгән фәнни анализлардан соң ул Кабан суы үзенең табигый сыйфатлары белән Идел суыннан яхшырак, йомшатрак булуын әйтә. Әмма ул органик калдыклар белән шулкадәр пычратылган ки, сәламәтлеккә зыян китермичә куллану мөмкин түгел. Галим мондый тәҗрибә ясый: тирес суын 31 өлеш дистилляцияләнгән су белән катнаштыра, әнә шул сыеклык үзенең төсе, исе һәм органик матдәләр күләме буенча Кабан суына тиң була.

Урта Кабанның суы исә үзенең төсе, исе, органик матдәләр һәм эремәгән кисәкчәләр микъдары, кыскасы бөтен күрсәткечләре буенча да Идел суыннан өстенрәк була. Бутлеров, тиз арада суүткәргеч төзергә кирәк, ди, суны исә Урта Кабаннан алырга тәкъдим итә.

Болакның хәле бигрәк тә авыр була. Җирле журна-

листлар аның турында: «Шәһәрне төзекләндерүнең иң нечкә җире», диләр. Шәһәр монда чүп-чарын түгә, пычрагын агыза... Ярына элеккечә мунчалар сырышкан. Арада сәүдәгәр Меркулов, борынгы нәселдән булган Жуковский һәм Баратынскийларныкы кебек ике катлы таш мунчалар да бар.

Болак ул чагында да әле су юлы буларак та әһәмиятен җуеп өлгермәгән була. Бу шуннан да күренә: XVII—XVIII гасырларда Болакта әле ике якка ачыла торган күперләр тора. Аларның берсе (төзеткән сәүдәгәр исеме белән «Жарковский күпере» дип йөртелгән) XIX гасыр башларына кадәр сакланып, бары 1815 елгы янгында гына харап була. Төнлә күперләрне ачып Иделдән, Казан суыннан кергән судноларны яр буендагы складларга үткәрәләр. Бу традиция хан заманнарыннан бирле сакланып килә: инде шул чакта ук Болак тамагында күтәрмә агач күпер булган. Язгы ташу вакытларында кораблар Кабанның иң ерак почмакларына кадәр барып җитә. Корылык елларда исә Болак тирәнлеге нибары ярты аршын (30 сантиметр) булган сасы ермакка әйләнеп кала. Күп гасырлар буена җыелып килгән пычракны язгы ташулар да юып бетерә алмый.

Болакны чистарту, төзекләндерү проектлары аз булмаган. Иң беренчесен 1807 елда инженер Шевякин эшләгән. Шевякин төпне чистартырга, яр кыегын ныгытырга, Болакны агымсулы итәргә тели. Шәһәр Думасы проектны яхшы дип таба, әмма аны гамәлгә ашырырга акча җитми кала. Тик Болакка җиңел генә кул селти дә алмыйсың, хан заманнарыннан бирле чистартылмаган килеш, ул чир чыганагына әйләнә бара.

XIX гасырның егерменче елларында танылган архитектор П. Г. Пятницкийга (университет биналары комплексының авторларыннан берсе) яңа проект эшләү йөкләнә. Архитектор үз кулы белән эшләгән рәсемнәр һәм сызымнарны да эченә алган бу проект университет китапханәсендә саклана. Проект берничә мәртәбә аныклана һәм (арзанайту максатында) үзгәртелә. Ниһаять, 1829—1830 елларда реконструкция үткәрелә. Болакны чистарталар, тирәнәйтә төшәләр, яр кыегына кәс түшиләр, күперләр салалар. Шул кыяфәтендә Болак безнең көннәргәчә килеп җитте.

Шәһәребезнең үткәне дә, бүгенгесе дә Кабан белән, Болак белән бәйле. Алар турында җырлар, шигырьләр, поэмалар язылган. Лондонны — Темзадан, Парижны — Сенадан, Мәскәүне — Мәскәү елгасыннан башка күз алдына ки-

тереп булмаган кебек, Кабан белән Болактан башка Казан да — Казан түгел.

Кабан һәм Болак тирәсендәге иң шау-шулы, ыгы-зыгылы урын Печән базары булган. Монда исәпсез-хисапсыз лабазлар, амбарлар сузылып киткән. Сәүдә көннәрендә «кайнамакта бу базар». Кем генә юк монда. Һөнәрчеләр, чуар шәлле сәүдәгәр хатыннары, крестьяннар, тар кара бишмәтле шәкертләр дисеңме, ул чалма-чапанлы руханилар, ялан тәпиле бала-чага дисеңме... Аршын, ачкыч бәйләме тоткан приказчиклар әрле-бирле йөренә. Кызыл мал, вак-төяк, сабын, чәй, аш тәмләткечләр белән сәүдә бара. Шунда ук чәчтарашлар пәке кайрый, сакал-мыек төзәтә. Җәмигъ мәчетен кан саркып торган җәрәхәтләрен, гарип әгъзаларын товар кебек тиешенчә күрсәтергә омтылган гарип-гораба, теләнчеләр сырып алган.

Болак буенда ел саен 1 майдан алып 1 июньгә кадәр язгы ярминкә үткәрелгән. Татарлар аны — Ташаяк ярминкәсе дип, руслар Биржа дип атап йөрткәннәр. Балачагы, яшьлеге Казанда үткән С. Т. Аксаков (Казаннан 1806 елда китә) бу ярминкәләрнең матур тасвирламасын калдырган. Әдип язуынча, «җәйләрен сай, лайлы вә сасы була торган» Болак язын үзгәрә. Идел суы ыргылып кереп, коргаксып торган ярларны мөлдерәмә тутыра. Форсаттан файдаланып, Кабан аша Иделдән Болакка көтүе-көтүе белән төрле вак товар төягән зур вә бәләкәй көймәләр кереп, инешнең өстен тәмам каплап ала.

«Бердәнбер ярминкәләре була торган ошбу вакытны Казан халкы һәрвакыт түземсезләнеп көтеп ала. «Көймәләр килде» дигән хәбәр минут эчендә бөтен шәһәрне аякка бастырыр иде. Болакның һәр ике ягында шау-шу, күңел ачулар башланып китә. Нәкъ менә изге атнада Мәскәүдә Новинский янында булганча, Болакның пычрак яр буйларын халык сарып ала. Төрледән-төрле товар, эфлисун-лимон арасында, фарфордан, пыяладан, яшел лак йөгерткән, кызыл балчыктан ясалган савыт-саба бихисап булыр иде. Савыт-саба берлә кызыл балчыктан яисә пыяладан ясалган үрдәк-каз вә сыбызгы, су чәчрәткеч кеби уенчыклар алып киләләр иде. Ул көннәрдә бөтен Казанны бетереп, Болак тирәләрендә аерата, сатып алынган өр-яңа уенчыклар берлә «коралланган» өер-өер малайлар, кызлар ниндидер куанычлы вә кыргый бер дәрт илә чабышып-сикерешеп йөрерләр, сызгырырлар, чыр-чу килерләр, чәчрәткечләрдән төрле тарафка су фонтаннары аттырырлар, берләрен һәм хәтта өлкәннәрне дә коендырырлар иде. Бу хәлләр һәммәсе бер ай буена шулай дәвам итәр иде.

Халыкны, татар вә рус, кала вә сала киемнәре кушылмасын тамаша кылырга Казан аристократиясе дә килер иде. Мондый чын бер халык сәүдәсе вә уены бик тә кызыклы вә күрекле була иде».

Ташаяк ярминкәсендә елына миллион сумлык товар сатылган — заманы өчен зур сумма инде бу! Монда таш лабазлар, складлар, исәпсез-хисапсыз агач кибетләр һәм кибетчекләр тезелеп киткән була. Аларның кайберләре безнең гасырның илленче елларына кадәр килеп җитеп, циркның яңа бинасын төзегәндә генә сүтелде. Сүз уңаеннан, ул нәкъ менә ярминкә вакытында цирк балаганнары корыла торган, шамакайлар, аю биетүчеләр, курчак уйнатучылар тамаша күрсәткән урында калкып чыкты.

Кабан белән Болак үзенә күрә шәһәрнең рус һәм татар өлешләрен аерып торган чик тә булган. Татарлар бары Октябрь революциясеннән соң гына Казанның биегрәк һәм, димәк, корырак ягында нигез кору хокукы алганнар. Кремльгә керү юлында исә: «Татарларга һәм этләргә керү тыела» дигән язу булган. Кышларын рус һәм татар яклары Кабан бозында ике гаскәр кебек йөзгә йөз килә торган булганнар. Бу йодрык сугышларын ни дип бәялик? Милли дошманлык утын өреп дөрләтүче кыргый һәм рәхимсез яман гадәт дипме? Әллә үзенә күрә бер күңел ачу, көчкуәтеңне, егетлегеңне күрсәтергә мөмкинлек биргән хәтәр, әмма кызыклы күмәк уен дипме? Хаклык тегесендә дә, монысында да бардыр.

ҺӨҖҮМ КӨЧӘЯ

Сабын патшалыгы.
Суүткәргеч төзү.
Кабан пароходлары.
Дума һәм Болак.

XIX гасыр урталарында, капитализмның бик тиз үсүе сәбәпле, кешенең табигатькә тәэсире дә нык көчәя. Күл тормышында яңа этап — аның бик тиз пычрана һәм үлә бару чоры башлана.

Кабанны пычратуга иң зур «өлеш» кертүче, мөгаен, абыйлы-энеле Крестовниковларның Якын Кабан буенда салынган һәм тора-бара үзенә күрә бер шәһәрчеккә әверелгән сабын заводыдыр. Гасыр азагына ул, ел саен 150 мең пот стеарин шәм, 205 мең пот сабын җитештереп, алар белән ярты Рәсәйне тәэмин итеп тора. Шул

заманда чыккан шәһәр белешмәлекләрендә Казан сабын патшалыгы дип атала. Крестовниковлар гәрчә агулы суны Кабанга түкмичә, агач улактан шәһәр читендәге сазлыкларга агызсалар да, заводның зарарлы тәэсире барыбер сизелми калмый. Һава бассейны пычрана. Яңгыр суы, кар суы завод ишегалдында җыелган сабын күбеген, май һәм пычракны Кабанга юып төшерә.

XIX гасыр азагында Казанда инде, күп санлы остаханәләрдән тыш, 92 завод һәм фабрика була. Аларда 5900 кеше эшли, ун миллион сумлык продукция җитештерелә. Гасыр башындагы белән чагыштырганда бик зур алга китеш бу. Шәһәр дә нык кына үсә: 25 квадрат километр мәйданда инде 140 мең кеше яши. Мең таш, тугыз мең агач бина була. Бер һәм ике катлы йортларга өстән унөч мәчет, кырык чиркәү манарасы бага. Халык биш йөздән артык коедан су ала. Тик күбесенең суы тозлы, тәмсез була.

Хәзер ышануы да кыен: хәтта XX гасыр башларында да нәҗеснең нибары уннан бер өлеше генә шәһәрдән читкә чыгарыла, калганы, җир асты суларын агулап, туфракка сеңә, яисә... Кабан буена яки күлнең үзенә үк түгелә. Кыш буенча махсус обозлар Кабан бозына «сасы алтын» ташый. Бөтен өмет язгы ташуга баглана. Ләкин ташу ел да күл суын яңартырлык дәрәҗәдә көчле булмый.

Күл суын биегрәк тотар өчен Болак башланган җирдә капкалы буа корыла. Язын капка күтәртелә, Идел суы Кабанга кереп кала. Шул көннәрдә Болак, Казан суы һәм Иделдән күлгә көймәләр, төзелеш саллары, тоз, ташкүмер һ. б. товар төягән зур булмаган баржалар һәм хәтта пароходлар да керә.

1875 елда Казанда суүткәргеч төзелә. Моның алдыннан озак кына бәхәс бара: суны кайдан алырга? Башта Урта Кабанда су алу пункты төзү күздә тотыла. Тик, экономик яктан зур өстенлекләре булуга карамастан, бу вариант кире кагыла: күлнең пычрануы бар! Якын Кабанның язмышы шәһәр башлыклары өчен гыйбрәтле бер сабак була. Урта Кабан тирәләренең җәен меңнәрчә кеше ял итә торган урынга әйләнүе дә искә алына.

Суүткәргеч шәһәрдән унсигез чакрымдагы Пановка чишмәсеннән су кудыра башлый. (Бу линия әле дә эшли, ул Казанның югары өлешен тәэмин итеп тора.) Су, әлбәттә, байгуралар, хәлле гражданнарның өйләренә генә керә. Ярлы-ябагай һәм Болак аръягы халкы һаман әле Кабан суын эчәргә мәҗбүр. Шул елларда тиф, дизентерия, ашказаны-эчәк авырулары белән чирләүчеләр күбәя. Бу

хәл җәмәгатьчелекнең игътибарын яңадан күлгә юнәлдерә.

XIX гасырның сиксәненче елларында врач Купидонов Якын һәм Урта Кабан суына бактериологик анализ үткәрә. Нәтиҗәләрен 1890 елда төсле дагерротиплары булган аерым китап итеп бастыра. Китапның төп фикере шул: Якын Кабанның суы суүткәргечтәгедән 150 мәртәбә пычраграк икән. Ә менә Урта Кабан суы суүткәргечтәгедән (ягъни чишмә суыннан) да чистарак. Купидонов төп пычрату чыганакларын да күрсәтә: яр буендагы чүплекләр-тиреслекләр, кер юу һәм су коену урыннары, фабрикаларның агынтылары, бәдрәф һәм юынтык чокырлары.

Кабан суын бераз соңрак тикшергән профессор Глинский да асылда шундый ук нәтиҗәләргә килә. Әмма бу вакытта эпидемия куркынычы чигенә төшеп, җәмәгатьчелекнең дә бу мәсьәләләргә игътибары кимегән була. Язгы ташу да үзенең аруландыру миссиясен уңышлы үтәп килә. «Язгы ташкыннар да булмаса,— дип яза 1893 елда профессор А. Я. Щербаков,— Кабан суы гаять дәрәҗәдә пычраныр, күл күк булмас, чын мәгънәсендә әшәке сулар тонып торган чокырга әйләнер иде.»

Күлне өйрәнүгә татар галимнәре, язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләре дә өлеш кертә. Хосусан, тарихчы һәм дин белгече Шиһабетдин Мәрҗанинең хезмәтләрендә күлнең тарихы турында кызыклы гына мәгълүматлар бар. Каюм Насыйри беренче булып Кабан турындагы легендаларны җыя һәм бастырып чыгара. Алдынгы карашлы күпкенә татар зыялылары Кабанны, Болакны һәм алар тирәсендәге кварталларны төзекләндерү өчен җан аталар. Бер генә мисал, 1907 елның 15 ноябрендә яңа клубта татарлар өчен лекция була. Учительская школа укытучысы И. В. Терегулов җыелганнарга йогышлы авыруларның аерым алганда, ваба кизүенең килеп чыгу сәбәпләрен аңлата, шәхси гигиена мәсьәләләре һәм шәһәрдә суның чисталыгын саклау өчен зарур чаралар турында сөйли («Казанский вечер» газетасы, 1907 ел, 16 ноябрь).

Безгә килеп җиткән фоторәсемнәр һәм рәссамнарның әсәрләреннән Якын Кабанның яр буйлары XIX гасырда никадәр үзгәргәнлеген чамаларга була. Укытучылар семинариясенең ак кирпечтән салынган бинасы, Дүрт евангелист чиркәве, Мәрҗани, Юнысов мәчетләре һәм бигрәк тә Болгар дәүләтенең ислам динен кабул итүенә мең ел тулу уңае белән, инде тәмам тузган агач мәчет урынында салынган Иске таш мәчет (Һади Такташ урамында, хәзер анда балалар бакчасы) күлгә ямь өстиләр.

1868 елда Н. Свешников «Якын һәм Ерак (ягъни Урта) Кабан күлләре буйлап йөрү өчен «пассажир пароходчылыгы» оештыра. Әнә шул вакыттан алып күлләр буйлап регуляр пароход хәрәкәте башлана. Якын Кабанның бер ярыннан икенчесенә паром йөри башлый.

Пристань Болак башланган турыда, трамвай тукталышы янында корыла. Монда күпчәкле пароходлар — «Нептун», «Казанец», «Джигит», «Ласточка» һ. б. туктый торган була. Пароходлар арасында хәтта «Бобчинский» белән «Добчинский» да була — аларның хуҗасы, сыра заводы хуҗасы Оскар Петцольд юмор сөюче кеше булган, күрәсең.

Бу нәни пароходлар пассажирларны кая ташый соң? Казан юнкерлар училищесының Урта Кабандагы җәйге лагерьларына, Серебрянников, Андреевский кебек Казан байларының дачаларына. Җитмешенче еллар азагында Урта Кабанда кымыз шифаханәсе эшли башлый. 1885 елда монда үтә зур тантана белән «Аркадия» бакчасын ачалар. Ямьле табигать кочагында, бәләкәйрәк урман эчендә менәниләр була: зур заллы җәйге театр, ресторан, «җәмәгать җыелышлары һәм күңел ачу өчен урыннар» — кегельбан, бильярд бүлмәләре, тирлар, «иң яңа тасмалары булган синематограф» һ. б.

Ул чор газеталары болай дип яза: «Аллеяларда халык мәш килә... Берьюлы бернечә оркестр уйный... Бер генә буш өстәл, бер генә буш урындык та юк...»

«Аркадия»дә татарның күп кенә культура әһелләре дә ял иткән. Монда Тукай хозурланып йөргән, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал озак-озак яшәп алган.

Болар бар да хәзер «Теплоконтроль» берләшмәсенең гүләп-дуылдап торган иләмсез зур корпуслары, күрексез складлары урынында булуын күз алдына китерүе дә кыен.

Гасыр азагында Болак тагын ләмгә бата, йогышлы чирләр чыганагына әйләнә. Үзенең белешмәлегендә («Спутник по Казани») профессор Н. П. Загоскин: «Болактан инде барына да күнеккән Казан кешесе дә чыдый алмаслык авыр ис килеп тора» дип язган. Ул елларда Кабанны һәм Болакны савыктыруны максат итеп куйган күп төрле «прожектлар» эшләнә. Әйтик, махсус канал казып, мул сулы Мишәне Кабанга бору, яисә, агым хасил итәр өчен, Идел белән Кабанны ике яклап тоташтыру күздә тотыла. Бу проектлардан иң шиклесе, әмма иң арзанлысы сайлап алына. Аның авторы Болак төбендә артезиан скважинасы борауларга тәкъдим итә. Шуннан соң, янәсе, су үзе Болакка

бәреп торачак һәм аны сафландырачак. Бораулыйлар. 44 метр тирәнлектә, чыннан да, чиста су табыла. Ләкин нигәдер бәреп чыгарга теләми ул — Болак төбенә бер сажин кала туктый.

КҮЛ НИЧЕК ҮЛӘ?

> «Кабан суы, бигрәк тә якын Кабанда, нык пычранган. Пычрану чыганагы — урамнардан, яр буйларындагы ишегалларыннан агып төшкән су, заводлар, бигрәк тә «Спартак», күн заводы, Вахитов исемендәге сабын заводы һ. б. агынтылары, кер уу, ат коендыру, бозга түгелә торган тирес һәм нәҗес.
>
> ..Кабанны чистартырга, тагын да пычрануына юл куймыйча, аны агымсулы итәргә кирәк. Пычрак, баткак ярларын тигезләргә, ныгытырга һәм ял, спорт өчен, су коену өчен яшел зонага әйләндерергә кирәк».
>
> *В. Н. Сементовский. «КДУның гыйльми язмалары». 1940.*

Беренче күкрәү. Яңа индустриаль сикереш.
Куйбышев сусаклагычы төзелү.
Үлем алды гаргарәсе.

Болак һәм Кабан революциядән соңгы күп вакыйгаларга шаһит. Кайчагында алар тамашачы булып калырга да теләмиләр сыман. Егерме беренче елгы ачлык вакытында күпләрне ач үлемнән Кабан күле, аның балыгы коткара. 1918 елның мартында игълан ителгән «республика» тарихка «Болак аръягы республикасы» булып кереп калган. Башында Ильяс Алкин торган хәрби Шура ислам байрагы астына, «тимер дружинага» 12 меңгә якын кеше туплый. Мулланур Вахитов җитәкчелегендәге Мөселман социалистик комитеты әлеге республикага катгый рәвештә каршы чыга. Казан эшчеләре мөрәҗәгать иткәч, Ленин Мәскәүдән өч йөз матрос, бер пехота батальоны һәм бер бронепоезд җибәрә. Казан большевиклары Татар бистәсендә аңлату эше алып баруы сәбәпле, кан коюлар булмыйча кала. Туплардан бер-ике залп бирү белән, «республика» юкка чыга.

Илдә гражданнар сугышы барганда, Кабанның чисталыгын саклау кайгысы булмый, әлбәттә. Әмма күлнең үз

хәле хәл. «Якты көннәр» килгәнне көтеп тора алмый бит ул.

«Беренче күкрәү» 1926—1927 елларның кышына туры килә. Якын Кабанда балыкның күпләп үлүен җирле газеталар әнә шулай дип атыйлар.

Кыен вакытлар булуга да карамастан, республика халык комиссарлары Советы Казан университеты профессоры В. В. Миславский җитәкчелегендә махсус комиссия төзи. Комиссия үзенең сүзен кистереп әйтә: Кабан күле бик пычранган. Су һәм ләм анализлары әнә шул турыда сөйли. Якын Кабанда туберкулез бациллалары, Урта Кабандагы белән чагыштырганда, утыз мәртәбә күбрәк булып чыга. Промышленность сулары агып төшкән җирдә кислород бөтенләй булмый.

Комиссия фикеренчә, бу хәл күптөрле сәбәпләрнең бергә туры килүе нәтиҗәсендә мөмкин була. Беренчедән, Казан — Свердловск тимер юлын салганда Якын һәм Урта Кабаннарны тоташтырган элекке бугаз күмелә. Күпер астыннан үтә торган яңасы исә шактый тар да, сай да була, һәм күлләрнең су алмашуын тәэмин итми. Икенчедән, Беренче бөтендөнья һәм гражданнар сугышы, сугыштан соңгы бөлгенлек-җимереклек елларында шәһәр хуҗалыгы тәмам ташландык хәлгә килгән була. Чүп-тирес чыгару белән бөтенләй диярлек шөгыльләнмиләр, күл тирәсе урамнарындагы шакшы су чокырлары чистартылмый. Һәм, ниһаять, халык хуҗалыгы аякка басу белән, күлгә торган саен көчлерәк булып промышленность сулары ага башлый.

Комиссия түбәндәгеләрне тәкъдим итә: чистартылмаган суларны күлгә агызуны кичекмәстән туктатырга, чүплекләрне күл тирәсеннән күчерергә, бозга тирес түгүне тыярга. Мондый саклык чараларының гына җитмәвен аңлап, комиссия Кабан белән Болакның аеруча пычранган җирләрен генә булса да чистарту мәсьәләсен дә күтәрә.

Татарстан хөкүмәте кайбер чаралар күрә. Чүпне сугарулы басуларга чыгаруны оештыра, күл буйларына тирес түгүне тыя, күлнең хәлен тикшереп тору өчен санитар постлар булдыра. Әмма шәһәр промышленносте һаман үсә бара бит. Яңа йортлар салына, халык саны арта. Болай да сәләмә канализация челтәре бу үсештән нык калыша. Шушы нәрсә иң гүзәл ниятләрне дә тар-мар китерә инде, индустрияләштерү башланган еллар рәхимсез, мәҗбүри экономияне таләп итә иде.

1927 елның 14 сентябрендә Казан шәһәр башкарма комитеты каршында төзелгән Болак комитетының утырышы үткәрелә. Комитет профессор Енш проекты буенча баш-

ланган эшне дәвам иттерергә кирәк, дигән карарга килә [1]. Проектка кайбер төзәтмәләр дә кертелә. Әйтик, бер җир асты коллекторы урынына кечерәк диаметрлы ике кирпеч торба салырга булалар. Башкарма комитет тиешле акчаны бирә. Планлаштырган эшләрне 5—8 елда башкарып чыгу күздә тотыла.

Эшкә 1928 елда керешәләр. Беренче елда Куйбышев урамыннан Университетская урамына кадәрге араны салалар. Торбаларның шушы бәләкәй өлешен генә эшкә җигеп карау да сагаерга мәҗбүр итә. Бердән, авышлык аз булу сәбәпле, агым көчсез була. Икенчедән якын-тирәдәге урамнардан агып төшкән пычрак сулар коллекторны томалый.

Бәхеткә каршы, торбаларны күмеп өлгермәгән булалар. 1929 елның 11 маенда комитет яңадан җыела. Озак кына барган бәхәсләрдән соң, болай дип хәл итәләр: «Профессор Еншның проектын тагын да өйрәнергә, Болак белән Кабанны савыктыру проектларының кайсы кулай икәнлеген ачыкларга кирәк булу сәбәпле, Болакта торба салуны туктатырга». Әлеге документта Болак белән Кабанның янәшә торулары игътибарга лаек. Комитет әгъзалары Кабанның хәле Болакка бәйле булуын белгәннәр, димәк. Күл үзенең Казан суы һәм Идел белән мәңгелек бәйлелеген җуйса, үлемгә дучар булачак... Торбаның бер өлешен сүтеп алалар, калган өлеше соңыннан үзе ишелеп-җимерелеп бетә.

Утызынчы елларда һәм соңрак Болакны төзекләндерү проблемасы белән күп кенә белгечләр шөгыльләнә. Алар арасыннан архитекторлар Г. М. Спиридонов, Р. М. Мортазин, Н. Е. Чернядьевларны, инженер Л. К. Сошконы атый алам.

Утызынчы еллар уртасында Дәүләт шәһәр проектлаштыру институты («Гипрогор») Болакны һәм Якын Кабанны савыктыру проектын эшли (авторы — инженер А. Доценко). Болак белән Кабан төбен чистарту, Иделдән Болакка, Болак аша Кабанга чиста су кудырту һәм күлләр тезмәсендә суның агып торуын тәэмин итү — барлыгы өч миллион сумлык эш башкару күздә тотыла.

Исхак Казаков проекты да кызыклы була. Анда Болакны яңадан Кабан күлен Идел белән тоташтыручы, суднолар йөрешле каналга әверелдерү карала. Шәһәр пристанен Болак тамагына, Казан Кремле янына ук,

---

[1] Беренче Бөтендөнья сугышы башланыр алдыннан (1913—1914 елларда) Енш фамилияле профессор Болакны реконструкцияләү проектын төзи. Бу проект буенча Болак калын бетон торбага яшерелеп, өстән күмелергә тиеш була.

ягъни элекке тарихи урынына күчерү күздә тотыла. Икенче бер канал Урта Кабанны Идел белән тоташтырырга тиеш була, шул чагында бөтен күлләр тезмәсендә су да даими агып торыр, суднолар да йөреп торыр иде. Акча аз булу сәбәпле, Казаков проекты кире кагыла. Ф. Доценко проекты исә өлешчә генә тормышка ашырыла. 1936—1938 елларда Болак төбе бик әйбәтләп чистартыла, тирә-нәйтелә, ярларына кәс түшәлә. Эшне ярты юлда сугыш туктата. Сугыш беткәннән соң махсус суүткәргеч төзелә. Металл торбалар җитмәү сәбәпле, күп урында сумаланган агач улаклар салына. Тишек-тошыклардан су агып-саркып тора. Шуңа да карамастан, үзгәреш сизелә. Болак кабат җанлана, Кабан да күзгә күренеп тернәкләнә. Шул вакыттан башлап илленче елларның икенче яртысына кадәр Болакта (Кабан турында әйткән дә юк) бала-чага рәхәтләнеп су коена. Шул чорда популяр булган «Тарзан» фильмының героена охшарга тырышып, малай-шалай Сулъяк Болак урамында мунча тирәсендә үсеп утырган (кызганычка каршы, элек үскән, дип өстәргә туры килә) биек тирәкләрдән атынып, маймыллар кебек чинашып суга сикерешә иде.

Күл суын тиешле бер тирәнлектә тотар һәм язгы суларны җыеп калыр өчен Болакның ике башына су капкалары куела. Шулар ярдәмендә Якын һәм Урта Кабанда су дүрт метрга күтәрелә, күләме исә җиде миллион куб метрга арта.

Бер үк вакытта архитектор У. Г. Алпаров һәм М. К. Игъламовлар проекты буенча Болак буйлары реконструкцияләнә: яңа биналар салына, череп беткән агач күперләр урынына яңалары төзелә. Күл ярлары милли орнаментлы чуен рәшәткә белән әйләндерелеп алына. (Казанлылар күңеленә хуш килгән бу орнамент Болакны реконструкцияләүнең яңа проектында үзгәрешсез калдырылган.)

Утызынчы елларда шәһәребездә эре машина төзү, металл эшкәртү, синтетик каучук, кинопленка, фотожелатин заводлары, мех комбинаты, киез итек-киез фабрикасы һ. б. сафка баса. Кырыгынчы елга башкалабыз промышленность продукциясен революциягә кадәрге белән чагыштырганда унике тапкыр күбрәк бирә. Әйләнә-тирә мохитка төшкән басым, әлбәттә, шушы үсешкә тәңгәл була.

1929 елда ике Кабан тирәсендә урнашкан заводлар һәм фабрикалар ел дәвамында күл суының унике процентын, 1935 елда — дүрттән берен, утызынчы еллар ахырына яртысыннан күбрәген файдалана. Бу елларда Якын Кабанга иң зур зыянны «Спартак» аяк киемнәре комбинаты

ясый, бу хакта заманында матбугатта күп язылган. Комбинат тәүлек саен күлгә зәһәр кислота, көчле агулар, тире иләү калдыклары агыза.

Сугыштан соң Казан промышленносте янә зур сикереш ясый. Куәтле компрессорлар, электрон-хисаплау машиналары, реактив һава лайнерлары, вертолетлар, полиэтилен һәм халык хуҗалыгы өчен гаять мөһим тагын бик күп төрле продукция җитештерә торган уннарча яңа предприятиеләр эшли башлый. Искеләренең дә куәтләре күп тапкырлар арта. Кабан тирәсендә яңа микрорайоннар үсеп чыга...

Элекке су чыганагы ролен югалта барган Кабанга яңа бурычлар йөкләнде. Ул менә дигән ял итү урынына әйләнде. Студент чакларда, бераз гына буш вакыт чыктымы, Кабанга чаба торган идек. Анда һәрвакыт көймә алып була, туйганчы йөзәсең, кызынасың. Кабанда ГТО нормалары тапшырдык, күмәк йөзүдә катнаштык, курсташыбыз, ишү буенча РСФСР чемпионы Виктор Шадринга куәт өстәргә дә килә торган идек. Бәйрәмчә күтәренкелек, төрле төстәге әләмнәр җилфердәве, көймәләр һәм байдаркалар ярып барган киң, шома су өслеге күңелгә гаҗәеп бер хатирә булып кереп калган.

Казан тирәсендәге су мәйданы нинди генә иркен булмасын, Идел дә, Казан елгасы да бу җәһәттән Кабанны алыштыра алмый. Күл җил-дулкыннан ышыкланган, анда башка сулыкларда була торган агымнар да юк. Җитмәсә, үзе — шәһәр уртасында. Спортчылар Кабанны күнегүләр үткәрү өчен идеаль урын дип саныйлар. Кабан булмаса, аны казырга кирәк булыр иде, дип әйтергә ярата алар. Коену урыннары, көймә һәм спорт станцияләре, трамплиннар һ. б. корылмалары булган Кабан кырыгынчы-илленче елларда Россия Федерациясендә иң әйбәт су стадионы булып санала иде. Монда әледән-әле Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз ярышлары үткәрелеп торды.

Илленче еллар урталарында күлнең яңа биографиясен ачып җибәргән вакыйга булды. Куйбышев ГЭСы Идел суының Казан тирәсендәге биеклеген 11,3 метрга күтәрде. Шәһәрнең шактый өлеше түбәндәрәк булганга, катлаулы инженерлык корылмалары — дамбалар, дренаж чокырлары, насос станцияләр төзергә кирәк иде. Урта һәм Якын Кабаннар да сусаклагыч өслеге биеклегеннән 1,5—2 метрга түбәнрәк булып калды. Кабанны элеккечә Болак аша Казан елгасы һәм Идел белән тоташкан килеш калдырганда, Идел суы, күлне тутырып, якын тирәдәге урамнарны басачак иде, шуңа күрә Болак тамагын күмеп, аны Казан

суыннан дамба белән аердылар. Хәзер Болак Казан елгасына киңлеге ике ярым метрлы җир асты юлы аша, Иделгә исә аркылысы бер метр булган су юлы аша гына тоташкан. Хәер, тоташкан дип әйтү дөрес үк булмас, чөнки һәр ике су юлында да ачылмалы капка бар, алар, гадәттә ябык хәлдә тора.

Шәһәрнең икенче башында, су ташыганда Урта Кабан Идел белән ермак аша тоташкан җирдә дә дамба салынды. Шулай итеп, күлләр Иделдән киселеп калды, Кабан зарарлы матдәләр торган саен күбрәк туплана барган йомык экологик системага әйләнде.

Хәер, сусаклагычның гидростатик басымы тәэсирендә җир асты горизонтларыннан күлләргә берникадәр су кереп тора торуын. Яңгыр-кар сулары, промышленность, канализация агынтылары да бар бит әле. Арткан суны суыртып чыгарыр өчен Болак тамагында һәм Урта Кабанның ерак читендә ике насос станциясе төзелде. Алар, артык суны Иделгә һәм Казан елгасына кудырып, күлне ел әйләнәсе бер югарылыкта тоталар. Сусаклагычның су өсте биеклегенә һәм явым-төшемнең күпме булуына карап, кайбер елларда бер ярым яки хәтта ике Кабан күләмендә су суыртып чыгарыла.

Күл төбен ләм, пычрак томалаган саен сусаклагычтан су саркып керү кими һәм бөтенләй туктауга бара. Шуңа бәйле рәвештә, арткан суны суыртып чыгару да кими һәм, димәк, күлдәге агымлылык та елдан-ел кими бара.

Тулаем алганда, Куйбышев сусаклагычы төзү шәһәрнең санитария хәленә уңай йогынты ясады. Гасырлар буе чүп түгү урыны, чир чыганагы булган баткак уйсулыклар, сазламыклар су астында калды. Элекке Ташаяк урамындагы баткак урын юкка чыкты, монда Үзәк стадион төзелде, цирк «тәлинкәсе» барлыкка килде. Болак һәм Кабан яр буйларын төзекләндерүгә, дамбалар, пляжлар, күперләр, көймә станцияләре коруга дәүләт миллионлаган сум акча бирде.

Иң мөһиме әле бу да түгел. Куйбышев ГЭСы төзелгәнгә кадәр шәһәрне әледән-әле су баса торган иде. Ташу көчле булган елларда Казан халкы миллионнарча сумлык зыян күрә, кайчак хәтта һәлакәтләр булгалый иде.

Әнием 1926 елгы туфан турында сөйләгәне хәтердә калган. Ул чакта аңа егерме ике яшь булган. Су гомер булмаганча күтәрелгән (диңгез өсте биеклегеннән — 56 метр, Куйбышев сусаклагычның иң биек җиреннән дә өч метр биегрәк). Болак мөлдерәмә тула, су тротуарларга ташый. Ярларыннан чыккан Кабан дәһшәтле кармавычларын төр-

ле якка суза. Яңа бистә, Архангельск һәм Кәҗә бистәләре, Казанның бөтен уйсу өлеше су астында кала. Әни яшәгән К. Насыйри һәм Татарстан урамнары чатыннан кая да булса бары көймәдә генә барып булган. Халык өй түбәләренә кунаклаган, салларда йөзгән. Коткару катерлары һәм көймәләре әрле-бирле йөргән.

Кабанның уң ягында су Куйбышев мәйданы һәм Свердлов урамына килеп җитә. «Спартак» комбинатының ишегалдына чуртаннар йөзеп керә. Шәһәр электр станциясен, мех фабрикаларын су басу куркынычы туа. Дамбаларны су ашаудан да куркалар. Махсус комиссия су баскан 2611 йортта яшәүчеләрне бүтән өйләргә күчерергә туры килүен хәбәр итә. Бөтен мәктәпләр, клублар, тулай торaклар йортсыз калганнар белән тула. Республика хөкүмәте аларга ссуда бирә.

Бу кадәр үк һәлакәткә китермәсәләр дә, мондый су басулар 1929 һәм 1932 елларда да кабатлана. Шуннан соң су артык күтәрелми, ләкин су басуларга бары шәһәр инженерлык саклануы линиясе генә чик куя.

1957—1958 елларда Кабанның төбен яхшы ук чистарттылар. Земснаряд ярдәмендә яр сызыгы буйлатып 15—20 метр киңлектә, 2—3 метр тирәнлектә ләм суыртылды. Бу эшкә өч миллион сумнан артык акча тотылды. Моның күл өчен файдасы зур булды.

Кабанның йомык экологик система шартларында үзен ничек хис итүе мәгълүм түгел иде әле. Биолог В. В. Нечкина әнә шуны ачыкларга алынды. Ул илленче еллар башында (ягъни Куйбышев сусаклагычы төзелгәнче), аннары илленче елларның икенче яртысында һәм 1964—1965 елларда (күлнең яңа режимы урнашып җиткәч) тулы өч тикшеренү циклы үткәрде. Аларның төп яңалыгы шунда, галим суны химик яктан да бигрәк биологик яктан бәяли, чөнки тере организм тирәлек үзгәрүләргә аеруча сизгер.

Галим ясаган нәтиҗә шундый: күп кенә уңай яклары булуга карамастан, Куйбышев сусаклагычын төзү, тулаем алганда, күлләргә начар тәэсир иткән. Агымлылык бетү, Идел белән бәйләнеш өзелү пычрануның тизләнүенә китергән. Суның катылыгы Идел суыныкын да узып киткән. Берничә ел эчендә углекислота микъдары биш ярым мәртәбә артып, кислород микъдары шулкадәр дәрәҗәдә үк кимегән. Әмма, галим фикеренчә, төп куркыныч табигый ләмнең һәм суның күкертле водород белән агулануыннан гыйбарәт икән. Нечкина, галимнәрдән беренче буларак, Якын Кабанда тереклек калмаган зур-зур «үле зоналар» барлыкка килүен искәртә. Иң әүвәл планктон (бик вак

тере организмнар) зыян күрә, аның саны һәм төрләре нык кими. Ә бу инде су үз-үзен чистарту сәләтен җуя, авыру тудыра торган бактерияләрне мөстәкыйль рәвештә җиңә алмый дигән сүз. В. В. Нечкина үткәргән күп санлы анализлар Якын Кабанның куркынычлы инфекцияләр, кизүләр, ашказаны-эчәк авырулары һәм йогышлы мал чирләре чыганагына әверелә баруын күрсәтә.

Мондый хәл тууының сәбәбен галим шунда күрә: миллионнарча сумнар сарыф итеп тә, төп нәрсә эшләнмәгән — Кабанга элеккечә промышленность сулары һәм шакшы агынтылар елга булып коеп тора. Моңарчы күлне әледән-әле язгы ташулар сафландырса, хәзер ул чын мәгънәсендә тончыга, буыла. Нечкина шәһәр властьларыннан барлык промышленность, көнкүреш һәм канализация агынтыларын күлгә агызуны туктатырга, яр буйларындагы чүплекләрне бетерергә, сазлыкларны киптерергә, Болак белән Кабанның төбен әледән-әле чистартып торырга тәкъдим итә, дөресрәге, моны таләп итә. «Шушы елларда радикаль сәламәтләндерү чаралары күрелмәсә, Кабан котылгысыз рәвештә тиз арада гигант бер пычрак җыю урынына әйләнәчәк»,— дип яза ул. Тик... пычрак «инешләр» көчәя һәм ишәя генә бара.

Казан инде революциягә кадәр үк промышленносте алга киткән шәһәр булуга карамастан, республикабыз 1979 елда промышленность продукциясен, 1913 ел белән чагыштырганда, 770 тапкыр күбрәк эшләп чыгара. Сиксәненче еллар уртасында завод-фабрикаларыбыз бер көндә генә дә элек ике елда эшләп чыгарылган кадәр, бер айда исә бөтен XIX гасырда җитештерелгәннән да артыграк продукция биргән.

1954 елдан 1979 елга кадәр Казан халкы ике тапкыр артты һәм бер миллион чиген үтте. Шулай итеп, абсолют саннарда Казан халкы чирек гасыр эчендә элек сигез гасыр дәвамында артканнан да күбрәк арткан. Шәһәр үзе дә, аның әйләнә-тирәсендәге ландшафт та үзгәрә, чиста су күбрәк тотыла, производство калдыклары исә геометрик прогрессиядә арта бара.

КАБАННЫҢ КАН ТАМЫРЫ

Сәер операция. «Хирургия» ярдәм итәрме?
Тагын бер проект.
Медальнең икенче ягы.

Җитмешенче еллар башында бер очында Казан суыннан, икенче очында Кабаннан өзеп калдырылган Болак

асылда сасы су җыелган озынча бер чокырга әйләнде. Янышнан борынны кысып кына үтеп була иде. Санэпидстанция, Болак куркынычлы инфекцияләр чыганагы булып тора, дигән нәтиҗә ясады. Аның череп барган суында һәм лайлалы ләмендә табигатьтә очрый торган чир таратучы бактерияләрнең бөтенесен дә тапканнар, имеш. Җитмәсә, ул бу төбәкнең җир асты суларын да пычратыпагулап тора әле.

Ул елларда шәһәр Советыннан теге яки бу рәвешле Болак мәсьәләсенә кагылмаган бер генә сессиясе үтте микән? Бер-бер артлы проблемалы мәкаләләр, корреспонденцияләр басыла торды, фельетончылар, Болак турында язып, тапкырлыкта ярышты. Хезмәт ияләреннән хатлар, шикаятьләр өзелмәде...

Ниһаять, көтелгән минут килеп җитте: «Болак» операциясе башланды!

Яр буйлап зур әрҗәле самосваллар чиратка баскан. Чылбырлары шалтыр-шолтыр килгән куәтле экскаватор, гайрәтле селтәнеп, берничә куб метр сыйдырышлы чүмечен ләмгә батыра. Тик... сасы шулпа теш араларыннан агып бетә, чүмечнең мыегы гына чыланып кала. Суны куәтле насослар белән суыртып карадылар. Монысы да барып чыкмады, көчлерәк суырткан саен, сулы горизонтлар аша күбрәк керә торды. Куйбышев сусаклагычыннан Болакны йөз метрлап кына ара аерып тора бит. Ләмне суы белән чумырып алырдай чүмеч куеп та карадылар. Тик кара «шулпа» самосвал әрҗәсендәге ярыклардан чаптырып акты.

Җыелган халык төрлечә теш ыржайтты:

— Йә, кем самосвал белән су ташый инде?

— Тагарак белән ташыгыз, тизрәк булыр!

— Земснаряд кирәк, егетләр! Иң кулае, иң арзанлысы шул...

Тик халык фикеренә колак салучы булмады, әлбәттә.

Экскаваторны күпергә куеп карадылар. Һәм ул, элегрәк ватылган яр буе рәшәткәләренә өстәп, күпернең таш култыксасын да селтәп атты. Болак төбе анда ныграк дип, Казан суы ягыннан аска төшерергә булдылар. Тик бу иләмсез нәмәрсә, бер якка янтаеп, бата да башлады. Әлеге сәер операция, асылда, шуның белән тәгәлләнде. Вакытның һәм акчаның калган өлеше экскаваторны «батырларча коткару»га сарыф ителде.

Тарихка мәгълүм Болак чистартуларның бу иң «соклангычын» үткәргән оешманы атыйсым килми. Бердән, проектчылар гап-гади нәрсәләрне дә күздә тотмаганга

башкаручылар гаепле түгел. Икенчедән, җитәкчеләре аяк терәп каршы килүгә дә карамастан, оешманы белмәгән-күрмәгән эш белән шөгыльләнергә мәҗбүр иткәннәр. Хәер, бу юкны бушка авыштыруның да бер файдасы тиде: «Ура» кычкырып кына Болакны җиңеп булмаячагы, техник яктан дөрес, төпле фәнни мөнәсәбәт кирәклеге ачыкланды.

Шәһәр җитәкчеләре Ленинградның каналлар чистарту буенча зур тәҗрибә туплаган «Ленгипрогор» институтына мөрәҗәгать итәләр. Институт вәкилләре, Казанга килеп, эшнең торышы белән танышалар һәм... Әллә үз белдекләре белән, әллә кемнеңдер сүзенә колак салып, мәсьәләне «хирургик юл белән» хәл кылу вариантын тәкъдим итәләр. Болакны... күмеп, зур тизлекле автомагистраль саласың да, вәссәлам!

Беренче булып иҗат әһелләре каршы чыкты. Алар инешнең тарихи әһәмиятен аңлатырга тырыштылар. Болак турында күпме легенда, риваять бар, аңа багышлап шигырьләр язылган, җырлар чыгарылган. Болак шәһәр йөзендәге бер төсмер генә, әмма нәкъ менә ул Казанның тарихи үзәгенә мөкәммәллек бирә.

Архитекторлар исә сул һәм уң Болак урамнарының күп гасырлар дәвамында яр буе урамнары булып формалашуына һәм бу аларның «төс-кыяфәтләрендә» дә чагылуга игътибар итәргә өндәделәр. Архитектура һәйкәлләренә әйләнгән күперләрне кая куясың тагын?

Гидрологлар һәм шәһәрнең инженерлык саклануы вәкиле Болакның шәһәрнең бизәге генә булмавын искә төшерделәр. Ул элек-электән артык җир асты суларын суырып-җыеп торган, бу «вазифаны» әле хәзер дә үти. Болакның стадион янындагы очында урнашкан насос станциясе ел саен меңнәрчә тонна су суыртып чыгара бит. Болакны күмү белән, Куйбышев сусаклагычы кысып этеп торган җир асты сулары якын-тирәдәге йортларның подвалларын басачак. Сусаклагычның су өсте биеклеге — диңгез өсте биеклегеннән 53 метрда, Казанның уйсулыкта урнашкан өлеше исә күбесенчә 50—52 метрда гына булуын истән чыгарырга һич ярамый.

Проектка хәтта ГАИ вәкилләре дә каршы иде. Аларның фикеренчә, транспорт агымын шәһәрнең үзәк өлеше аша үткәрү кулай булмаячак. Болай да хәттин ашкан шау-шу арта, һава пычрана. Әйләнеч юллар эзләвең хәерлерәк...

Шау-шулы тикшерүдән соң авторлар күпчелек тавыш белән кире кагылган проектны яңадан эшләргә булдылар һәм күпмедер вакыттан аның бераз үзгәртелгән вариантын

тәкъдим иттеләр. Бусы да Болакны «күмә» иде. Тик, гидрологлар сүзен истә тотып, бу юлы төптә дренаж торбалары калдырылачак. Юл урынына бакча булдырырга тәкъдим ителә иде.

Бәхәс яңабаштан кызды. Бу вариант кайберәүләргә шул ягы белән ошады: ул проблеманы бөтенләйгә хәл итәргә мөмкинлек бирә, шәһәр сасы ис һәм инфекция чыганагыннан арынып кына калмыйча, өстәмә «яшел үпкә»дә ала. Шәһәр Советына хат арты хат юллап, якын-тирәдә яшәүчеләр дә кызган табага май өстәде: күмсәгез күмегез, томаласагыз томалагыз, сасысыннан һәм шакшысыннан гына коткара күрегез!

Болакның язмышы кыл өстендә калды.

Ләкин гидрологлар бу юлы да катгый рәвештә «Юк!» диделәр. Болак шәһәрнең уйсу өлешендә, шуңа күрә яңгыр һәм кар сулары шунда агып төшә. Язын көчле яңгырдан соң проекттагы бакча 30—40 сантиметрлы су катламы астында калачак. Ул гына да түгел әле, дренаж системасы салып калдыру проектның бәясен нык арттырачак. Файдасы, ышанычлылыгы ачык каналныкыннан азрак булган хәлдә, кыйммәткә төшәчәк ул. Шул ук чыгымнар исәбенә, әйбәтләп чистартып һәм төзекләндереп, Болакны саклап калу хәерлерәк.

Экологик тигезлекне саклау зарурлыгы да исәпкә алына. Ул вакытта Кабанны агым сулы итү буенча берничә проект эшләнгән иде инде, аларның барысы да Болактан файдалануны күздә тота. Проектларның берсе менә мондый. Дамбадагы үткәрүчәнлеге үзгәртелә торган ерым аша су Куйбышев сусаклагычыннан биеклеге шул чама булган Югары Кабанга кертелә. Аннан ул, махсус суташлагыч аша, Монастырь бугазына, аның аша Урта Кабанга керә, шул рәвешле, Ботан бугазы һәм Якын Кабан аша үтеп, Болакка ага, насос станциясе суны Казан елгасына, ягъни кабат сусаклагычка кудыра.

Бу проект, аз чыгым тоткан хәлдә, бөтен системаны юдырырга мөмкинлек бирә. Һәм әле, күлләрнең хәленә карап, иң әйбәт режимда юдырып була. Тик моның өчен, күргәнегезчә, Болакның сәламәт булуы кирәк...

Менә шуларның барысын да бизмәнгә салып карагач, ленинградлыларның проекты кире кагылды.

Болакны реконструкцияләүнең бүтән проектлары да була. Берсе, әйтик, ярларны гына түгел, каналның төбен дә бетонлауны күздә тота. Болакны чистартуны нык җиңеләйтәчәк бу, әмма кыйммәткә дә төшәчәк. Ник дисәң, төпне бетонлау ГЭС котлованын төзегәндәге кебек кат-

лаулы шартларда алып барылачак, аерым участокларны шпунтлар белән аерырга, корытканчы суын суыртырга, бихисап бетон тотарга туры киләчәк. Ә файдасы ташка үлчим. Хәтта зыянлы да булачак әле: махсус калдырылган тишекләр тиз арада ләм белән томаланып, Болакның дренажлау сәләте юкка чыгачак.

1970 елның 20 февралендә Казан шәһәр башкарма комитетының төзелеш һәм архитектура бүлеге каршындагы архитектура-художество советы киңәшмәсе үткәрелде. Совет Болакны саклап калырга карар бирде. Киңәшмәдә Болакны реконструкцияләүнең ике проекты каралды. Аларның берсе Болакны текә бетон ярлы, икенчесе авыш ярлы «итә». Өстенлек соңгысына бирелде: матуррак та була, чыгымы да азрак. Асылда Болак үзенең соңгы гасыр ярымдагы кәяфәтен җуймый, бары ямьләнеп-яшәреп ала, саф сулы була. Шул ук авыш яшел ярлар; инеш бары тирәнәйтелеп, төбе һәм ян-яклары ныгытыла.

Проектны хуплыйлар һәм... оныталар. Ленинград архитекторларының проекты кире кагылгач кына табып алдылар аны.

1975—77 елларда Болак проблемасына яңа бер төсмер өстәгән вакыйга булды... 1 нче һәм 2 нче энергоүзәкләрне тоташтырган җылылык магистрале салырга кирәк булып чыга. Аны Болакның уң як яры буйлап суздылар. Ашыгыч булганга, килештереп-раслап маташмадылар, салдылар да куйдылар. Нәтиҗәдә, уң якта авыш яшел яр урынына бетон дивар пәйда булды. Ул гына да түгел, шәһәр башкарма комитетының төзекләндерү идарәсе бу «законсыз туган» стенаны бөтен Болак өчен өлге дип тапты: икенче як ярны да шундый итәргә кушылды.

Әмма җәмәгатьчелек тә тиз генә бирешергә теләмәде. ТАССР Архитекторлар союзының гомуми җыелышында әлеге карар кискен төстә тәнкыйтьләнде. Болак, тарихыбыз һәм архитектурабыз ядкаре буларак, кадерләп сакланырга тиеш дип табылды. Язучылар, журналистлар да үз сүзләрен әйттеләр. Ризасызлык шул дәрәҗәгә җитте ки, башкарма комитет хәтта үзенең карарын үзгәртергә мәҗбүр булды. «Казгражданпроект» институтына Болакны авыш ярлы итеп төзекләндерү проектын әзерләргә кушылды. Әмма... 1979 елның 20 ноябрендә, бер елдан артык вакыт үтеп, шау-шу басыла төшкәч, төзекләндерү идарәсе институтка яңадан текә бетон яр вариантына әйләнеп кайтырга кушты. Проект тиздән әзер булды. Ул менә нәрсәләрне күздә тота. Авыш туфраклы яр текә бетон стена белән алыштырыла. Стена читеннән, элек авыш яр булган



җирдән, шәһәр өчен үтә кирәкле коммуникацияләр: җылылык трассасы, суүткәргеч, магистраль канализация коллекторы уза. Яңгыр-кар сулары өчен махсус тондыргычлар төзелә. Болак, суның уртача тирәнлеге ике метрдан ким булмаган хәлдә, су өсте биеклеге Кабанныкы белән тигезләшерлек итеп тирәнәйтелә. Чистартканнан соң төпкә чуерташ һәм эре бөртекле ком җәелә, бу исә дренажлау сәләтен тулысынча саклап калачак, ләм һәм пычрак аска саркыячак дип уйланыла.

Сызымнар һәм рәсемнәрдә Болак бик «чибәр» күренә. Ике яклап челтәрле рәшәткәләр һәм юкә аллеялары сузыла, матур-матур фонарьлар эленгән. Причаллар һәм төшү юллары ясалган.

Проект 1982 елны тормышка ашырыла башлады. Бу эшне «Гидроспецстрой» трестының Казан төзү участогы алып бара. Эш бөтен шартын китереп башкарыла. Яр читләп сигезәр метр тирәнлеккә сигезәр тонналы субайлар сугыла. Субайларны аксыл-соргылт профильләнгән бетон белән тышлыйлар. Бер уңайдан күперләр дә төзекләндерелә.

Шулаен шулай да... Эшнең бик тә акрын алып барылуы борчый. Бер елда барлык эшнең нибары өч проценты чамасы гына башкарыла. Болакны тирәнәйтү, төбенә чуерташ, ком түшәү киләчәккә калдырыла. Болай барганда эшне тәгәлләү өчен тагын утыз елдан артык вакыт кирәк булачак, ягъни Болак XXI гасырның икенче унъеллыгы азакларында гына рәсемдәге кыяфәтенә керәчәк. Хан заманында Болакны тоташ казу өчен дә берничә ел гына кирәк булган лабаса!

Хәер, кайберәүләр фикеренчә, эшнең шулай сузылуы шәп тә. Вертикаль бетон яр кирәксез, элекке яшел авыш ярларны саклап калырга кирәк, ди алар. Күпме дефицит тимер-бетон материал кирәк булачак, дип, дәгъваларын экономик яктан да нигезлиләр.

Проекттан читкә дә тайпылулар байтак. Әйтик, Болакны хәзер дә тирәнәйтмәсәң кайчан тирәнәйтәсең ди?

Яңгыр суы өчен тондыргычлар, насос станцияләре, чистарту корылмалары да төзелми. Утыз-кырык ел үткәч, нигә эшләмәдегез дип сорар кеше дә калмагачмы? Юк, нәкъ менә хәзер, кул астында куәтле техника булган, акча «үзләштерелеп» бетмәгән чакта эшләргә кирәк. Минемчә, шәһәр башкарма комитеты проекттагы шартларны сакламыйча башкарылган эшне кабул итмәскә тиеш.

Проект Болакның тарихи бер өлешенә эверелгән яр буе тирәкләрен саклап калдыруны күздә тоткан иде. Алар-

ны эшкә керешкәнче үк кисеп ташладылар. Бер очтан, менә дигән юкә аллеясын да харап иттеләр.

Проекттан читләшүләр өчен кем җавап бирәчәк? Эшнең сыйфатын ничек яхшыртып, темпны ничек арттырып була? Бу сорауларны Казан шәһәр Советы башкарма комитетына адресларга туры килә.

ЭТ КАЙДА КҮМЕЛГӘН?

Кабан мескен — беткән...
Ә дуңгызлык — тора!
Равил Фәйзуллин.

Хатлар, хатлар...
Хуҗа Насретдин ишәге.
Әзер калып буенча...
Табигать дуслары булмаса...

«Элек Кабанда балык күп иде, акчарлаклар оча, балалар су керә иде. Хәзер ни бар? Күбекле дулкыннар да, кер порошогыннан акка буялып беткән ярлар гына.

Кайчандыр Кабаннан җәйге челләдә дә саф җил исә иде. Хәзер исә сабын исе, черек исе, күкертле водород исе килә».

Равил Хәсәнов.

«Без Кабан күле буенда яшибез. Икебез дә «Теплоконтроль»дә эшлибез, мин — егерме ел, сеңелем — унбиш. Күлнең күз алдында үлеп баруын күреп җан әрни. Квартирабызда гел авыр ис тора. Йокыдан уянсаң, ис тигәндәге кебек, баш авырта. Көне буе эшлисе бар бит әле... Нәни кызыбыз шуның аркасында дәрес калдыра, өлгереше начар, өйдә бөтенләй дәрес хәзерли алмый».

Апалы-сеңелле Хухровалар.

«Кичә, 1980 елның 11 августында, унынчы яртыда Вахитов исемендәге химкомбинаттан Кабанга куе ак сыекча агыза башладылар. Банкага алдым — кер порошогы. Бу хәл кичке тугызга кадәр дәвам итте. Балыкны агулап бетергәннәр иде, инде бака да калмады. Әлеге порошоктан су башта агара, аннары дегет кебек кап-кара була, ә һава — противогаз киярлек. Мондый башбаштаклыкка кайчан чик куелыр икән?»

И. А. Кирьянов, Комсомольская урамы, 312 нче йорт.

«Элегрәк сокланып туймаслык күл булган Кабанның сасы сазга әйләнеп баруы белән кайчанга кадәр килешеп яшәрбез микән? Күлгә күпме пычрак агызырга, чүп тутырырга буладыр? Шәһәр властьлары кая карый?»

Л. С. Хәбибуллина

«Болай яшәргә ярамый! Форточканы ачарлык түгел. Ачмасаң да — һава җитми. Иртән йокыдан мунчада ис тидергән сыман торасың. Берни дә эшләп булмый микәнни соң?»

18 имза куелган күмәк хаттан.

Мин берничә хаттан гына өзек китердем. Ә аларның исәбе-хисабы юк. Казан шәһәр Советы башкарма комитетында Кабанны пычрату турындагы хатларны аерым папкаларга тегеп баралар. Соңгы елларда гына да калын-калын өч папка тупланган.

Аларга матбугаттагы чыгышларны да өстәргә кирәк. Тулы булмаган мәгълүматларга караганда да, 1971 елдан 1987 елга кадәр җирле һәм үзәк матбугат, радио, телевидение Кабан һәм Болак проблемалары турында 38 мәртәбә чыгыш ясаган. Миндә саклана торган материаллар гына да бер папка.

Күп кенә хатларда бер үк сорау кабатлана: нигә? Нигә, бернинди икеләнүсез-куркусыз күлләрне пычраталар, табигатьне һәлак итәләр? Нигә җәмәгатьчелекнең протестларына, матбугаттагы чыгышларга да карамастан, хәл төзәлми генә түгел, киресенчә, елдан-ел начарлана бара? Кем гаепле? Хикмәт нәрсәдә?

Кая гына язылмасын, газета, радио, телевидение редакцияләренәме, яки абруйлы үзәк органнаргамы — хатлар барыбер, ахыр чиктә, шәһәр Советы башкарма комитетына килеп керә.

Мине бу очракта эш йөртү тәртибе гаҗәпләндерде. Менә хат килде, газетада мәкалә басылып чыкты ди. Шуннан соң ни була? Бюрократ көлеп кенә куяр: хат килгән икән, димәк, аңа җавап язарга кирәк. Аннары инде ник шунда дөньясының асты өскә килми.

Хатлар төрлечә языла. Җаваплар исә бер әзер калыпка салынган. Хәер, ике төрле калып бар. Беренчесе, кыскарагы — аерым кешеләрнең хатларына җавап язу өчен. Икенчесе, киңрәге, редакцияләргә җавап язганда файдаланыла. Әйдәгез, шәһәр башкарма комитет председателе урынбасары А. Александров имзасы белән 1970 елдан алып

газета-журнал редакцияләренә җибәрелеп торган җавапларга күз йөртеп чыгыйк.

Башта фактларның дөрес булып чыгуы танылa. Гәрчә томанлырак төстә һәм беркадәр киметелеп булса да: «Кабанга пычрак агынтылар әләгүнең аерым очраклары булгалады...» Игътибар итегез әле: «аерым очраклары». Бу — агынтылар көннәр буена коеп торган чак турында! Арырак, көр күңел белән, «мондый һич тә ярамый торган пычратуларга» чик куелачагы искәртелә, сроклар күрсәтелә, газета чыгышына җавап йөзеннән күреләчәк конкрет чаралар күрсәтелә. Әйтик: «Совет районыннан Идел буе районына бара торган яңа канализация коллекторы төзелә, ул 1971 елда файдалануга тапшырылу белән, Жданов — Свердлов — Луковский — Спартак урамнары төбәгендә эшләп килгән канализациядәге аварияле ситуацияләр һәм Кабанга канализация агынтылары әләгү очраклары бетәчәк. Күпсанлы чистарту корылмалары төзелә, алар агымдагы бишьеллыкта сафка басачак. Шәһәрнең үсү перспективасын күздә тотып, өч яңа магистраль канализация коллекторы салына. Әлеге коллекторларның аеруча мөһим участоклары 1972 елда сафка басачак. Бу исә хәлне тамырдан яхшыртачак».

Шулай итеп, тел-теш тидермәслек итеп төзелгән әлеге документка ышансак, Кабанда хәл инде 1972 елда ук «тамырдан яхшырырга» тиеш иде. Ә ул начарланганнан-начарлана бара. Нигә? Совет районыннан Идел буе районына баручы коллектор санап үтелгән урамнардагы авария ситуациясенә, чынлыкта, берничек тә тәэсир итмәде һәм итә дә алмый иде — әнә шуңа! «Шәһәрнең үсү перспективасын күздә тотып» өч магистраль коллектор һәм шулай ук Кабан тирәсендә «күпсанлы чистарту корылмалары» төзү турында асылда сүз генә йөрде. Икенең берсе монда: я җавапларны «төзүче» үзенең дәрәҗәсе һәм вазифасы буенча белергә тиешле гап-гади фактларны белми, я ... аңлы рәвештә чираттагы «яздым-котылдым» хатын иҗат итә.

1973 елның январеннан «калып» үзгәрә. Констатацияләүче өлеш элеккечә кала, әзерләнгән һәм кабул ителгән чаралар бүлегенә исә яңалык керә: «1974 елда «Горки» коллекторы, шулай ук промышленность предприятиеләренең канализация һәм йомык су әйләнеше системалары төзелү тәгәлләнгәч (Кабандагы хәлне тамырдан үзгәртергә тиеш булган элекке коллекторлар турында ләм-мим!), Кабан күленә пычрак су агызу туктатылачак».

Һай, бу кәгазь дигәннәре тылсымлы көчкә ия булсачы!

Әмма... Тыныч кына 1974 ел да узып китте, пычрак инешләр көчәя генә барды. Моннан нинди нәтиҗә ясалырга тиеш? Дөрес уйлыйсыз, нәкъ шулай: яңа калып әзерләргә кирәк. Бу юлы А. Александров саграк кылана һәм агынтыларны бөтенләй туктату өчен яңа срок билгеләгән: 1980 ел. Яңа вариантта күлне савыктыру чараларының тулы бер системасы санап чыгыла: ярны ныгыту, яр буйларын төзекләндерү, янгыр суы юллары төзү һ. б. Шәһәр башкарма комитеты председателе урынбасарының җавабын 1974 елның 7 январь санында баскан «Известия» газетасы редакциясе бу уңайдан шулкадәр дә зарур эшләрне башкару өчен алты ел вакытның күбрәк булуын искәртә һәм Кабанны савыктыру эшләренең тизләнүенә өмет баглый.

Кайчандыр Хуҗа Насретдин, башы белән ант итеп, ишәген укырга өйрәтергә була. Үзенең исән калачагына шикләнми ул: вәгъдәләшкән егерме ел эчендә я ишәк, я хан, яисә үзе теге дөньяга китеп барачак бит.

Шулай булып чыкты да! 1980 елда, әлеге шома хатларны иҗат итеп утыручының күзенә карыйм әле, ичмасам, дип, шәһәр башкарма комитетына килсәм, Александров иптәш анда эшләми икән инде. Аны бу постта алыштырган Я. Ишбулатов, үткәндәге эшләр өчен җавап бирә алмыйм, бигайбә, дигәндәй, кулларын гына җәйде.

Болганчык сасы су агымы һәм кәгазь агымы шулай янәшә ага бирделәр.

Шул хәлләрдән соң башка менә мондый уй килде. Әгәр, мин әйтәм, кала дивары астына күмелгән эт турындагы риваятькә хәзерге фән казанышлары биеклегеннән баксаң, аны бюрократизм дигән хәтәр нәрсә туу мөмкинлегенә тәгъриф итеп булмый микән? Үтерелгәнме? Үтерелгән! Күмелгәнме? Күмелгән! Ни кирәк сезгә тагын? Чара күрелгән бит. Ничек, ни дәрәҗәдә — анысы вак-төяк инде аның.

Күлнең хәле соңгы чигенәчә начарлануда әнә шундый бюрократик мөнәсәбәтнең дә «өлеше» зур.

1975 елдан Кабан суын үсемлекләргә сибү өчен дә кулланмый башладылар — агачларны үстерми, яшелчәләрне корыта иде ул.

1976 елда Якын Кабанда балык юкка чыкты. Акчарлаклар качты. Җәй урталарында Урта Кабаннан адашып килеп кергән балык була иде әле булуын, ләкин язга анысы да җан тәслим кыла иде.

1978 елда санэпидстанция, бактереологик агулану булмасын дип, урамнарны Кабан суы белән юдыртуны тый-

ды. Күл төбендәге организмнар, суалчаннарга кадәр, үлеп бетте.

Урта Кабанда да ике метрдан «үле зона» башлана иде. Мондый суны Куйбышев сусаклагычына кудыру Иделне пычратуга китерәчәк, диючеләр арта барды. Әмма шәһәр санэпидстанциясе һәм Бассейн инспекциясе бу хәлгә күз йомарга мәҗбүр булдылар, чөнки бүтән юл юк иде.

1980 елда Казан санэпидстанциясе «Күлгә агызылган пычрак сулар соңгы чик концентрацияне узу сәбәпле, Кабан күле торак массивлар атмосферасын пычрата торган күкертле водород исе чыганагына әверелгән» дигән нәтиҗә ясады.

Гади телгә күчергәндә бу, боз ачылгач, Кабан тирәсендәге кварталларда тәрәзә-форточкаларны ябу-томалау гына җитми, кайбер предприятие, оешма, учреждениеләрне дә ябарга кирәк, дигән сүз иде. Моңа тагын хезмәт җитештерүчәнлеге кимү, бюллетеньнәргә түләү, күл буенда төзү эшләрен туктатудан күргән зыянны да өстәсәң, түгәрәк кенә сумма килеп чыга.

Әмма иң аянычы — кешеләр интегә. РСФСРның ишү буенча элекке чемпионы Н. Ф. Минһаҗева сөйли: «Җилле көннәрдә спортчылар Иделгә я Казан суына чыга алмыйлар — дулкын комачаулый, тыюларга карамастан, ишү белән Кабанда шөгыльләнәләр. Исенә дә ияләнер идең, хәл китә, күнегү азагына һуштан язучылар да була».

Шул 1980 елда Якын Кабан рәсми рәвештә үле күл дип табылды. Баксаң, бу чып-чын фәнни термин икән. Пычрану дәрәҗәсе ун баллы шкала белән үлчәнә. Бу төбәккә кеше аяк басканга кадәр әлеге күрсәткеч — нуль, XIX гасыр башында бердән бераз гына артык булса, 1980 елда 7,7 баллга җиткән. Тере организмнар яши алган чикне (биш балл чамасы) үтеп киткәч, күл суы инде канализация агынтысыннан берни белән дә аерылып тормый башлаган.

Кабанның мең ел буена тула килгән сабыр касәсе, ниһаять, тулып ташкан.

Бәхеткә каршы, эш шома җаваплар белән генә чикләнмәде, Кабанның ихлас һәм фидакарь дуслары табылды, алар, шикаятьләр, матбугатта чыгыш ясаулар белән генә чикләнмичә, зур һәм мөһим эш башкардылар — мәсьәләне тамырдан хәл итү өчен җирлек әзерләделәр. Бу кешеләрнең берничәсен генә булса да атап үтик.

В. В. Нечкинаның тикшеренүләрен сиксәненче елларда университетның табигатьне саклау кафедрасы аспиранты (хәзер доцент) Нәфисә Минһаҗева дәвам иттерде. Ул күл

суына меңнәрчә тапкыр анализ ясады, күлләрнең экологик системасын комплекслы өйрәнү үткәрде һәм аның язмышын хәл итү өчен фәнни база булдырды. Бу эшне ул кафедра мөдире Ю. С. Котов җитәкчелегендә алып барды. Җәмгыятьнең коллектив әгъзалары, өлкән класс укучылары, университет, химия-технология һәм төзүче-инженерлар институтлары студентларыннан торган табигатьне саклау буенча яшьләр группалары аеруча мактауга лаек.

Шәһәр санэпидстанциясе хезмәткәрләре М. А. Калашникова белән С. А. Яни, балык саклау инспекторы Р. В. Мәрдәнов, Казанда яшәүчеләрдән С. Ш. Абдюшев, И. Никитина, И. М. Николаев һәм башка күп кенә кешеләр хөрмәт белән искә алынуга лаек.

Төп кыенлык шуннан гыйбарәт иде: Казанны төзекләндерү өчен бүлеп бирелә торган акча белән генә шәһәр Советы башкарма комитеты әллә ни майтара алмый. Алдан исәпләүләрдән күренгәнчә, мәсьәләне тәмам хәл кылу өчен уннарча миллион сум акча һәм болай да муеннан эшкә күмелгән төзелеш оешмаларының тырышлыгы сорала. Инде тагын да кичектерергә ярамый. Димәк, ныклап уйланырга, исәпләргә-санарга кирәк иде.

РЕАНИМАЦИЯ

«Реанимация — терелтү дигән сүз. Ул клиник үлемнән соң, ягъни тын алу һәм кан әйләнеше туктап 4—6 минут узганчы үткәрелә. Соңыннан файда бирми — үзәк нерв системасында кайтмас үзгәрешләр башланган була, биологик үлем килә. Реанимация йөрәккә массаж ясау, артерияләргә кан кудыру һәм башка чаралардан гыйбарәт».

Медицина белешмәлегеннән

Комиссия. Беренче үзгәрешләр.
Күтәп алынган көн. Күл тын ала!
Кабан буендагы театр.

Кешенең зур ясалма сулыклар, чып-чын диңгезләр булдырганы бар. Әмма тарих үле сулыкларга яңадан җан өрдерү очракларын белми әле. Ә менә сиксәненче елларда Кабан белән нәкъ шундый хәл булды.

Бу эш гадәти комиссия төзүдән башланды.

Хәер, комиссиясе гади үк түгел иде. Биологлар, медиклар һәм санитария хезмәткәрләреннән тыш, аңа реаль

власть иялəре — партия-совет органнары вəкиллəре дə кертелде. Комиссиягə җитəкчелек итү Казан шəһəр Советы башкарма комитеты председателе урынбасары Ю. М. Погореловка йөклəтелде. Гыйльми секретарь итеп университетның табигатьне саклау кафедрасы доценты, биология фəннəре кандидаты Ю. С. Котов билгелəнде.

Үз гомеремдə миңа күп кенə комиссиялəрнең əгъзасы булырга яисə аларның эшен күзəтергə туры килгəне бар. Җаваплылык бөтен кешегə дə тигез бүленə торган һəм, димəк, конкрет берəүгə дə төшми торган, бюрократик гакылның иң югары казанышы булган бу оештырылмалар искиткеч бер сəлəткə — эш тəэсире тудыру сəлəтенə ия. Кемдер ашыкмыйча гына эшли (яисə эшлəгəн була), актлар төзелə, документлар теркəлə, беркетмəлəр языла... Шулай еллар буена сузыла.

Əмма бу юлы башкачарак булды. Инде төзелгəн чакта ук комиссиягə хəлнең торышын өйрəнү һəм «тиешле җиргə» хəбəр итү генə түгел, хəлне төзəтү бурычы да куелды. Телəсə ничек тə түгел əле, иң оптималь, иң кулай юл белəн төзəтергə кирəк иде. Чиксезлеккə кадəр сузылырга мөмкин булган «иң кыска срокларда» да түгел, конкрет вакыт эчендə — Г. Камал исемендəге театрның яңа бинасы ачылуга, ягъни 1985 ел башына кадəр. (Соңыннан бу срок 1986 елның азагына күчерелде.)

Менə шуңа да комиссиянең эшчəнлек нəтиҗəлəре ул эшнең торышы белəн танышып анык бер фикергə килгəнче ук күренə башлады. Табигатьне саклау белəн еш кына проходнойдан да үтеп керə алмый торган лаборант кыз шөгыльлəнү — бер нəрсə ул. Заводка партиянең шəһəр комитеты секретаре яки бүтəн зур җитəкче килеп, план үтəлешеннəн дə алда Кабанга агызыла торган суның күлəме һəм чисталык дəрəҗəсе белəн кызыксынуы исə бөтенлəй башкача кабул ителə. Мəсьəлəнең асылын директор җитəкче иптəшнең тавышыннан ук чамалап ала...

1981 елның маенда комиссия хөкүмəткə тиешенчə дəлиллəнгəн, экономик яктан нигезлəнгəн документ тапшырды. Бу документтан күлне бары ясалма юл белəн — кеше кулы белəн генə коткарып булганлыгы күренə. Комиссиянең тəкъдимнəре шуннан гыйбарəт:

1. Күлгə һəртөрле пычрак су агызуларны кичекмəстəн туктатырга.
2. Ясалма агым булдырырга.
3. Күл төбен əйбəтлəп чистартырга.
4. Суны аэрациялəргə (һава өрдерергə).

5. Ярларны төзекләндерергә һәм яшелләндерергә.

6. Яңгыр һәм кар суларын махсус коллекторларга җыеп, канализация челтәренә кудырырга.

7. Күлдән су алу күләмен чикләргә.

8. Күлнең тереклек дөньясын тергезергә.

Асылда бу — коры тәкъдимнәр генә булмыйча, комиссия үзе үк тормышка ашырырга тиешле эш планы иде инде.

Чираттагы гадәттән тыш адым директорлар советы төзүдән гыйбарәт булды. Кабан буенда урнашкан, күпме еллар күлне тончыктыру белән шөгыльләнгән предприятиеләрнең җитәкчеләренә аны коткару бурычы йөкләнде.

Бер директор: төрле-төрле 37 советта әгъза булып торам, аларның һәр утырышында катнаша башласам, миңа 74 сәгатьле тәүлек кирәк булачак, дигән иде. Әмма бу совет АТНА САЕН үткәрелеп, анда бөтен директорларның да катнашуы МӘҖБҮРИ иде! Хәер, акча бирү кебек нәрсәне директордан башка кем дә булса хәл итә аламы соң әле? Мәсьәләнең чын-чынлап шулай куелуына кайберәүләр башта ышанып та җитмәде: сез нәрсә, иптәшләр, шаяртасыз мәллә? Моңа кем юл куяр? План бар, смета бар. Сметадан тыш сукыр бер тиен дә тота алмыйбыз... Финанс ревизияләре, халык контроле белән ни эшләргә кушасыз тагын? Ирекле көннән башны төрмәгә тыгар хәл юк, янәсе.

— Ә уннарча ел буена күлгә теләсә ни агызырга ярый идеме соң? — аларның авызын әнә шулай томаладылар.— Күз яше күк чиста суны бушлай тотарга, табигатьне харап итәргә ярый идеме? Табигатьтән алган бурычны түләргә вакыт.

Утырышларда төрлесе булды. Берәүләр, кызгандырырга теләп, мескенгә сабышты, икенчеләре акча өчен җан талашты. Инстанцияләр буйлап та йөрделәр, эштән китү турында гариза язып та карадылар. Тик, беркайда да теләктәшлек тапмагач, аз-азлап янчыкларын чишә башладылар. Шулай итеп, җыя торгач, 20 миллион сум тупланды. Идеяне тормышка ашырып карау, эш башлау өчен җитәрлек сумма иде инде бу.

Әмма директорларны акча каерыр өчен генә җыймадылар. Иң әүвәл Кабанга аккан суның күләме һәм сыйфаты өчен сорала иде. Чынлап торып тотынгач, һәрбер предприятиедә дә диярлек, пычрану үзенчәлегенә бәйле рәвештә, үз чистарту системаларын эшләү, берәр төрле әмәл табу мөмкин булып чыкты. Бер предприятиедә суны тондыру буасы да җитеп торса, икенчесендә зарарлы агын-

тыларны нейтральләштерү кулай, өченчесендә гади, әмма ышанычлы фильтрлар куеп була икән. Рационализаторлар да күп кенә отышлы чаралар тәкъдим итте.

Шәһәр һәм республика җитәкчеләренең ярдәмен тоя башлагач, санитария хезмәткәрләренә җан керде. Бер кат чистармыйча торып алар агынтыларны хәтта шәһәр канализациясенә дә кабул итми башладылар. Һәрбер соңгы чик концентрацияне үтү очрагы «ЧП»га әйләндерелә, шәһәр башкарма комитеты председателе кабинетында, хәтта КПССның шәһәр комитеты бюросында тикшерелә иде.

Нәтиҗәдә, 1981 елның беренче яртысында күлгә агулы су агызу күләме өч тапкыр кимеде. 1980 елда Якын һәм Урта Кабанга төрле яктан 18 сасы «кушылдык» койса (дөрес, аларның өчесе «рәсми түгел» — минем картада гына билгеләнгән), 1981 ел җәендә аларның нибары алтысы гына торып калды.

Кабанның аргы башындагы насослар тулы көченә җибәрелде. Күкертле водород белән агуланган су урынына чиста агымсу керә башлады. Анализлар кислородка туенган катламның аз-азлап тернәкләнә баруын күрсәтте.Ботан бугазы аша саф су Якын Кабанга да керә башлады. Әмма монда ләм тыгылган сулы горизонтларны терелтү мөмкин булып чыкмады. Күл төбен чистартырга кирәк иде.

1981—1982 еллар кышында ничәмә-ничә еллар эчендә беренче тапкыр Якын Кабан өсте бозланды. Соргылт, куыклы, тотрыксыз боз иде бу, шулай да, парланып торган бәкегә чумудан курыкмыйча атлап йөриләр иде инде.

Язын сасы ис гадәттәгедән азрак килде, тиздән анысы да бетте диярлек. Әлбәттә, күлдә җан әсәре юк иде әле. Шулай да, үлчәү тәлинкәсе тирбәлеп куйгандай булды. Казанлыларның күпчелеге бу үзгәреш хакында берни дә белми иде әле. Якын-тирәдә яшәүчеләр исә шундук чамалап алды. Шикаятьләр дә кимеде.

1982—1983 елларда агынтыларны бетерү, Иделгә су кудыру һәм күл төбен чистартырга әзерлек эшләре дәвам итте. Күмәк тырышлык белән тиз арада 16 миллион сумлык проект та эшләнде. Юкка баш ватып тормыйча, илленче елларда инде сыналган һәм бик тә отышлы булып чыккан ысулны кулланырга — земснаряд белән чистартырга карар кылдылар. Проектчыларны бүтән нәрсә борчый иде: миллионнарча тонна агулы ләмне кая куярга?

Эзли торгач, Утар ягындагы сазланган ташландык җиргә кудырырга булдылар. Шәһәрдән ерак булуы әйбәт иде, әмма 13—15 чакрым артык ерак түгелме? Хәтта Идел-

Дон каналын төзегәндә дә кудыру ераклыгы тугыз чакрымнан артмаган... Проектчылар кыен хәлдән пульпаның (балчык белән су кушылмасы) басымын тиешле дәрәҗәдә тотачак арадаш насос станцияләре ярдәмендә чыгарга булдылар.

Вакыт ашыктыра иде. Театрның яңа бинасы ачылуга өч ел чамасы вакыт калып бара. Җитмәсә, ул театрның сиксән еллыгы белән туры килә. Мәскәүдән, союздаш һәм автономияле республикалардан могтәбәр кунаклар чакырылган. Республиканың йөз аклыгы җитди сынау алдында калган.

Казан заказы буенча Цимлянск судомеханика заводында җитештерүчәнлеге сәгатькә 250 куб метр булган куәтле земснаряд ясыйлар. Аны өлешләп алып кайтып, җыеп, 1983 елның апрелендә «Спартак» берләшмәсе янында суга төшерделәр. Шул ук вакытта пульпаүткәргеч салу буенча шактый катлаулы һәм күп хезмәт сорый торган эшләр дә алып барылды. Моңа җитәкчелек итү һәм төрле оешмаларның тырышлыгын координацияләү өчен шәһәр башкарма комитеты председателе җитәкчелегендәге шәһәр штабы булдырылды.

Шундый ерак арага пульпаүткәргеч салу өчен күпме торба, күпме металл кирәк! Ә алар Госплан разнарядкасы буенча гына бирелә. Нишләргә соң? Планнарга төзәтмә кертеп, Кабан өчен «берничә тамчы» бүлеп биргәннәрен берничә ел көтәргәме? Еллар түгел, минуты да кадерле. Урында «эзләп табарга» кирәк иде. Бу четерекле эш, шәһәрнең инженерлык саклануы идарәсе башлыгы Иван Степанович Аксеновка һәм шул ук идарәнең баш инженеры Илдар Сәлахович Шәехсаттаровка йөкләделәр. Менә шулар инде бөтен Казанны бетереп, әле металл ватыклары өемендә, әле предприятиеләр ишегалдында күгәреп ятканны табып, план органнары ризалыгы белән, яисә ярымрәсми рәвештә алып, төрле диаметрдагы шактый гына торба тупладылар.

Төпкә «Трансгидромеханизация» трестының 480 нче төзелеш идарәсе җигелде. Эшне тизләтә төшү өчен аңа «Татнефтепроводстрой» трестының кайбер идарәләре дә ярдәм итте. Шәһәрнең инженерлык саклануы идарәсе, «Татспецстрой», «Казгражданпроект» трестлары һәм башка оешмаларның бүлекчәләре һәм аерым белгечләре дә бу эшкә тартылды. Төп эш көчен һәм белгечләрне Кабан тирәсендәге предприятиеләр бирергә тиеш иде. Эшнең барып чыгуына ышанмаучыларның юравы буенча, мондый таркаулык әзерлек эшләренең генә дә 10—15 елга сузы-



луына китерәчәк иде. Гыйбрәтле мисалы күз алдында: «Гидроспецстрой» трестының Казан төзелеш идарәсе сигез ел эчендә Болакның нибары биштән бер өлешен генә торгыза алды. Анысын да проекттан тайпылгалап кына әле.

Ләкин шәһәр штабы пульпаүткәргеч төзелешен үз кулына алды. Штабта һәрбер эш көне кыска оператив киңәшмәдән башланып китте. Анда конкрет мәсьәләләр куелды: ни комачаулый, нәрсә кирәк, ничек ярдәм итеп була? Электрчылар җитмиме? Кайчанга һәм ничә кеше кирәк? Шунда ук штаб членнарының берсенә шәһәр предприятиеләреннән тиешле санда белгечләрне табу йөкләнә. Элемтәчеләр җитмиме? Шәһәр элемтә идарәсенә шалтыратып, күпмедер вакытка кеше җибәрү турында килешәләр.

Моныңише мәсьәләләр сәгать саен диярлек чыгып тора. Я транспорт юк, я материал китереп җиткермәгәннәр, я ягулык беткән, я берәр төрле механизм сафтан чыккан. Әмма алар сәгате-минуты белән хәл ителеп торды. Ул гына да түгел, мондый өзеклекләр кабат булмасын өчен тиешле чаралар да күрелә иде.

Ярты ел дигәндә, унөч километрлы пульпаүткәргеч әзер иде инде. Арадаш дүрт насос станциясендә дә эш тәгәлләнде.

Туфрак өемнәре белән читләнгән илле гектарлы мәйдан — ләм «склады»н әзерләргә кирәк иде әле. Агулы ләм җир асты суына үтеп кермәсен өчен комнан махсус «түшәк» юдырдылар.

Кабан тирәсендәге бер генә предприятие дә «өлешсез» калмады. Эш өч смена буена — көне-төне барды. Төннәрен, җирне-күкне прожекторлар балкытканда, өзми-куймый бульдозерлар үкергәндә «эш күренеше» бигрәк тә тәэсирле була иде. Судан күтәрелүче томан катыш машина төтененнән тоташ зәңгәр чаршау барлыкка килә, гигант баганалар сыман, фара утлары чайкала... Берәүне дә тырышып эшләргә үгетлисе юк. Күлне коткарырга кирәк — һәркемне шул уй ашыктырды-җилкендерде.

Менә бер генә мисал. Штаб утырышында тракторчылар җитмәве ачыкланды. Штаб вәкилләре Идел буе районы предприятиеләренә мөрәҗәгать иттеләр. Үтенеч кире кагылды. Хикмәт шунда: күпләр бу вакытта авыл басуларында эшлиләр, тагын күпмеседер җәйге ялдан кайтып җитмәгән. Штаб әгъзалары цехларны йөреп чыктылар, эшчеләргә мөрәҗәгать иттеләр. «Кабан ярдәмгә мохтаҗ» дигән сүз күпләрнең күңел түренә барып ирешә. Ярдәмгә



килергә әзер булганнарны теркәп, график төзеделәр. Төп эштән соң һәм ял көннәрендә эшләргә кирәк иде.

Һәм менә ул көн килеп җитте.

1983 елның 4 ноябрендә земснаряд машинисты Виктор Иванович Соловьев пульт артына кереп утырды. Егерме метрлы рама, калтырангалап, әкрен генә суга күмелде. Тагын бер кнопкага баскач, рам очындагы кашыклы фреза хәрәкәткә килде. Торбаның дерелдәвеннән, ком бөртекләре ышкылган тавыштан аңладым: пульпа агыла башлады. Тик тиешле җиргә барып җитәрме ул?

Ялыктыргыч минутлар үтә. Ниһаять, телефон шалтырады. Трубканы бригадир В. Савельев ала.

— Пульпа унөченче километрга килеп җитте! — кемдер шат тавыш белән әнә шулай дип хәбәр итә.— Тизлекне арттыра аласыз.

Земснаряд, бөтен тәне белән калтыранып, дәртлерәк гүли башлады. Виктор Иванович лебедкаларны эшкә җигә. Әкренләп земснаряд театр төзелешенә таба шуыша.

Ул көздә земснаряд бер ай чамасы гына эшләп калды. Язын якын-тирәдә яшәгән кешеләр, өмет катыш курку белән, иснәнделәр — сасы ис килми иде. Моны болай аңлаттылар: земснаряд, ләм суыртудан тыш, суны шактый болгатып кислородка туендырган.

Күл боздан арыну белән, земснаряд кабат эшли башлады һәм җәй буе туктамады. Кабан әйтерсең лә күкрәк тутырып сулыш алып җибәрде. Эссе көннәрдә аннан инде сасыган күкәй исе түгел, рәхәт сафлык килеп тора иде. Күлнең үтә күренмәле яшькелт суында күтәрү краннары, театр бинасының ак мәрмәр диварлары көзгедәгедәй чагыла иде... Бераздан яр буйларында камыш үсеп китте, җете яшел күрән үсте. Очлы яфрак, җикән кебек күп еллар күренмәгән үләннәр дә баш калкытты. Бакалар аваз салды. Табигатьне саклау кафедрасы студентлары яр буендагы ләмдә озынборын личинкалары, су сөзгеч моллюск кабырчыклары да таптылар. Болар бөтенесе күлнең терелә баруы һәм аның үз-үзен чистарту сәләте кайта башлауның дәлилләре иде.

1984 елның 14 июлендә Кабан буенда беренче балыкчыга юлыктым. Театр янындагы бетон парапеттан аякларын асылындырып утырган бу малай бик тә җитди кыяфәт белән калкавычка текәлгән иде. «Чиртмидер бит?» дигән соравыма җавап төсендә горур рәвештә янындагы сулы банкага ишарә итте ул. Банкада ике елгыр җилембалык йөзә иде! Зурлыкка зур түгелләр, әмма, һәрхәлдә, оптикасыз да күрерлек. Бу малайны кочаклап үбә яздым.

Без күп еллар буе омтылган, әмма үзебез дә ахыргача ышанып бетә алмаган эш мөмкин булып чыкты. Хәер, бер уйласаң, шаккатарлык әйбер дә юк монда. Күл меңнәрчә еллар буена кешедән башка яши алган. Аңа үзен тынычлыкта калдырулары гына кирәк. Кешенең Кабанны бугазлаган кулы бераз гына йомшауга пычрану дәрәҗәсе 3,5—4 баллга төште, ягъни ике тапкыр кимеде һәм кимүен дәвам итте. Земснаряд та тәүлек саен биш мең тонна чамасы сасы ләм боткасы суыртып ала торды. Күз алдына китерегез әле: биш тонналы мең самосвал! Көн саен!

Бер тапкыр шулай земснаряд машинисты Виктор Иванович Соловьев белән сөйләшеп киттек. Якын Кабан төбендәге ләмнең күләме галимнәр исәпләгәннән күп өлеш артык булырга тиеш, диде ул. (Ахыр чиктә шулай булып чыкты да. Тормыш чынбарлыгы әлеге санны икегә тапкырларга мәҗбүр итте.) Сүз иярә сүз чыгып, ханнар хәзинәсе турында да сөйләшеп киттек. Виктор Иванович минем хикәяткә бик җитди карады, галимнәрнең күлне өйрәнү өчен шундый форсаттан файдалана алмый калуларына уфтанып та куйды. Бер тапкыр земснаряд «тончыгып алган» икән: Гражданнар сугышы заманыннан калган маузер тыгылган. Монысы очраклы хәл, әлбәттә, мондый зурлыктагы әйберләрне земснаряд гадәттә сизми дә йотып җибәрә.

Виктор Иванович әйтүенчә, тоткыч җайланмалы махсус рәшәткә куйсаң (шунда ук кәгазьдә сызып күрсәтте — гап-гади нәрсә) шактый «ганимәт» җыярга мөмкин буласы икән. Хәзинә кадәресен үк әйтеп булмый, ә менә төрле савыт-саба, чүлмәк ватыклары, балык тоту әсбаплары кебек нәрсәләр өзелеп тормаячак. Күлнең төбе ташлы түгел, димәк, каты әйберләрнең һәркайсы диярлек археологлар өчен кызыклы булырга мөмкин... Күп тә кирәкми, юкса, теге җайланманы ясату өчен беркадәр акча да аның эшенә күз-колак булырга бер кеше...

Кабанда чакта земснаряд хәзинәне дә эзләп карый алыр иде. Әмма моның өчен махсус приборлар ярдәмендә металл массасы яткан урынны аныклый төшәргә кирәк. Юкса, кашыклы фреза белән пыран-заран китерүең бар.

Без гәп куертып торганда пульпаүткәргеч торбасында нәрсәдер чыңлап, шыкылдап куйды. Бәлкем, хәзинәдер?..

Кабанга бәйле бүтән эшләр дә башкарылды.

Компрессорлар төзү конструкторлык бюросы, комиссия заказы буенча, аэрация проектын эшләде. Яр буйларында биш насос-компрессор станциясе төзеп, торбалар аша суның төптәге катламнарына һава өрдерүне күздә тота иде

бу проект. Мондый корылмалар Балтик буе сулыкларында кулланылган иде, нәтиҗәсе дә бик шәп булган. Хәер, өендә компрессорлы аквариум тоткан кеше моны үзе дә белә... Кабан «аквариумы»на электр энергиясе күбрәк кирәк булачак, әлбәттә.

Аэрация варианты әлегә запаста тора. Төпне чистарту ярдәм итмәгән очракта куллану өчен. Ис беткәч, теге станцияләрне төзергә ашыкмыйлар. Акчаны һәм көчне бүлгәләмәү, бер башланган эшне ахырынача җиткерү җәһәтеннән караганда, дөрестер дә. Әмма белгечләр аэрация барыбер кирәк булачак, диләр: күл элекке яшел итәген җуеп, шәрә ярларында торып калды бит.

1984 елдан башлап, күлнең хәле яхшыруга бәйле рәвештә, театр төзелеше нык тизләнде. 1986 елның ноябрендә аны ачу тантанасы булды. Театр бинасы күлнең йөзек кашына әйләнде. Шәһәрнең күренекле урыны булып белешмәлекләргә дә кереп өлгерде инде. Киләчәктә, бәлкем, тарихка да даны сүнмәс-сүрелмәс Кабан буе театры булып кереп калыр ул... Проектчыларның иҗади фикерләве шунда да чагыла: алар театрны Кабан ярына утыртып кына калмаганнар, гүя күлнең үзен театр эченә керткәннәр. Фойедан күренеп тора ул. Анда хәтта кышкы бакча да бар... Әйтерсең лә Кабан төбендәге әкияти сарайларның берсе тылсым көче белән яңадан өскә калкып чыккан.

ЭКОЛОГИК КУЛЬТУРА ТУРЫНДА

Урманым кырылды,
Камышлар корыды,
Күл түгел — сазламык...
Тапталдым, тапландым.
Бака үлән катыш
Ләм белән капландым.

М. Шабаев

Умырзаялар кая китте?
«Яшәсен хуш исле сабын!»
Кул белән балык тоту.
Серле чишмә.

Һәр язны бер күренеш күңелне әрнетә. Урманда ял иткән халык, башлыча яшьләр, кочак-кочак кызгылт-зәңгәр күкебаш һәм сыек шәмәхә сәрдәнә чәчәкләре күтәреп кайта. Алып кайтып җиткерә алмыйлар, әлбәттә (бу чәчәкләр бик тиз шиңә), чүплекләргә яисә урамга ук то-

мырып калдыралар. Юкса матурлык сирпеп урманда күпме үсеп утырырлар иде алар. Иң мөһиме, орлыкланырлар иде.

Укучы инде төшенгәндер: сүз «кайбер юньсез кешеләр» турында түгел, ә бәлки халыкның экологик культурасы турында бара. Шәһәрләр зурайгач һәм һәркайсыбыз ял саен диярлек «табигатькә чыгуны» гадәт иткәч, үз-үзеңне тотуның элекке стереотиплары инде ярамый. Меңнәрчә ел буена кеше урманга табыш эзләп, ни дә булса «кыстырып» кайтырга дип барган. Хәзер дә шуны куабыз, «табигать кочагында» үзебезне шул кыргый кеше сыман тотабыз. Бер-ике кыргый ярый әле ул, әгәр дә алар миллион булса?

Хәер, бер кеше дә зур бәлаләр китерә ала. Әгәр... Әгәр дә аның кулында заман техникасы, органик һәм органик булмаган химия казанышлары булса.

Абыйлы-энеле Крестовниковларның данлы сабын заводының варисы — М. Вахитов исемендәге химия комбинатын берничә тапкыр телгә алган идек инде. Ярты илне диярлек төрле-төрле сабыннар һәм кер юу өчен синтетик порошоклар белән тәэмин итеп тора ул. Моңа сөенәсе генә иде дә бит...

1984 ел. Сентябрьнең бер көнендә отпусктан кайтып төшкәч, гадәтемчә, Якын Кабан буйларын урап кайтырга булдым һәм... күлне танымадым. Су нииндидер соргылт, болганчык иде. Бәлки, күз Кара диңгезнең зәңгәрсу дулкыннарына ияләшкәнгә генә шулай күренәдер? Юк, күлдән черек исе, сасыган күкәй исе аңкып тора иде. Үле сулыкны савыктыру буенча уникаль эксперимент үткәрү турында газеталарда җиңүле хәбәрләр басылганга бер ай да үтмәде бит әле югыйсә...

Яр буйлап бераз гына баргач, үлгән бакага тап булдым. Әнә, ялтырап бер балык та «йөзеп йөри»... Саерак урынга җиткәч, шундый күренеш ачылды: ярда ап-ак тасма — кер порошогы эзе күренеп тора иде...

Иң яман шик-шөбһәләрем расланды: химкомбинат тагын бер куәтле «залп» биргән. Күлдә тагын тормыш әсәре калмаган иде. Дәррәү күтәрелеп, яшәреп киткән камышлар тагын кибә, саргая башлаганнар. Күрән корыган. Үле балыклар өстендә күпмедер вакыт әйләнеп очып йөргәч, акчарлаклар да каядыр китеп барганнар... Якын Кабан тагын үле сулыкка әйләнгән...

Тикшерүләр башланды.

Комбинат директоры Рәхмәтуллин аяк терәп гаебен инкарь итә, барын да Водоканалга, алкогольсез эчемлекләр

заводына чәпәп калдырмакчы. Хәтта земснарядка да өлеш чыгарды: янәсе, төптән агулы юшкын күтәрә. Ярдәм итмәде: комбинат дирекциясенә зур штраф салдылар. Күзгә пычрак агынтылар тукталды, күл яңадан терелә башлады.

Күлне пычрату «эшенә» турыдан-туры шәһәр башкарма комитетына буйсынган коммуналь хуҗалыгы да өлеш кертте.

Бер кызык хәл истә калган. Киңәшмәләрнең берсендә сууткәргечләр-канализация хезмәте башлыгы Арутюновка, «кискен рәвештә киметербез», «юл куймабыз», «чара күрербез» кебек чираттагы ышандыруларына җавап йөзеннән, мондый сорау бирделәр:

— Әйтегез әле, Кабан булмаса нишләр идегез соң сез?

Башлык аптырашка калды:

— Ничек инде, Кабан булмаса?

— Күл урынында, әйтик, стадион яисә торак кварталы ди. Шулай ук нәҗескә батыра бирер идегезме?

— Ә-ә-ә...— дип сузды җитәкче иптәш, төшенгәнен сиздереп.— Вакытлы трасса сузарга, өстәмә насослар куярга туры килер иде. Чистарту корылмасына кудырган булыр идек.

Кемдер шунда әйтә куйды:

— Ә сез шулай итегез дә! Күл барын онытыгыз! Юк дип исәпләгез аны!

Башлык җавап биреп торуны кирәк санамады, нотыгын өзелгән җиреннән ялгап алып китте.

Ә бит, баксаң, эчке сулыклары булган башка шәһәрләрдә нәкъ шулай эшлиләр дә. Нигә Кабанны безгә дә, әйтик, су стадионы дип санап, аңа су стадионына тиешле кадер-хөрмәтне күрсәтмәскә ди әле? Хәер, хәзер башкача мөмкин дә түгел, чөнки бөтен Казанның сәламәтлеге Кабанның саулыгына бәйле.

Күрелгән чаралар күлгә аз-азлап хәл җыярга мөмкинлек бирде. Төпне чистарту, су кудыру дәвам итте. Иң зыянлы агынтылар санын тагын киметергә мөмкин булды. 1980 елның августы белән чагыштырганда 1986 ел августына Якын Кабанда эремәгән кисәкчәләр микъдары 3,75 мәртәбә, нефть продуктлары — 33,6, химия комбинаты агыза торган синтетик актив матдәләр 480 мәртәбә кимрәк иде! Якын Кабанга янә балык кайтты.

Шулай да, бу мең кыенлык белән урнашкан тигезлек шундый да тотрыксыз ки, үлчәү угының һәр минутта кирегә якка авышуы бар.

1987 елның апрель азаклары... Өйгә кайтып барам...

Болак аша салынган күперләрнең берсе янында сәер хәл күреп алдым. Бала-чага чыр-чу килеп күпер астында чабышып йөри һәм... кул белән балык тота иде. Бу урында Болакның чистартылган өлеше бетеп, туфрак өелгән урын башлана. Өемнәрдән кар суы агып төшә. Чабаклар, җилембалыклар әнә шул сихәтле ермакларга ташланалар иде. Арада бер карыш чамасы булган шактый зурлары да бар... Бу хәлнең гаҗәплеге тагын шунда: соңгы йөз елда бер генә тапкыр да Болакта балык әсәре күргән кеше булмаган.

Моның сере көймәдә Урта Кабанга йөзеп чыгу белән ачылды. Һәр ике яр үле балыктан ап-ак иде. Күлдә аллыгөлле таплар һәм мазут кисәкләре йөзеп йөри. Тиздән көймәнең бортлары, ишкәкләр кап-кара булды.

Мазут «Танковая» дигән троллейбус тукталышы тирәсендәге яңгыр суы канализациясеннән агып чыга иде. Ә менә канализациягә кайдан эләгә? Башта Урта Кабан буендагы кар чүплегеннән шикләндек: анда мазут, бензинга пычранган кар түгелә бит. Әмма күлгә мазут агу кар эреп беткәч тә кимемәде. Аннары якын-тирәдәге автотранспорт предприятиеләренең ишегалларын тикшереп чыктык. Алардан, чыннан да, күлгә майлы су аккалый, тик... бу кадәр үк түгел бит инде!

Су инспекциясе хезмәткәрләре бу төбәккә биш мәртәбә килделәр, шулай да, пычрату чыганагын таба алмадылар. Бу табышмакка җавапны студентлар эзли башлый. Мазут эре панельле йортлар заводы ишегалдыннан ага, дигән фикергә килә алар. Ләкин моның бернинди дә билгесе күренми. Көрәк-ломнарны эшкә җигәргә туры килә. Шулай маташа торгач җир астында галәмәт зур резервуар табалар, ул мазут белән тулы була. (Бу резервуарның барлыгын завод директоры үзе дә белмәгән, имеш.)

Таш мичкә берничә урында ярылган. Ярыклардан мазут саркып торган. Аннан, кар сулары белән кушылып, күлгә аккан.

Эшне суд карый. Завод зыянны капларга мәҗбүр була. 500 мең сумлык штрафның бер өлешен директор һәм кайбер башка җитәкчеләр үзләре түли.

Университетның табигатьне саклау кафедрасы каршында табигатьне саклаучылар түгәрәге эшләп килә. Бервакыт аның әгъзалары Урта Кабан ярында чишмә табалар. Ул ТЭЦ тирәсендәге ташлар өеме астыннан бәреп тора һәм көмеш тасма булып күлгә агып төшә. Түгәрәк җитәкчесе, кафедра хезмәткәре Нәфисә Минһаҗева аптырашта кала. Гүләп янган мичләр, югары егәрлекле трансформа-

торлар һәм электр линияләре патшалыгына чишмә каян килсен ди? Җитмәсә, иссез-тәссез, ифрат чиста сулысы. Кайда да булса сууткәргеч торбасы ярылгандыр дигән фараз расланмый. Тәҗрибәле белгеч моның юньле эш булмавын чамалап ала, балаларга суны татырга рөхсәт итми. «Тәрбия максатында» бер тәҗрибә ясап карарга була. Чишмә суын аквариумга тутырып, анда гуппи балыклары җибәрәләр. Бер-ике көннән балыкларның бөтенесе дә корсакларын өскә куеп калкып чыга.

Бу казаннар юу өчен тотылган селтә эремәсе була. Торба тишелеп ага, җылылык энергоүзәгендә исә моны күрүче-белүче булмый.

Шушы вакыйгадан соң балалар кафедра хезмәткәрләре белән яр буен җентеклəбрәк тикшереп чыгалар һәм унбишләп яшерен агынты табалар. Кайбер предприятие җитәкчеләре, санэпидстанция белән даулашып бимазаланмас өчен, торбаны су астыннан салдыртып, еллар буе күлгә төрле агынты сулар җибәреп яткан икән. Мондый «чишмәләр»не табуы җиңел түгел. Бары җилсез аяз көннәрдә генә көймәдән төптән күтәрелгән һава куыкларын, күбекләрне күреп алырга була.

Нәрсә бу, гамьсезлекме, әллә җинаятьме?

Бер тапкыр миңа шулай бер кызу бәхәскә шаһит булырга туры килде.

— Безнең агынтылар — иң зарарсыз! — дип лаф орды I нче җылылык энергоүзәге җитәкчеләре.— Бөтенесенә дә шулар гаепле...— аннары күрше тирәдәге предприятиеләр санап чыгылды. Шунан соң Н. М. Минһаҗева агынтылар күлгә койган җирдән пыяла савытка су чумырып алды һәм аңа маймычларны җибәрде. Мескеннәр кайнап торган суга эләккән кук атылып-бәрелеп йөзә башладылар. Савыттан сикереп чыгарга да маташтылар. Аннары бер-бер артлы җан тәслим кылдылар. Йөзе таш булып каткан Нәфисә Минһаҗева «нәтиҗә»не билгеләп торды. Балыклар ике секундтан ике минутка кадәр вакыт эчендә кырылып бетте. Комментарийлар артык иде.

Галимә Урта Кабанда фәнгә мәгълүм булмаган яңа төр кысла табылуы турында сөйләде: шөкатьсез рәвештә күбенгән башы — зәңгәр, эчке органнары исә куе кызыл төскә кергән. Ниткән куркыныч нәмәрсә бу? Баксаң, гапгади кысланың химик матдәләр йогынтысыннан үзгәргән, юкка чыга торган формасы икән...

Кабан соңгы елларда яшәү белән үлем арасында гомер кичерә. Исән калырмы ул? Ун-унбиш елдан ни хәлдә булыр?

Бу бары кешегә, аның зирәклегенә, экологик культурасына бәйле. Сезнең белән безнең культурага бәйле...

Белгечләрнең бәяләвенә караганда, 1989 елның җәенә Кабан системасына кергән күлләрнең экологик хәлләре төрлечә килеп җиттеләр.

Якын Кабанның хәле аеруча авыр. Соңгы унъеллыкларда монда регрессив, ягъни бозыла, үлеп баручы экологик система урнашты. Аңа хайваннар һәм үсемлекләр дөньясының гомуми ярлылануы, шулай ук состав ягыннан да үзгәрүе хас. Гасыр башында Якын Кабанда 54 төрле кош көн итсә (шул исәптән, кыр үрдәкләре һәм хәтта кыр казлары да), соңгы вакытта соры козгын, чыпчык һәм күгәрченнәр генә торып калган иде. Экологик шартлар яхшыра төшкәч, акчарлаклар әйләнеп кайтты, ара-тирә саесканнар, кара каргалар, сыерчыклар очып керә. 1984 елда Кабанга берничә кыр үрдәге төште. Әмма, күңелләренә хуш килерлек камышлыклар, тынлык һәм тынычлык тапмыйча, очып киттеләр.

Планктонның һәм су үсемлекләренең төре үзгәрә (зәңгәрсу-яшькелт чүп суүсемнәр өстенлек ала). Яр буйларында күкрәп үсеп яткан кыяклы үләннәрне һәм төрле кузаклы үләннәрне чүп үләннәре — кычыткан, кылган, канлы үлән, наратбаш, бака яфрагы кысрыклап чыгара. Чикләвек куаклары, шомырт, зирек, гөлҗимеш урынына нибары тал гына кала бара, анысы да йончу, зәгыйфь.

Элеккечә берөзлексез хозфекаль агынтылар һәм әледәнәле химкомбинатның промышленность сулары агып торган Ботаник бугаз да хәзер шундыйрак хәлдә.

Урта Кабан шундый ук регрессив экологик системага күчү алдында тора. Соңгы 10—15 ел эчендә генә дә тереклек ияләре һәм үсемлекләрнең төрләре өч мәртәбә кимегән. Әйтик, безнең күз алдында диярлек эт балыгы, сыла (судак), жумба һәм хәтта әрсез шыртлака да юкка чыкты. Бүгенге көндә чабак белән җилембалык күренгәли. Әмма аларның да хәле әйбәт дип әйтеп булмый: кислород җитмәүдән меңәрләп кырылалар... Экологлар күлгә тиз үрчи торган һәм (зарарлы агынтылар беткән хәлдә, әлбәттә) промысел ачарга мөмкин булырлык карп балыгы җибәрергә кирәк, диләр. Җылылык энергоүзәгенең элекке юшкын чүплеге күлне һаман пычратып тора. ТЭЦка бу урынны культуралаштырырга (иң гади юлы күл төбеннән земснаряд белән ләм юдыртудыр), анда агач утыртырга, спорт мәйданчыклары ясарга кушылган. Кулдан килерлек

эш ләбаса бу, теләк, тырышлык кына булсын... Ләкин иң мөһиме йомык су әйләнеше кертү һәм, чистарту корылмалары төзеп, күлгә промышленность сулары агызуны тулысынча туктату, әлбәттә.

Югары Кабанның хәле яхшырак. Сәбәбе гади: промышленность агынтылары юк. Шуңа Кабан күлләре тезмәсендә, күкертле водород тупланган үле зоналарсыз бердән-бер сулык булып калганы да ул. Югары Кабанда «цивилизация сыйларын» татып өлгермәгән кара балык, чуртан, алабугалар йөзә әле. Тик аның да пычрану дәрәҗәсе соңгы чиккә җитеп килә инде.

Пычрату чыганакларымы? Авыл хуҗалыгы институты фермасыннан аккан сулар (язын аерата мул була), якын тирәдәге юл һәм урманнардан агып төшкән яңгыр-кар сулары, машина юу, кер уу, су коенулар. Тирә-яктагы күмәк бакчаларга сиптерү өчен су күп суыртыла, эссерәк җәйләрдә күл 1,65 метрга саега. Җәйләрен ял итүчеләр өзелеп тормый, ярлар таптала, пычратыла.

Су үсемлекләре аз булу сәбәпле (бөтен өслекнең 0,1 процентын гына алып тора, су үз-үзен чистартсын өчен 15—20 процент булырга тиеш), бәләкәй генә пычрактан арыну да кыенга килә күлгә. Ярлары тигез булып сузылу сәбәпле, яр буйларында да яшеллек җитәрлек түгел. Бары төньяк ярда өлешчә сазланган тар гына бер култык бар.

Күлнең экологик хәле соңгы елларда яңа аэропорт ягына тимер юлның дөрес салынмавыннан да начарланды. Ул Дәүләкәй чокырыннан аккан инешнең элекке юлын кисеп калдырды, шуңа да күлгә ләм утыра башлады. Кабанның аргы башындагы күпер дә экология җәһәтеннән караганда дөрес салынмады. Аның астындагы туфрак күтәртелде, шуның аркасында су күлдә тонганнан соң гына сусаклагычка ага.

НИШЛӘРГӘ КИРӘК СОҢ?

«Иҗат итү, яңаны төзү дәрте кешенең асылына ук салынган. Табигать ресурслары — моның өчен материал, табигать үзе — остаханә. Табигатьтәге бер нәрсәгә дә кагылмау принцибына буйсынса, кеше кеше булудан туктар иде. Әмма, үзенең үзгәртеп кору эшчәнлеге китерергә мөмкин күп төрле кәсафәтләр турында, экологик проблемалар турында уйланмаса, ул үзенең «гагыл иясе» дигән мәгърүр исемен җуячак. Бу кәсафәтләр исә котылгысыз түгел».

«Табигать алдында җаваплылык». «Правда» газетасының 1987 ел, 10 январь саны баш мәкаләсе.

Кеше табигатьнең иң гүзәл затымы?
Хәл кыласы проблемалар.
Күлнең математик моделе.
Хәзинә турында бер кәлимә сүз.

Кеше белән бергә планетабызда уй-фикер дә барлыкка килгән. Нәкъ менә фикер йөртү сәләте кешене табигатьнең падишаһы, җирдә булган һәрнәрсәнең иң камил үрнәге итә.

Ләкин кеше белән бергә җирдә чүп дигән нәрсә дә пәйда була. Табигатьнең бөтен буыннары да миллионнарча еллар дәвамында бер-берсенә гаять дәрәҗәдә җайлашкан-көйләнгән. Табигать әйләнешенә сыя алмаган беренче җан иясе — кеше.

Табигатьнең сыгылмалылыгы, үз-үзен көйләү сәләте никадәр соклангыч булмасын, техник цивилизациянең хәзерге этабында табигать үз көче белән генә пычрактан арына, биосфераны тотрыклы хәлдә тота алмый инде. Күптән түгел заруրият, мәсәлән, Байкал һәм Ладога күлләре янындагы целлюлоза-кәгазь комбинатларын ябу мәсьәләсен алга куйды. Бу гыйбрәтле ачы тәҗрибә табигать белән алыш-бирештә бүгенге көн файдасын гына күздә тоткан исәп-хисапка таянып эш итәргә ярамаганлыгын бик тә ачык күрсәтә. Ахыр чиктә бу табигатьнең дә, кешенең дә җиңелүенә китерәчәк. Аларны бер-берсенә каршы куеп булмый, чөнки кеше — табигатьнең үсеш нәтиҗәсе генә түгел, аның аерылгысыз бер өлеше дә.

Үлә, чери баручы Кабан — күпмедер вакыттан шартлаячак бомба сыман. Кабан күле Казан халкы өчен генә түгел, бөтен Идел артериясе өчен дә куркыныч тудыра. «Без үлгәч, ашасыннар балчык күмәч» дигән принцип

буенча эш итүче бүгенге көн коллары, эгоистлар булып калырга теләмәсәк, моны истән чыгарырга ярамый... Хәер, эш истә тоту, аңлауга гына да терәлмәгән. Берәр предприятиегә килеп, сүз каткач, слесарьдан алып директорга кадәр һәркемнең табигатьне пычратуның зарарын бик шәп аңлавына, кайчакта моннан үзе дә зыян күргәнлегенә ышанасың. Шуңа да карамастан, пычрата торалар... Бурыч, күрәсең, экологик аңлылыкны әхлак нормасына, үз-үзеңне тоту кагыйдәсенә әйләндерүдән гыйбарәттер.

Шулай да, Кабанны коткарып калу өчен бүген ниләр эшләргә кирәк соң?

Кабанны савыктыру буенча комиссия тәкъдимнәрендә бу бурычлар бик тә төгәл тәгъбир ителгән. Аларның иң мөһимнәрен кабат искә төшерик.

Беренче чираттагы бурыч — бөтен төр агынтыларны да бетерү. ТАССР Министрлар Советы карарында моның иң соңгы катгый срогы итеп 1990 ел билгеләнгән. Кайчандыр бу бик ерак ара булып күренә иде, инде менә килеп тә җитте. 1927 елдан башлап бер-бер артлы билгеләнә һәм өзелә килгән бөтен сроклар кебек, монысы да өзелерме?

Мохитны саклау турындагы Законны үтәү һәр совет гражданының конституцион бурычы югыйсә. Законны бозучы, кеше үтерәме ул, күлнеме, казна милкенә кул сузамы яисә халык байлыгы булган чиста су ресурсларын юк итәме — җинаятьче. Без исә еллар буе аларны оялтырга яки үгетләргә маташабыз, күп дигәндә, табигатькә китерелгән зыянга һич кенә дә бәрабәр булмаган символик штрафлар белән чикләнәбез.

Күрәсең, суны чистарту технологиясен камилләштерүгә түгел, бәлки калдыксыз эшләүгә, йомык су әйләнешенә күчүгә йөз тотарга кирәктер. Предприятие эшчәнлеген бәяләгәндә төп шартларның берсе, һичшиксез, җитештергән продукция берәмлегенә тотылган су микъдарын киметү булырга тиеш.

Хәзер, үзфинанслау һәм тулы хуҗалык исәбенә күчкәндә, чиста су өчен, шулай ук күлгә пычрак су агызган өчен түләү кертү зарур. Суга мөнәсәбәтне тиз үзгәртер иде бу.

Кабан төбен чистарту дәвам итә. 1987 елның азагына ярты миллион тоннадан артык ләм чыгарылды. 1988 елның языннан башлап земснаряд Урта Кабанда эшли. Якын Кабанда исә иң кыен урыннар — Вахитов күпере, Ботан бугазы һәм тимер юл күпере тирәләре чистартылмыйча калды. Земснаряд ул якка үтә алмый. Төрле урыннарга

үтеп керә ала торган бәләкәйрәк, хәрәкәтчелрәк земснаряд әмәлләргә кирәк күрәсең.

Кабанны савыктыру комиссиясе, яңгыр сулары өчен коллекторлар, тондыргычлар төзүне, төптәге катламнарга һава өрдерүне дә кертеп, эшне комплекслы алып барырга тәкъдим итә. Әмма бу объектларны төзү проектлаштыру стадиясен үтә алганы юк әле. Һаман бәхәсләшәләр: аерым резервуар тондыргычлар төзергәме (сүз уңаеннан, алар шактый кыйммәткә төшәләр, туктаусыз карап-көйләп тору сорала, өстәвенә, нәтиҗәлелеге дә чамалы гына), яисә бөтен күл системасына берне — шәһәр чистарту корылмалары кебекнеме? Пай кертү тәртибендә, Кабан буендагы предприятиеләр исәбенә төзегәндә бу эш реаль күренә.

Суга һава өрдерү дә гаять нәтиҗәле булачак. Казан компрессор заводында компрессорларның бер өлеше эшләнде инде. Кайбер галимнәр бу ысул үзе генә дә проблеманы хәл кылырга мөмкинлек бирәчәк дип исәпли: чистарту процесслары уннарча тапкыр тизләнәчәк. Күл асылда күпмедер микъдарда промышленность һәм хуҗалык агынтыларын да эшкәртергә сәләтле мөстәкыйль чистарту корылмасына әйләнәчәк. Системаның бер генә кимчелеге бар: эксплуатацияләү кыйммәткә төшә, болай да исәпле электр энергиясе гаять күп тотыла. Димәк, төрле-төрле вариантларны сынап карарга, алардан иң отышлысын сайлап алырга кирәк.

Кабанны коткаруга бүлеп бирелгән акчаның төп өлешен хәзер ярны төзекләндерү чыгымнары йотып бара. Зур-зур төзелеш оешмалары, куәтле техника җәлеп ителгән. Вертикаль ярлар корырга һәм яр буйларын төзекләндерергә шактый күләмдә дефицит тимер-бетон китә. Театр урнашкан көнбатыш ярдан алып, Кабан буйлары күз алдында танымаслык булып үзгәрә бара. Монысы шәп. Әмма биологлар, бу иң отышсыз вариант, диләр. Чөнки, суны сафландыручы яр буе үсемлекләре экологик циклдан төшеп кала.

Шәһәрне үстерүнең перспектив планында күлнең төньяк-көнчыгыш яры буйлап метро линиясе уздыру күздә тотыла. Буш җирләр, чүплекләр, җимерелә язган беркатлы йортлардан торган кварталлар монда линияне иң арзанлы ачык ысул белән салырга мөмкинлек бирә. Бу төзелеш шәһәрнең әлеге аеруча күрексез, ташландык өлешен төзекләндерер, матурлар дип ышаныйк.

Е. Голубцов җитәкчелегендәге Казан дизайнерлары Кабан күле читендә хасил булачак Театр мәйданының

кызыклы планын эшләде. Казанның бу борынгы почмагындагы Камал театры, филармониянең концерт залы кебек яңа биналар, реставрацияләнгән «Болгар» кунакханәсе, Г. Тукайга бәйле башка биналар белән матур бер ансамбль барлыкка киләчәк. Күлнең көньяк ярындагы иң үзенчәлекле иске биналарны да элекке хәленә кайтару күздә тотыла. Мәрҗани мәчете белән бергә алар иске Татар бистәсенә элекке ямен кайтарачаклар.

Кабан күлендә тәгәрмәчле пароход, венеция гондолаларына охшаш көймәләр йөзәчәк, яр буйлап атлы трамвай (конка) йөриячәк. Элеккеге Печән базары мәйданында татар сәнгате, һөнәрчелеге һәм көнкүреше музее ачылачак. Болак тирәсе урамнарына шәһәргә милли төс бирерлек архитектура бизәкләре өстәләчәк.

Экономистлар исәпләвенчә, күлләр һәм алар тирәсендәге территорияләрне тулысынча реконструкцияләү, дамбаларны рәтләү, төпне чистарту, суга һава өрдерү, чистарту корылмалары салуны да кертеп, йөз миллион сумга төшәргә тиеш. Кыйммәт, әлбәттә. Бигрәк тә, шәһәрнең кичектергесез проблемалары моннан гайре дә бихисап икәнен уйласаң. Ләкин экологлар табигатьне саклауда «акча кысу»ның тагын да кыйммәткәрәк төшәчәген әйтәләр. Сүз кешеләрнең сәламәтлеге турында бара бит. Аллергия, тире авырулары, онкологик чирләр, тын юллары ялкынсынуларның артканнан арта баруы, күп кенә галимнәрнең фикеренчә, асылда мохитның пычрануы нәтиҗәсе булып тора. Димәк, бүлеп бирелгән акчаны тота белергә, максатларны һәм аларга ирешү юлларын дөрес билгеләргә кирәк.

Шушы максаттан чыгып, шәһәрнең берләштерелгән экология хезмәте булдырыла. Аңа экологлар да, биологлар, медиклар, психологлар, архитекторлар, философлар да җәлеп ителә.

Университетның теоретик кибернетика кафедрасында Кабан күленең электрон-хисаплау моделе эшләнгән. Электрон-хисаплау машинасы, теге яки бу тискәре фактор булган тәкъдирдә, күлнең үзен ничек тотасын шактый төгәл исәпләргә мөмкинлек бирәчәк.

Әлеге модель, экология җәһәтеннән караганда, бетон ярның файдасы гаять аз булуын күрсәтә. Суны камыш, күрән, тал куагы үскән сөзәк яр бик шәп чистарта икән. Күл камышы, әйтик, пестицидлар, фенол һәм авыр металл кушылмаларын (шул исәптән, терекөмешне дә) «суырып ала». Кызык: мондый матдәләрнең сабакта һәм яфрактагы концентрациясе судагыдан ун мең өлеш күбрәк була

икән. Ягъни камыш суны сөзеп чыгара һәм моны махсус корылмаларга караганда шәбрәк тә эшли!..

Боларның бөтенесен дә исәпкә алып, университетның табигатьне саклау кафедрасы Кабан күлләре системасын республика күләмендәге табигать һәйкәле итү турында закон проекты эшләде һәм аны хөкүмәт органнары каравына кертте. Проектта күл тирәсендәге буш урыннарда 50—100 метр киңлектә яшеллек саклау зоналары булдыру каралган. Мондый зонада нәрсә дә булса төзү тыела, ул бары ял итү, балык тоту өчен генә файдаланылачак. Проект суны чистартуны гына түгел, күлнең балык хәзинәсен яңартуны да күздә тота. Мөмкин эшме бу?

Берничә ел элек Оренбургтагы дусларым мине соклангыч бер күлгә алып бардылар. Җете яшел зирек, тал куакларына, камышка күмелеп утырган зәңгәр күл өстендә кара болыт булып киек кошлар бөтерелә. Чүрәкәй үрдәкләр дә, кыр казлары да, патшаларча мәгърур сылу аккошлар да, челәннәр дә бар монда... Яр буенда утырган балыкчылар алабугаларны һәм симез корбан балыкларын чүпләп кенә торалар...

Бу күлнең Оренбург газ эшкәртү заводы агынтыларыннан хасил булганлыгын белгәч, исем китте. Хикмәт менә нәрсәдә икән — монда баштан ук табигатьне мөмкин кадәр саклауны максат иткәннәр. Чистарту корылмалары дирекциянең дә, җәмәгать оешмаларының да күз уңында. Иң яңа сепараторлар кулланалар, агулы катнашмаларны нейтральләштерүнең нәтиҗәле юлларын эзлиләр, кислород өрдерү һәм биологик чистарту кулланалар. Арзанга төшмитөшүен, аның каравы шәһәр искиткеч табигать почмагына, ял итү урынына ия булган.

Мондый мисаллар тагын да бар. Идел тамагындагы Зур лиман дигән ясалма сулык турында газеталарда күп язылды. Лиман асылда Волжск шәһәре чистарту корылмалары тезмәсендәге соңгы буынны тәшкил итә. Ике йөз мең кеше яшәүче кала һәм зур-зур нефть-химия предприятиеләре суларын шунда агызалар. Ләкин — бары химик, механик һәм биологик чистарту үткәннән соң гына.

Зур лиман түбән Иделнең балыкка һәм киеккә бай табигый лиманнары арасында да аерылып тора. Балык монда хәттин ашкан, аккошлар, челәннәр йөзеп йөри, башка төрле киек кошлар көтүләре белән оя кора. Яр буе әрәмәләрендә гүзәл боланнар утлап йөри. Кабан дуңгызлары шулкадәр үрчегән ки, лиманны дәүләт заказнигы дип игълан итеп, аларны аттыра башларга туры килгән.

Мин, әлбәттә, Кабан күлләре тирәсенә дә яңадан көтү-

көтү кабан дуңгызлары әйләнеп кайтыр дип өметләнмим. Ләкин кешенең үзе харап иткән соклангыч, гаҗәеп табигый сулыкны табигатькә кайтарып бирмәскә хакы юк...

СҮЗГӘ УКУЧЫ КУШЫЛА

Чит ил концессиясе турындагы хәбәр. Болак серләре. Җир асты юлы кая илтә?

Әлеге китаптан өзекләр башта республикада чыга торган газета-журналларда басылган иде. Шул уңайдан редакцияләргә һәм минем үземә дә күп кенә хатлар килде. Аларның иң кызыклылары белән укучыларны да таныштырып үтәсем килә.

Казанда яшәүче Илдус Әҗемев борынгы Әҗемнәр нәселеннән икән. Хатында ул менә ниләр яза: «Исмәгыйль абый Әҗемевны томанлы гына хәтерлим, чөнки бәләкәй идем. Кабан буендагы өйләренә әтием алып барган иде. Хәзер ул йорт юк инде. Безгә үзе дә килгәли иде. Әтиемнең сөйләвенә караганда, бик тә гыйлемле кеше булган ул. Аяклы энциклопедия инде. Хәтере дә яхшы булган. Нәселебез шәҗәрәсен генә түгел, туган як тарихын да энәсеннән җебенә кадәр белгән. Гомере буена (туксанны тутыра язды, шөкер) ышанмыйлар аңа. Хәтта туган-тумача да «җиңелрәк» бер сәер затка санады. Исмәгыйль абый ихлас күңелдән халкыбызга бөек серне җиткермәк була. Тик... Гамьсезлек диварын җимерә алмый. Һәм менә дүрт гасыр аша сузылган җеп өзелеп калды... Аның халкыбызның үзаңы арткан бүгенге көнгә кадәр яши алмавы үкенеч. Кызганычка каршы, яңартыр өчен, фотога төшерер өчен Исмәгыйль абый кәгазьләрен биргән кешеләр дә намуслы ук булып чыкмый — документларның бер өлеше югала. Моны бик авыр кичерә ул. Теге юньсезләрне каргый, үз-үзен битәрли. Йөри-йөри, тартышып-даулашып та берни чыгара алмыйча хәлдән тайгач, тыныч кына дөнья куя.»

Башка төрле «кайтавазлар» да булды. «Вечерняя Казань» газетасында мәкаләм чыккач, берәү телефоннан шалтыратты. «Данлыклы Әҗемнәр нәселеннән мин»,— диде ул үзе турында. Аннары дорфа төстә таләбен әйтте: Әҗемевларның гаилә сере белән сату итүне юньле чакта туктатыгыз! Югыйсә...» Аныңча, ханнар хәзинәсен кояш яктысына чыгарыр көн җитмәгән әле, аның кем кулына эләгәсен белгән юк. Республикабыз хәзинәдән колак как-

масын дисәң, хәзинә ләм астында тыныч кына ята бирсен, янәсе. Минемчә, Исмәгыйль Әҗемевның төп варисларының бу куркыту-янауларга катышы булмаска тиеш. Картның ике улы, ике кызы бар, һәммәсе дә мөхтәрәм кешеләр. Икесе — фәннәр кандидаты... Әтиләрен җүләрсымак итеп сурәтләгән өчен миңа бераз үпкәләре бар ахрысы. Әйе, Кабан күле белән чыннан да шөгыльләнгән, редакцияләргә дә йөргән, әмма бит аны башлыча күлнең чисталыгы һәм төбендәге ләмне ашлама итеп файдалану мәсьәләсе кызыксындырган... Аларның әйтүенчә, карт үлгәндә аның бернинди кәгазьләре дә булмаган.

Хәер, моңа карата төрле фикерләр бар. Пенсионер Сөләйман Йосыпов миңа Әҗемевның кәгазьләре тулы ике әрҗәне үз күзләре белән күргәнлеген, аларның Каравайда яшәүче Шакировта саклануын әйтте. Мин килгәндә Шакиров анда яшәми иде инде, хуҗалар аның кая китеп барганлыгын белмибез диделәр.

Б. Ерунов чит ил концессиясенең Кабан күлен чистартырга тәкъдим итүе турындагы хәбәрнең, мин уйлаганча, «Волжский вестник» газетасында түгел, (ул 1907 елда ябыла), ә бәлки калган барлык Казан газеталарында да бирелгәнлеген әйтеп язды. Басылу вакытын 1913 ел яки 1914 елның башы дип хәтерләп калган. Эзли торгач, әлеге хәбәр табылды. Казан управасына «Казан шәһәре атлы юлларының Бельгия акционерлар ширкате» мөрәҗәгать иткән булган. Әлеге ширкать, 1885 елдан башлап, Казанда трамвай юллары салу һәм аларны файдалану белән шөгыльләнгән, «Казанский телеграф» газетасында басылган отчетка караганда, 1913 елда ширкатьнең саф табышы 560 мең франк тәшкил иткән. Шундый зур фирманың булмастай эшкә алуынуы шик уята. Ширкать идарәсе кулында ышанычлы документлар булган дип уйларга кирәк.

А. П. Зеленовны исә үзәк универмагны салганда ачылган чокыр менә мондый фаразга этәргән: «Хәзинәне күл төбендә дип уйлыйлар. Ә аны, җир асты юлыннан килеп, күл астына яшергәннәр. Берничә мичкәне, эзне югалту өчен, күл төбенә томырулары да мөмкин...»

Кыю фикер, әлбәттә. Әмма, меңнәрчә куб метр җир казып үтеп, күл астына килеп чыксаң да, бу мәгарәне тиз арада су баскан булыр иде: күл астында су үткәрә торган, известьлы һәм гипслы катламнар ята. Хәзинәне Кремль тавына күмү тизрәк тә, ышанычлырак та булыр иде.

Бу җәһәттән, Илдус Әҗемев сүзе дөреслеккә якынрак түгел микән: «Әтием Кремль тавында башланган яшерен

җир асты юлы Кабан күле буендагы камышлыкка килеп чыга, ул юл экскаватор эшләгән турыдан уза»,— дигән иде.

2 нче төзелеш трестының элекке мастеры, универмагны төзүдә катнашкан Я. Я. Карпунин исә җир асты юлы вариантын бөтенләй инкарь итә. «Төзелеш барганда, чыннан да, кунакханәгә таба сузылган чокыр ачылган иде. Тирәнлеге — дүрт, киңлеге — биш, озынлыгы утыз метр. Идән-түшәмнәре — бетоннан, стеналары ике рәт кирпечтән салынган. Чокырны канализация агынтыларыннан арындыру өчен шәһәрне чистарту трестына 27 мең сум акча түләдек.

Бу чокыр, минемчә, сугыштан соң төзи башланган мич белән ягыла торган бер бик зур йортның подвалы булырга тиеш».

Өлкән төзүченең фикеренә колак салмыйча булмый, әлбәттә. Әмма шәһәр башкарма комитетының капиталь төзелеш идарәсендә бу йорт турында берни дә әйтә алмадылар. Иске карталардан бу урында ул чакта инде революциягә кадәр үк салынган иске йортлар булуы күренә. Сугыштан соң мич ягып җылытыла торган дәүләт биналары салмаганнар да әле.

Сугыштан соң шул тирәдә, Островский урамына табарак, җир иңә. Газеталар мондый вак-төяк хәбәрне язып тормаган, әлбәттә, ләкин шул төбәктә яшәгән карт-коры моны яхшы хәтерли, урынын гына төрлечәрәк күрсәтәләр.

Хезмәт ветераны, отставкадагы офицер Равил Фатыйхович Самсонов үзенең хатында тагын бер кызыклы хәл турында хәбәр итә. «Ун-унике еллап элек, «Казремстрой» трестының 4 нче идарәсендә прораб булып эшләгәндә, минем участокка Свердлов урамындагы Спортлото бинасын ремонтларга туры килде,— дип яза ул.— Чери башлаган такта идәнне бетонга алыштырганда идән астында 8—11 метр тирәнлектә чокыр булуын күрдек. Бик әйбәт булды, бөтен чүп-чарны шунда гына тутырдык. Капкач та ясап калдырдык (ул әле дә тора). Ярты елдан капкачны ачып карасак, аста янә бушлык. Уннарча куб метр чүп кая киткән соң?»

Чыннан да, кызык бит. Катлам уылу-ашалу нәтиҗәсе, дияр идең, ул чагында бина үзе дә җимерелергә йә, ким дигәндә, иңәргә-ярылырга тиеш. Иң кызыгы шул: әлеге җир упкан урыннарны картага төшерсәң, күлдә серле мичкәләрнең берсе табылган урынга төбәлгән туры сызык хасил була.

Хәер, юрап-хыялланып торасы да түгел. Сернең адресы мәгълүм, хәтта капкачы-ишеге дә бар: ач та тикшер генә. Монысын археологлар эшләргә тиештер.

СОҢГЫ СҮЗ

Әлеге китапның кульъязмасы нәшриятка тапшырылган иде инде. Казанга «Комсомольская правда» газетасының экспедициясе килеп төште. Максаты — Кабан күленнән хәзинәне эзләп табу. Менә кемнәр килде: Мәскәү янындагы «Леонтьево» совхозы электрчысы Виктор Муравьев (ул үзе әмәлләгән махсус җайланма да алып килгән), Мәскәүдәге «Знамя революции» заводы эшчеләре Петр Киреев белән Василий Павлов (икесе дә — аквалангчылар), «Комсомольская правда» хезмәткәрләре В. Юнисов белән В. Козин. Казанлылар арасыннан да ярдәм итәргә теләүчеләр табылды.

Иң әүвәл хәзинәнең кайда ятканлыгын ачыкларга кирәк иде. Муравьев җайланмасы «Динамо» су станциясе тирәсендәге урынны күрсәтте. Муравьевның Казанга өченче килүе бу. Кышын, язын боз өстеннән дә тикшерде. Өченче тапкыр рәттән җайланма нәкъ бер урынны күрсәтте. Планканың нык кына тынычсызлануыннан Виктор, төптә бер генә әйбер ятмый, дигән нәтиҗә ясаган.

Бу урынны 1949 елда мичкә чыгаруда катнашкан Равил Богданов күрсәткән урын белән чагыштыралар. Аннысы илле метр чамасы читтәрәк икән. Кабан кебек зур күл өчен бик аз аерма инде бу... Шулай итеп, эзләү мәйданы ачыкланды. 1988 елның 13 августында егетләр эшкә керештеләр.

«Кабан күле Кара диңгез түгел икән!» — аквалангчыларның беренче сүзе шул булды. Су болганчык, ике метр төшүгә үз кулыңны да күрмисең икән. Су асты фонарьларыннан бер файда да юк (безнең илдә эшләнгәннәр): шундук ватылалар, яктысы да ташка үлчим. Аста суы да галәмәт салкын — 7—8 метр тирәнлектә 6 градуска гына кала. Берничә минут эшләүгә, аквалангчылар кире атылып чыга. Төптә чишмәләр бардыр, ди егетләр. Университетның табигатьне саклау кафедрасы хезмәткәре Н. Минһаҗеваның аңлатмасы бүтәнчәрәк: су болганчык булганга, кояш нуры төпкә төшеп җитә алмый... Җитмәсә, төптә йомшак ләм, ласталар кигән килеш тә суыра. «Кемдер аяктан сөйрәгән кебек»,— ди егетләр... Суның аскы катламы

күкертле водород белән агуланган булуы да өстәмә кыенлыклар тудыра.

Көне дә көн булмады, җитмәсә. Ике ай тоташ Казанда аяз, эссе һава торды. Чумулар башлану белән диярлек көчле җил чыкты, дулкын купты. Җил көймәне читкә куа, эзләү урынын күрсәткән тамгаларны йолка, бауларны чуалта. Күл әйтерсең лә үзенең борынгы серен ачарга теләми иде...

Кыенлыкларга да карамастан, эш туктап тормады. Махсус ыргаклар биш тапкыр авыр гына әйберне эләктереп алды. Тик... «балыклар» бер-бер артлы төшеп кала бирде. Җил-дулкын комачаулый иде. Менә ләмгә тирән үтеп кererлек иң авыр ыргакны бәйләделәр. Богданов мичкә төшеп калган урынны төгәл итеп күрсәтте. Берничә мәртәбә салгач, нечкә корыч трос гитара кылыдай зыңлап тартылды. Бергәләшеп тартып карадылар — йөк кымшанмый да! Троска тотынып, аска Петр Киреев төшеп китте. Шактый гына маташкач, күренде бу. Теше тешкә тими, кислород җитмәүдән йөзенең төсе киткән. Ләм аша теге әйбергә төшеп җитә алмавын әйтте. Аквалангында һава басымы да нык кимегән, бүтән чумарга ярамый, куркыныч. Тик... Күпме ялварулы караш аңа текәлгән: «балык» «кармак»ка капкан ләбаса, әнә генә бит ул!

Бераз ял иткәч, Петр тагын төшеп китә. Бу юлы аның кулында — борынгы сөңгегә охшаган алты кырлы тимер таяк.

Минут артыннан минут үтте. Тынлык. Бары җил сызгырганы гына ишетелә. Төптән гүя кара төтен күтәрелә — Киреев ләмдә актарына... Кинәт трос бушады. Бу ни бу? Соңыннан белдек: Петр, ялгыш, таякның очлы кыры белән тросны чабып өзгән икән. Күп тә үтмәде, көчле җилдән кинәт тартылып, көймә якорьны суырып чыгарды — теге урынны җуйдык.

Икенче көнне кыска гына бәхәстән соң, ярдәмгә профессиональ водолазларны чакырырга булдылар. Казан Үзәк коткару станциясенең тәҗрибәле водолазлары Д. Добронравов белән В. Абросимов ризалык бирделәр.

Профессионаллар тиз эшли икән. Аларның киемнәре дә температурага яраклы, җиһазлары да камилрәк.

— Монда «көндәшләр» булып өлгергән инде,— ди егетләр.

— Нигә алай дисез?

— Ләм ак балчыкка хәтле казылган, балчыкта чокырлар бар. Яңа әле — ләм каплап өлгермәгән.

— Бәлкем земснаряд эзедер?

Бу фараз бердәм рәвештә кире кагыла: земснаряд ярга табарак эшләгән. Аннан, кашыклы фрезаның эзе дә бүтәнчәрәк: кавынсыман һәм зуррак.

Төпкә тагын бер төшкәч, водолазлар әлеге чокырлар яныннан «матди дәлил» дә алып менделәр. Бу — сапер көрәге сыныгы.

Кичен, водолазлар ләм актарганда, һич көтмәгәндә өскә мәет йөзеп чыкты. Йөзе танымаслык булып күпкән. Кем бу, хәзинә эзләүчеме? Аквалангсыз төпкә нигә төшсен ди ул? Су коенганда баткан дияр идең — күлмәк-чалбардан, ботинкадан. Менә сиңа тагын бер табышмак. Монысының җавабын тиешле органнар эзләр.

Мәет бөтенебезнең дә кәефен кырды, күл белән шаярырга ярамаганлыгын искә төшерде. Эзләнүне туктатырга карар кылынды. Водолозлар да: төпне карап-капшап йөрү әллә ни файда бирмәячәк, су астында эшләүче, металлны сизә торган прибор кирәк, диделәр.

Шулай итеп, дүрт көн буена барган эш нәтиҗә бирмәде. 17 августта эш туктатылды. Экспедиция Мәскәүгә кайтып китте. Шуны гына көткән кебек, җил басылды, көн җылынды, ялт итеп кояш чыкты...

Шулай да, борынгы сергә таба беренче адым ясалды. Икенчеләре дә булыр: мәскәүлеләр, әйбәтрәк әзерләнеп, тагын килергә ниятлиләр. Шунысы гына гаҗәп, мондый тынгысыз сертабарлар Казанның үзендә юк микәнни соң? Кабан күле халкыбызның тарихы белән аерылгысыз бәйләнгән милли ядкаребез ләбаса!

Шулай да, хәзинә тирәсендәге шау-шуның төп мәсьәләне каплап китүен теләмәс идем мин. Бәһаләп бетергесез иң зур хәзинә — Кабан күле үзе, аның көмеш суы, зөбәрҗәт яры, сихәтле кислород белән мөлдерәмә тулы фирүзә һавасы икәнен онытмыйк әле!

ЭЧТӘЛЕК

ЛЕГЕНДАМЫ, ГАИЛӘ РИВАЯТЕМЕ? 3

Әрсез карт. Ханнар хәзинәсенең сере. Күл төбендә ниләр бар? Югалган ярлыклар.

КИТАП ЯЗУНЫҢ СЕРЕ 11

Чынбарлык илһам бирде. Югалтулар. «Сасы театр».

КҮЛНЕҢ ҖАНЫ 15

Эт күмгән җирдә корылган кала. Монастырьның «балык биләмәләре». Аккошлар булганмы? Төньяк джунглилары.

КАСЫЙМ ШӘЕХ БИШМӘТЕ *(килеп чыгу табышмагы)* . . 20

Риваять ни әйтә? Галимнәр фикере. Мондый тирәнлек каян килгән? Шайтан почмагы. Сулар кирегә акканда. Җавапсыз калган сораулар.

КҮҢЕЛСЕЗ СӘЯХӘТ 29

Күрсәтмә шундый булгач. Сумы, әллә агумы? Кабанны иң нык пычратучы. 72 миллион куб метр шакшы су. Табигатьне алдый алмыйсың.

КҮЛ БУЕНДАГЫ ШӘҺӘР *(Исемнең сере)* 37

«Кабан»нар ничә булган? Кабанбәк әмир турындагы риваять. Н. Ф. Калинин үткәргән казылмалар. Тагын бер версия. Шулай да, барыбер, кабан дуңгызы...

«КАБАН ҖИҢЕЛДЕ» 44

Абдулла Алиш Кабан турында. Җылылык пычрануы. Кем гаепле? Чистарту корылмаларында.

КАБАН КҮЛЕНДӘ АЖДАҺА БУЛГАНМЫ? 50

Канатлы аждаһа. Легенданы ничек дип аңларга? Казан гербы каян килгән? Күл төбендәге хан кызы. Моңсу хикәят.

ФӘНГӘ МӘГЪЛҮМ БУЛМАГАН КУШЫЛДЫКЛАР 54

Иң изге җирдә. Чыганакны эзлибез. Җир астындагы сер. Кушылдыклар кими... Карар барын бар да...

ТӨГӘЛЛӘНҮНЕҢ БАШЫ 61

Җир асты чишмәсенең сере. Казанның су муенсасы. Беренче реконструкция.

ТАГЫН ХӘЗИНӘ ТУРЫНДА 68

Яшерер хәзинә булганмы? Казанда сугылган тәңкәләр кая киткән? Хәзинәне алып чыгу мөмкин булганмы?

РАВИЛ БОГДАНОВ ХИКӘЯТЕ 76

Кайгылы көн. Бер мичкә алтын. Кабан үзенең серләрен нык саклый.

КАЙСЫ СУ ЧИСТАРАК? 83

«Рәсәйнең Мәскәүдән кала беренче шәһәре бу». Европа белән Азия чигендә. Кабанны фәнни өйрәнү башлангач. Шәһәрне төзекләндерүнең иң «нечкә» җире. Ташаяк ярминкәсе.

ҺӨҖҮМ КӨЧӘЯ 90

Сабын патшалыгы. Сууткәргеч төзү. Кабан пароходлары.

Дума һәм Болак.
КҮЛ НИЧЕК ҮЛӘ? 95
Беренче күкрәү. Яңа индустриаль сикереш. Куйбышев сусаклагычы төзелү. Үлем алды гаргарәсе.
КАБАННЫҢ КАН ТАМЫРЫ 102
Сәер операция. «Хирургия» ярдәм итәрме? Тагын бер проект. Медальнең икенче ягы.
ЭТ КАЙДА КҮМЕЛГӘН? 109
Хатлар, хатлар... Хуҗа Насретдин ишәге. Әзер калып буенча... Табигать дуслары булмаса...
РЕАНИМАЦИЯ 114
Комиссия. Беренче үзгәрешләр. Күтеп алынган көн. Күл тын ала! Кабан буендагы театр.
ЭКОЛОГИК КУЛЬТУРА ТУРЫНДА 124
Умырзаялар кая китте? «Яшәсен хуш исле сабын!» Күл белән балык тоту. Серле чишмә.
НИШЛӘРГӘ КИРӘК СОҢ? 131
Кеше табигатьнең иң гүзәл затымы? Хәл кыласы проблемалар. Күлнең математик моделе. Хәзинә турында бер кәлимә сүз.
СҮЗГӘ УКУЧЫ КУШЫЛА 136
Чит ил концессиясе турындагы хәбәр. Болак серләре. Җир асты юлы кая илтә?
СОҢГЫ СҮЗ 139

Рафаэль Ахметович Мустафин

Массово-политическое издание

ОЗЕРО ҚАБАН

(на татарском языке)

Редакторы *Р. Мәһдиев*
Художнигы *М. Вәлиев*
Художество редакторы *Ш. Насыйров*
Техник редакторы *Г. Шәрифуллина*
Корректоры *Р. Хәкимова*

ИБ 5575

Җыярга тапшырылды 16.04.90. Басарга кул куелды 30.07.90. Форматы 84×108 1/32. Типогр. кәгазе № 2. Литературная гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 7,56. Шартлы буяу-оттиск 8,19. Нәшер-хисап табагы 8,43. Тиражы 15 000 экз. Заказ Л-174. Бәясе 35 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.

У. КАБАН

35 тиен.